Татар әдәбияты

6



Татар әдәбияты 6

Л. Фәттахов. Сабантуй

Ф. Г. ГАЛИМУЛЛИН, Ф. К. МИФТИЕВА,
И. Г. ГЫЙЛӘҖЕВ

Татар әдәбияты

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия

(татар балалары өчен)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Тулыландырылган өченче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1:821.512.145*06
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Г 23

Фәнни редакторы — филология фәннәре докторы, профессор **Ф. Г. Галимуллин**

Дәреслекнең Казан Кремле, Сөембикә манарасы һәм аларның архитектурасы; А.Аббасов; З.Хисмәтуллина; Г.Әпсәләмов; С.Хәким; Р.Фәйзуллин; З.Нури; Р.Фәизов; Н.Әхмәдиев; Милли киемнәр; Милли бәйрәмнәр. Сабан туе бүлекләрен — **Ф. Г. Галимуллин;**

А.Әхмәт; М.Җәлил; Р.Яхин; А.Алиш; Ф.Хөсни; Ш.Галиев бүлекләрен — **Ф. К. Мифтиева;**

Татар халык авыз иҗаты. Җырлар; Һ.Такташ; Җ.Фәйзи; И.Гази; Ф.Халитов; Ш.Биктимеров; Л.Ихсанова; И.Солтан; Милли йолалар; Милли орнаментлар. Бина-корылмаларны бизәү ысуллары бүлекләрен **И. Г. Гыйләҗев** язды.

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Галимуллин Ф. Г.

Г23 Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 6 нчы с-фы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен) / Ф. Г. Галимуллин, Ф. К. Мифтиева, И. Г. Гыйләҗев.— Тулыл. 3 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2005.— 206 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1504-3

ISBN 5-7761-1504-3
© «Мәгариф» нәшрияты, 1999, үзгәрешләр белән
© «Мәгариф» нәшрияты, 2005, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Һәр дәреслекне серләр сандыгы белән тиңләштерергә мөмкин. Чөнки аның эчендә без әлегә кадәр белмәгән күпме белем хәзинәләре бар. Бу яктан караганда, әдәбият дәреслеге аеруча бай була. Сезгә тәкъдим ителгән әлеге әсәрләрдә халкыбызның үткәне, бүгенгесе турында да күп мәгълүмат бирелә. Үткәннәрне бик яхшы белергә, аңларга кирәк. Бары тик шул вакытта гына белемле, ачык фикерле, игелекле, гадел, намуслы булырга, тормышта дөрес юлны табарга мөмкин.

Җирдә милләтләр бик күп. Без — татар милләтеннән. Һәрбер милләтнең үз теле, яшәү рәвеше, дәүләте була. Безнең дәүләтебез Татарстан исемен йөртә. Аны дөньяның бөтен якларында яхшы беләләр. Чөнки Татарстан җире нефтькә бай, анда КамАЗ машиналары, самолетлар, вертолетлар ясала, мех киемнәр, химия промышленносте әйберләре чыгарыла, саный китсәң, бик күп. Бигрәк тә безнең милләтнең кешеләре данлыклы. Каһарман шагыйрь Муса Җәлил, атаклы галим Роальд Сәгъдиев, бөтен дөньяга билгеле табиб Ренат Акчурин, кыю очучы Мәгубә Сыртланова, батыр йөрәкле Петр Гавриловларны кемнәр генә белми! Бу исемлекне әле бик озак дәвам иттерергә мөмкин булыр иде.

Безгә үз милләтебез белән горурланырлык сәбәпләр бик күп. Халкыбызның бай һәм данлы тарихы бар, ул элек-электән олы дәүләтләр төзеп яшәгән, мәдәниятле, югары дәрәҗәдә аңбелемле булган. Күрше халыклар белән дус-тату яшәргә омтылган. Ислам дине йогынтысында йомшак күңелле, әхлаклы, шәфкатьле, намуслы булып тәрбияләнгән. Аның үзенә хас кием-салымы, бизәнү әйберләре, йола-гадәтләре, бәйрәмнәре булган. Болар турында без шушы дәреслек аша байтак мәгълүмат алырбыз. Бу китап газиз халкыбызның тарихы, бай туган телебез белән горурлану хисе тудырыр һәм халкыбызның әдәбиятын, тормыш-көнкүрешен тагын да күбрәк белү теләге уятыр.

Белем иленә сәяхәтне дәвам иттерәбез. Юлыбыз хәерле булсын!

Татар халык авыз иҗаты

ҖЫРЛАР

> Татар халкының үз җырлары... ниндидер үз характерына туры килгән авыр, сабыр моң. Әйтерсең ул аның язмышыннан сыгып алынган. Күңелгә бер керсә, тиз генә чыкмый, төпкә утыра, төпкә ята.
>
> *С. Хәким*

Халык күңелендә туган, аның хисләрен, кичерешләрен чагылдырган әсәрләр бездә бик күп. Халык авыз иҗаты әсәрләре кешеләрнең тормыш турындагы уйлануларын, теләкләрен, хыялларын, яшәү рәвешен, идеалларын, киләчәккә омтылышларын чагылдыра.

Татар халык авыз иҗаты әсәрләре күптөрле. Алар: әкиятләр, бәет, мәкаль, табышмаклар һәм башкалар. Җыр — шуларның берсе. Әкиятне берәү сөйли, ә икенчеләре исә тын да алмыйча тыңлый. Табышмакны берәү әйтә, ә тыңлаучылар аңа җавап табарга тиеш була. Ә менә җырны кеше үзе өчен генә дә башкарырга мөмкин. Сагышланганда, кеше җырлап юана, күңелен тынычландыра. Шатлык, куаныч килсә, үзе дә сизмәстән, җыр сузып җибәрә. Кешенең җаны, рухы әнә шулай җыр булып, моң булып агыла башлый.

Җыр кешенең эчке дөньясын, аның хис-кичерешләрен чагылдыра. Вакыт үткән саен, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр һәм аларның дөньяга карашлары да үзгәрә бара. Бу хәл халык җырларында да чагылмый калмый. Нәкъ менә шуның өчен дә Габдулла Тукай «җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле» җырларга «халык күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер. Бу төрле сихри көзгедер», дип югары бәя биргән. Әллә ничә гасырлар буена күңелләрдә туып, камилләшеп

килгән җырлардан халыкның яшәешен, кайгы-хәсрәтен һәм шатлыгын, ягъни күңел байлыгын бик ачык күреп була. Җырларда аның изге теләкләре, якты омтылышлары, бәхеткә, иминлеккә, матурлыкка булган өметләре дә урын ала.

Җыр дип әйтүгә, күңелгә билгеле бер сүзләр һәм көй килә. Әйе, җыр сүздән һәм көйдән тора. Халык, сәләтле сүз остасы булу белән бергә, моң чыганагы да. *Көйгә салынган шигъри әсәрләргә җыр дип әйтәләр.*

Халык авыз иҗаты әсәрләренең башка төрләре белән чагыштырганда, җыр халык арасында тизрәк таралып өлгерә. Чөнки халык җырларының көй белән аерылмас бәйләнеше бар. Алар иң борынгы заманнардан бирле билгеле бер моңкөйгә ятышлы рәвештә иҗат ителгәннәр, җырның сүзләре көе белән генә табигый яңгырый. Матур көй исә күңелгә тирән үтеп керә. Икенче төрле әйткәндә, көй, моң — җыр сүзләренең канатлары.

Халык иҗатын өйрәнүче галимнәр җырларны, нинди уңай белән, кайда башкарылуына, эчтәлегенә карап, түбәндәге жанрларга бүләләр: *йола җырлары, уен җырлары, хезмәт җырлары, иҗтимагый тормышны чагылдырган җырлар, тормыш-көнкүреш җырлары, лирик җырлар.*

Хәзер шушы жанрларның кайберләренә аерым тукталыйк.

Борынгы заманнарда халык төрле гореф-гадәтләрне һәм йолаларны үтәүгә тугрылык саклаган. Мәсәлән, яз көннәрендә җылы яклардан кайткан кошларны шатланып каршы алу, бай иген уңышы теләп, беренче буразнага йомырка тәгәрәтү гадәтләре, карга боткалары, язгы чәчүдән соң була торган Сабан туйлары һ. б. борынгы ышанулардан калган йолалар. Аларның берсе дә җырсыз узмаган.

У е н җ ы р л а р ы. Уеннар халыкта, бигрәк тә яшьләр тормышында, зур урын тоткан. Уеннарның күбесе җырлау, такмаклау белән башкарылган.

Халык уеннары җырлы һәм җырсыз уеннар дигән ике зур төркемгә бүленәләр. Җырлы уеннар кумәк һәм аерым-аерым җырлау рәвешләрен алганнар, алар арасында такмак әйтеп бию аерым урынны алып тора.

Халкыбыз уеннарында кара-каршы әйтелүче яки биеп башкарыла торган кыска җырларны *такмак* дип әйтәбез.

Җырның аерылгысыз юлдашы булып бию яши. Бигрәк тә күңелле-шаян җырлардан биюгә күчеп китүе җиңел. Җырбию күп кенә очракларда бергә үрелеп яши.

Бию такмагы — борынгы жанр. Ул әле биюләр музыкасыз гына башкарылган заманнарда ук туган. Чөнки кешеләр аптырап калмаганнар: такмак әйтеп биегәннәр. Хәзерге көннәргә кадәр телдә сакланган «Әпипә», «Әнисә», «Бас, бас эзенә», «Бие-бие, Хәйбулла» кебек, бию көенә җырлана торган бик күп сандагы шигъри тезмәләр бар. Такмакларның максаты — биючеләргә ритм биреп, дәртләндереп тору. Такмак чыгару, аны әйтү бүгенге көндә дә саклана. Гармунга бию белән бергә такмакка биюне дә күзәтергә мөмкин. Такмак әйтешле әйлән-бәйлән уеннарында яшьләр теләп катнашалар.

Җыйнап кына әйткәндә, такмаклар татар халкының сурәтле фикерләү мәйданы иксез-чиксез икәнлеген, ә туган телебезнең сыгылмалы, шигъри яктан бай, бизәкле булуын исбатлый. Җырлы уеннар бездә бик киң таралган булган. Яшьләр су буйларында, болыннарда күмәк җырлап күңел ачканнар. Мәсәлән:

Бас, кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам;
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам («Әпипә»).

Тыпыр-тыпыр биергә
Тимер идәннәр кирәк,
Тимер идәннәр өстендә
Имән өстәлләр кирәк («Әнисә»).

Ай-ли, бөгелми,
Матур баса түгелме;
Тып-тып басып биегәндә,
Күңелне ача түгелме («Бас, бас эзенә»).

Хезмәт җырлары. Халык җырының иң беренче үрнәкләре эш кораллары әле камилләшеп җитмәгән заманнарда ук күмәк хезмәт вакытында барлыкка килгән. Кеше ләззәтләнеп эшләгәндә дә, юлда да, кырда һәм болында да, ял вакытында яки кайгылы, хәсрәтле минутларында да җырга мөрәҗәгать иткән. Җыр аның хезмәтен җиңеләйткән, хәсрәтле чагында күңел юанычы булган. Йорт салу, печән чабу, тула басу яисә киндер талку кебек авыр хезмәтне җиңеләйтүгә, аны күңеллерәк итеп оештыруга җыр бик нык ярдәм иткән. Хезмәт җырларын, әлбәттә, өмә җырларыннан башка күз алдына да китереп булмый.

Жырлый-жырлый, гөрли-гөрли
Өмәләрдә күңел ачабыз,
Ак оекка, ак чикмәнгә
Сулап тула басабыз;
Яшь йөрәктә янган утны
Алып читкә атабыз, —

кебек «Өмә жыры» буш җирлектә тумаган, әлбәттә. Бу хезмәт лирикасының җырда чагылуын күрсәтә.

Лирик җырлар. Борынгы халык көйләренең күбесе *озын, моңлы көйләр.* Аларда аһ-зар да, сагыш та яңгырый. Ләкин ул җырларда тормыш авырлыгына түзәргә ярдәм итүче көч тә бар. Иң сагышлы җырларда да усаллык, ямьсезлек, шәфкатьсезлек фикерләре булмый. Алар мәрхәмәтле, кешелекле булырга, татулык, дуслык, бердәмлеккә өндиләр, сабыр итәргә кушалар.

Халкыбыз арасында бик киң таралган һәм хәтта хәзер дә телдән төшмичә җырланып йөри торган «Кара урман», «Салкын чишмә», «Галиябану», «Су буйлап» һәм башка шуның кебек бик күп җырларыбыз бар. Болар — борынгы җырларыбызның матур үрнәкләре. Менә, мәсәлән, «Салкын чишмә» җыры:

Кара урманнарны чыккан чакта,
Кара атым чаба әлсерәп.
    Тау астында салкын чишмә
    Таң алдыннан туңадыр;
    Күрми торулары авыр,
    Күргәч, күңелем буладыр.
Акыллы башымны тиле итте
Башларыма төшкән хәс(е)рәт.
    Тау астында салкын чишмә
    Чылтыр-чылтыр агадыр;
    Уян, егет, эшкә башла,
    Гомерләр үтеп барадыр.

Сүзләренә игътибар итегез: әлеге юлларда халыкның сагышы, хәсрәте чагыла, шуның белән бергә киләчәккә өмет, ышаныч та бар. Бәхетнең хезмәт белән тәэмин ителергә тиешлеге хисләргә төреп бирелә.

Ә көендә никадәр моң, серле авазлар агышы!

Җырларны музыка коралларына кушылмыйча да башкарып була.

Җыр — мәңгелек, чөнки халык яшәгәндә, ул югалмый. Заманнар узган саен, җыр күмәк рәвештә башкаруга һәм төрле музыка коралларына кушылып җырлауга яраклаша, аның яңгырашы, рухы да үзгәрә. Композиторларыбыз, халык моңнарын өйрәнеп, яңадан-яңа көйләр иҗат итәләр. Шулай итеп, халык тормышында булган вакыйгаларга бәйле хис-кичерешләр җырларда төгәлрәк, тулырак чагыла башлый. Ләкин борынгы бабаларыбыз тарафыннан иҗат ителгән җырларның матурлыгы һич кенә дә кимеми, киресенчә, көннән-көн кадерләре арта. Бүгенге көй иҗатчылары, күренекле композиторларыбыз да борынгы көйләрне өйрәнәләр, алардагы сихри моңнарны үз иҗатларында да бик уңышлы файдаланалар.

Җырның ни дәрәҗәдә моңлы, тәэсирле яңгыравы аны башкаручыларның тавышына, сәләтенә дә бәйле. Җырларны һәркемнең күңелен тибрәндерерлек итеп, тыңлаучының йөрәгенә кереп урнашырлык итеп иҗат итүдә халык үзенең тел байлыгыннан да бик оста файдалана белә. Һич тә икеләнмичә, җырларны туган телебезнең матурлыгын күрсәтә торган, аны баетуга хезмәт итә торган гүзәл бер хәзинә дип әйтә алабыз.

Камил Мотыйгый, Газиз Әлмөхәммәтов, Галия Кайбицкая, Ситдыйк Айдаров, Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Фәридә Кудашева, Әлфия Афзалова, Илһам Шакиров, Рәйсә Билалова, Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллина, Габдулла Рәхимкулов, Флера Сөләйманова кебек җырчылар — халкыбызның тирән мәхәббәтен казанган шәхесләр.

Халык авыз иҗаты үрнәкләре

Яшә, Республикам!

Биек тауның башларында
Уйный каплан баласы.
Яшә, минем Республикам,
Яшә, Казан каласы!

Аккошлар чума күлләргә,
Былбыл куна гөлләргә.
Җырлый-җырлый без барабыз
Алдагы шат көннәргә.

Безнең илләр — ямьле җирләр,
Үсә бездә ал гөлләр.
Гөлләр кебек матурланды
Безнең хәзерге көннәр.

Бу җыр егерменче еллар башында Татарстан Республикасы төзелү уңае белән халык тарафыннан чыгарылган. Халык үз дәүләтенең данын еракларга яңгыратырга теләгән, аңа мактау җыры багышлаган. Аның сүзләренә игътибар итегез. Ирек сөюче, горур капланны халкыбыз күңеленә якын итә, үзенең дә кабат биеклекләргә ирешергә тиешлеген әйтә. Аккош, былбыл, ал гөл сурәтләре — халык иҗатының барлык жанрларында да еш очрый торган гүзәл образлар. Халык үзенең бүгенгесен, бигрәк тә киләчәген, әнә шулай матур итеп күрергә тели.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Халык авыз иҗаты төшенчәсен аңлатыгыз.
2. Җыр халык авыз иҗатының башка төрләреннән нәрсә белән аерыла?
3. Җырлар, нинди уңай белән һәм кайда башкарылуына, эчтәлегенә карап, нинди төркемнәргә аерылалар?
4. Сез тагын нинди уен җырлары беләсез? Үзегез белгән җырлы уеннарны бергәләп уйнагыз.
5. «Моң» төшенчәсен сез ничек аңлыйсыз? Ул җырның сүзләре белән бәйләнгәнме, көе беләнме?
6. Татарстан Дәүләт гербына ни өчен каплан (барс) сурәте төшерелгән дип уйлыйсыз?

уйлану — фикерләү (размышление)
теләк — омтылыш (желание, стремление)
хыял — чикләнмәгән киңлектә уйлану (мечта, фантазия)
киләчәк — алда булачак нәрсәләр (будущее)
мәкаль — пословица
табышмак — загадка
кайгы-хәсрәт — борчу (горести и печали)
көй — мелодия
ямьсезлек — күңел кайтаргыч күренеш (безобразность)
мәрхәмәтле — рәхимле (милосердный)

Җыр турында мәкаль һәм әйтемнәр

Ил яшәве — җыр белән.
Сүз — басу, җыр — чәчәк.
Җыр белгәнгә җыр — һөнәр, җыр белү дә — зур һөнәр.
Җыр — күңелгә куаныч, күңелсезгә юаныч.
Җырлап эшләсәң, җырлап яшәрсең.
Эчкә сыймаган җырга чыга.
Бер йөрәктә туган җыр мең йөрәкне кузгата.
Яхшы җырның даны үзеннән алда йөри.
Җырсыз кеше — канатсыз кош.
Җыр — юлдаш, эштә кулдаш.

Казан Кремле, Сөембикә манарасы һәм аларның архитектурасы

Билгеле булганча, татар халкы үз тарихында аеруча катлаулы юл үтте. Бик ерак тарихка китеп тормастан, бары тик аның шактый соңгы чорларына гына күз ташлыйк. 1236 елга кадәр Идел һәм Чулман елгалары буенда Болгар дәүләте яшәп килә. Идел Болгары исеме белән дөньяга танылган бу дәүләт һәм матди тормыш, һәм хәрби, һәм фән, һәм мәдәният үсеше ягыннан нык алга китә. Ләкин 1236 елда аны Алтын Урда дип аталган гаять зур илләр берләшмәсенә кертәләр. XV гасыр урталарына исә бу берләшмә аерым ханлыкларга таркала: Казан ханлыгы, Әстерхан ханлыгы, Себер ханлыгы, Кырым ханлыгы, Касыйм ханлыгы. Болар барысы да татар ханлыклары. Күргәнебезчә, без Алтын Урдага Болгар иле хәлендә кертелгәнбез, ләкин аннан аерылып чыкканда, Казан ханлыгы исеме белән атала башлаганбыз. Аның башкаласы — Казан шәһәре. Мөстәкыйль яшәгән йөз елдан артык вакыт дәвамында (1445 — 1552) Казан ханлыгы зур уңышларга ирешкән, халкы мул, ирекле, бәхетле яшәгән, мәгърифәтле булган. Татар телендә бик күп әдәби әсәрләр, фәнни хезмәтләр язылган, биредә бай китапханә булган (әлбәттә, сүз кулдан язылган һәм күчерелгән китаплар турында бара).

Казан шәһәре койма белән әйләндереп алынган, аңа керүчыгу юллары нык сакланган. Шәһәр үзәгендә, Казансу өстендәге калку урында, Хан сарае урнашкан. Әлеге сарай аерым койма белән уратылган. Ул ике рәт имән бүрәнәләрдән ясалган, алар арасына таш һәм балчык тутырылган. Бу ныгытма эчендә, Хан сараеннан тыш, таш сарайлар, мәчетләр, мавзолейлар булган. Шәһәрнең халкы утыз меңгә җиткән. Ул вакыт өчен бу шактый зур сан.

Казанның халык яши торган бистәләрендә йортлар нигездә агачтан эшләнгән. Эреле-ваклы остаханәләр тезелеп киткән. Һөнәрчеләр савыт-саба, бизәнү әйберләре, өс һәм аяк киемнәре, ат җигү дирбияләре, арба-чана һәм башка күп нәрсәләр эшләгәннәр. Биредә берничә базар булган. Казан ханлыгы Көнчыгыш һәм Көнбатыш илләре белән мәдәни, сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырган. Ханлыкның халкы үз туган телендә сөйләшкән. Ислам дине кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне билгели торган төп канун булган.

Казан ханлыгы халкы төзелеш, архитектура өлкәләрендә дә зур уңышларга ирешкән. Казан ул вакытта Идел-Урал төбәгенең мәдәни, икътисади һәм сәяси үзәгенә әверелгән. Йортларны, башка корылмаларны да матур һәм мәһабәт итеп төзергә тырышканнар. Җәмәгать биналарын, дини корылмаларны ак таштан, кирпечтән салу алга киткән. Сәүдә пулатлары, кәрвансарайлар, мунчалар да күп булган.

Күрше рус дәүләте Казанга еш-еш һөҗүм оештырып тора. Шуңа күрә шәһәрне саклау чараларын күрергә кирәк була. Менә ни өчен Кремльне калын диварлар, хәрби манаралар белән ныгытуга игътибар ителә. «Ул тирәләргә яу үтәрлек түгел», — дип яза шул вакыттагы Казан елъязмачысы.

Хан сарае Кремльнең төньяк өлешендә урнашкан. Анда керү өчен кирпечтән салынган биек манара капкасыннан үтәргә кирәк була. Шуннан ерак та түгел сигез манаралы зур мәчет булган, аны Җамигъ мәчете дип йөрткәннәр.

Татарлар төзелеш өлкәсендә бик нык алга киткәннәр. Казан Кремлендә, шәһәрдә генә түгел, авыл җирләрендә дә гүзәл биналар шактый күп була. Югары дәрәҗәдәге Мәскәү түрәләреннән берсе, мәсәлән, Арча якларында булганнан соң, болай дип язган: «Ул җирләрдәге... түрәләрнең йортлары бик тә гүзәл һәм чын-чынлап таң калырлык».

Ләкин 1552 елның 2 октябрендә рус патшасы шушы тыныч кына яшәп яткан ханлыкны, йөз меңле гаскәр белән килеп, явызларча басып ала. Шәһәрнең күп биналары яндырыла, меңнәрчә-меңнәрчә татарлар вәхшиләрчә үтерелә. Казан шәһәре, бигрәк тә аның Кремль туфрагы, ата-бабаларыбызның изге каны белән сугарыла. Халык рус басып алучыларына каршы көрәштә каһарманлык күрсәткән Япанчы, Кол Шәриф кебек асыл ирләрен онытмый.

Руслар Кремль диварларын гына түгел, бистәләрнең саклану корылмаларын да җимерәләр, манараларны шартлаталар.

Дүрт елдан соң үзләре үк Кремльне төзекләндерү эшләрен башлап җибәрергә мәҗбүр булалар. 1556 елда Кремльдә булган биналарны исәпкә алу кенәгәсеннән күренгәнчә, бу вакытта анда Хан сарае, Ширин кенәзләренең сарае, Хан мәчете, Нургали мәчете, җимертелгән мавзолейлар була. Руслар, мәчетләрне җимереп, христиан дине храмы салалар. Сөембикә манарасы янындагы Нургали мәчетен дә сарай чиркәвенә әверелдерәләр. Төзелеш өчен таш кулланалар. Кремль диварлары 4—5 метр киңлектә, биеклеге урыны-урыны белән 8—12 метрга җитә. Кайбер урыннары имән бүрәнәләр кулланып эшләнә. XVIII гасыр башында (1730 елда) агачтан ясалган урыннар таш белән алыштырыла. (Ул чакларда анда унөч манара булса, хәзер алар — сигез.) Казан Кремле патша армиясенең терәк пункты булып әверелә. 1774 елда Е. Пугачев явы анда кереп качкан патша гаскәрләрен штурмлап карый. Пугачев гаскәрендәге татар халкының батыр улы Бәхтияр Канкаев җитәкчелегендәге татар берләшмәләре уңышка ирешә алмыйлар.

Кремльнең төп биналарыннан берсе — Спас манарасы. Ул шулай ук ак таштан эшләнгән, турыпочмаклы, ике яруслы. Әлеге манара XVI гасырда салынган. Биеклеге 46,6 метр. XVIII гасырның беренче яртысында анда суга торган сәгать куела. 1780 елда сәгать тагын алыштырыла, ул инде сукмый торган була. 1963 елдан бирле анда телләренә алтын йөгертелгән, суга торган электр сәгате эшли.

Әлбәттә, Кремльдәге иң мәһабәт бина — Сөембикә манарасы.

Сөембикә үзе кем булган соң? Ул тумышы белән Нугай ханы Йосыф кызы. XVI йөзнең утызынчы елларында Казан ханлыгы белән идарә итүче Җангали исемле ханга Сөембикәне кияүгә бирәләр. Мәскәү дәүләте алдында яхшатлы булып күренергә теләгәне өчен монда Җангалине яратып бетермиләр. Шуңа күрә 1536 елда аны үтерәләр. Сөембикә Сафагәрәй ханга кияүгә чыга. 1547 елда аның улы туа. Аңа Үтәмешгәрәй дип исем кушалар. Балага ике яшь тулганда, кинәт әтисе үлеп китә. Шушы сабый хан дип игълан ителә. Үтәмешгәрәй үсеп җиткәнче, әнисе Сөембикә ханлык белән идарә итәргә тиеш була.

Ләкин Мәскәү дәүләте белән Казан ханлыгы арасындагы мөнәсәбәтләрнең тагын да куркыныч төс алуын булдырмас өчен, Казанның сатлык табигатьле өстен катлаулары Сөембикә

Сөембикә. *Р. Төхфәтуллин рәсеме*

белән Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә сөргенгә озаталар. 1553 елның 5 гыйнварында Үтәмешгәрәй чукындырыла, аңа Александр дигән исем бирәләр. Сөембикәне исә Касыйм ханы Шаһгалигә — Казанның Мәскәү тарафыннан яулануына күп тырышлык куйган кешегә — кияүгә бирәләр. Сөембикәнең шуннан соңгы язмышы турында анык кына мәгълүматлар юк.

XIX гасырда рус телендә чыккан белешмә-сүзлектә (энциклопедиядә) мондый аңлатма китерелә: «Сөембикә манарасы — татар халкының монументаль һәйкәле. 1549 елның мартында Сөембикәнең ире Казан ханы Сафагәрәй үлә. Сөембикә ихтыяры (теләге. — *Ф. Г.*) белән тиз арада бу манара Сафагәрәй кабере өстенә төзелә. 1552 елда Казан алынганнан соң... Сафагәрәй кабере аннан күчерелә. Шуннан соң мавзолей күзәтү манарасы итеп файдаланыла»[1]. Димәк, бу корылма мавзолей буларак төзелгән, соңыннан урыслар аны хәрби максатларда файдаланганнар. Шуңа күрә аны башка биналарны җимергән вакытта ватмый калдырганнар да. Ягъни ул аларга кирәк булып чыккан.

Җиде катлы бу бина әллә кайлардан ук күренеп тора. Ислам дине өйрәтүләре буенча, күк җиде каттан тора. Алла тәхете җиденче күктә. Җәннәт тә шунда ук дип аңлатыла мөселман динендә. Җиде катлы бу манара да күкнең җиденче катына омтылганлыкны раслап тора. Аның биеклеге 58 метр. Ул, нигезе тигез булмау сәбәпле, 1 метр 89 сантиметрга көнчыгышка авышкан. Әле 1960 елда авышлык 1 метр 69 сантиметр иде. XX гасырның соңгы елларында, авышуны туктату өчен, нигезне ныгыту эшләре алып барылды.

Манараның эченнән, тар һәм текә баскычларга баса-баса, өске катларга күтәрелергә мөмкин. Тәрәзәләрдән гаҗәеп матур күренеш ачыла. Идел буйлап килүче көймәләр әллә кайлардан ук күренә. Ослан таулары, шәһәрне уратып алган урман-сулар, Кабан күле, Казан шәһәре уч төбендәгедәй синең алда җәйрәп ята.

Сөембикә манарасын татар халкында биек манара, бөек манара, Хан мәчете дип тә йөрткәннәр. Мәсәлән, Мәҗит Гафури 1907 елда язган «Сөембикә манарасы» шигырендә аны шул исем белән атый.

---

[1] Энциклопедический словарь Брокгауза и Евфрона. 3А том. — С.-Петербург, 1894.

Һәр бинадан биек булып күккә ашкан башың,
Мин беләм белдермәсәң дә: агадыр күздән яшең,
Бу хәлеңнән зарланды синең һәрбер ташың, —
Күңелемне мең кисәккә телде шул гүзәл Хан мәчете.

Патша Россиясе хөкүмәте Сөембикә манарасының башына ике башлы каракош сынын кадаттыра. Татар халкының күренекле улы Мирсәет Солтангалиев тырышлыгы белән 1918 елның 8 мартында анда мөселманнарның изге билгесе — ай куела. Ләкин совет хакимияте бераздан аны алып ташлаттыра. Бары тик 1990 елның җәендә генә изге ай яңадан үзенең тиешле урынын алды. Хәзер, ниһаять, милләтебез тарихына һәйкәл булып торган Сөембикә манарасы очында алтын ай балкый.

Сораулар һәм биремнәр.

1. 1236 елга кадәр безнең ерак әби-бабаларыбыз нинди дәүләт төзеп яшәгәннәр? 1236 елда нинди вакыйга була? Ул болгарларның тормышына нинди тәэсир ясый?
2. Казан ханлыгы Алтын Урдадан кайчан аерылып чыга? Ул мөстәкыйль булып күпме яши?
3. Казан шәһәре, Хан сарае ни рәвешле ныгытылган булган?
4. Мәскәү дәүләте Казан ханлыгын кайчан сугышып ала? Татар халкына басып алучылар нинди мөнәсәбәт күрсәтәләр? Басып алучыларга каршы сугышкан иң күренекле кешеләрнең исемнәрен әйтегез. Сез тагын алар турында нәрсәләр беләсез?
5. Мәскәү дәүләте басып алгач, Казандагы корылмаларның, йортларның язмышы турында сөйләгез.
6. Сөембикә манарасын кемнәр, кайчан салган дип уйланыла? Кем ул Сөембикә?
7. Сөембикә манарасын ни өчен «ава торган» биналар рәтеннән исәпләп була? Бу «аву» нинди тизлектә бара? Тагын дөньяда «ава торган» нинди манаралар бар?
8. Ни өчен бу манара Сөембикә исемен йөртә?
9. Манараның башына төрле чорларда төрле билгеләр куела. Моның сәбәпләре нидә икән?
10. Мәҗит Гафури Сөембикә манарасына бәйле рәвештә нәрсәләр турында уйлана?

Идел — Волга
Чулман — Кама
Алтын Урда — Золотая Орда

Казансу — Казанка елгасы
сарай — дворец
бистә — слобода
остаханәләр — мастерскойлар
канун — закон
сәүдә мөнәсәбәтләре — торговые отношения
мәдәни — *монда*: культура
икътисади — экономик
сәяси — политик
җәмәгать биналары — общественные здания (мәчетләр, мәдрәсәләр, сарай, мунча һәм башкалар)
дивар — стена
яу — һөҗүм итүчеләр
түрәләр — өстен катлаулар, идарәчеләр
терәк пункты — бу яклардагы гаскәрләрнең төп тупланган урыны, крепость
алтын йөгертелгән — алтынлы буяу белән буялган
Нугай — Иделнең түбән өлешендәге татар дәүләте
тәхет — трон
җәннәт — оҗмах (рай)
дирбияләр — *монда*: ат җигү өчен кирәкле әйберләр

Абдулла Әхмәт

(1905—1976)

Абдулла Әхмәт (Абдулла Сафиулла улы Әхмәтов) 1905 елның 25 мартында Курган өлкәсенең Притобольный районы Звериный авылында крестьян гаиләсендә туа. Ул авылларында башлангыч белем ала. Махсус курслар тәмамлап, балалар йортында тәрбияче, авыл уку йорты мөдире булып эшли.

Аның беренче тапкыр кулына каләм алып яза башлавы егерменче елларга туры килә.

Шуннан соң Абдулла Әхмәт Казанга килә. Педагогия институтына укырга керә. Аны тәмамлагач, балалар укыта. Татарстан китап нәшриятында эшли. «Пионер» исемле балалар журналын чыгаруга җитәкчелек итә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, ул фронтка китә. Алгы сызыкта фашистларга каршы сугыш вакытында яраланып, госпитальдә дәваланып чыга һәм сугышның азагына кадәр фронт газетасы редакциясендә эшли. Солдатларның батырлыклары турында очерк, хикәяләр яза. 1952 елда басылган «Солдат хикәяләре» китабында аның шул хикәя һәм очерклары урын алган.

Абдулла Әхмәт сугыштан соң проза һәм драматургия жанрларында нәтиҗәле эшләде. Безгә аның «Кара алтын», «Яшәү көче» исемле очерк китаплары, «Серләр», «Егет сүзе» һ.б. драма әсәрләре билгеле.

Абдулла Әхмәт калдырган әдәби мирасның күп өлеше балалар өчен язылган әсәрләрдән гыйбарәт. «Үги кыз» — бу өлкәдә аның беренче уңышлы әсәре. Әсәрне яшь укучылар һәм тамашачылар яратып кабул иттеләр. Муса Җәлил, Гадел Кутуй кебек әдипләр дә аны уңай бәяләделәр.

«Бу пьеса, — дип язды М. Җәлил, — балаларга аңлаешлы, гади, җиңел һәм образлы тел белән, борынгы татар халык әкиятләренең берсен сәхнә чаралары аша сөйләп бирә. Язучы яшь буынны намуслылыкка, хезмәт сөюгә, булдыклылыкка, һөнәрле булырга өйрәтә».

Абдулла Әхмәт балалар өчен уннарча пьесалар иҗат итә. «Мәктәптә булган вакыйга», «Әнием гаебе», «Безнең абый», «Камыр батыр» исемле пьесалары шундыйларга керә.

Язучы А. Әхмәт халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю белән дә шөгыльләнә. Ул мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар җыентыгын бастырды (1948). Бу өлкәдәге зур белгеч Хәмит Ярми белән бергәләп «Халык иҗаты» исемле китап та чыгарды (1941). «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» китабын төзүче һәм әдәби эшкәртүче дә Абдулла Әхмәт булды.

Сораулар һәм бирем.

1. Абдулла Әхмәтнең тормыш һәм хезмәт юлы турында сөйләгез.
2. Ул нинди жанрларда иҗат итә?
3. Аның иҗатына М. Җәлил, Г. Кутуйлар нинди бәя бирәләр?
4. Халык авыз иҗатын җыюда аның нинди хезмәтләре бар?

очерк — тормышта булга́н вакыйгаларны, аларда катнашкан кешеләрнең эш-гамәлләрен үзгәртмичә сурәтли торган кечкенә күләмле әдәби әсәр

әдәби мирас — элекке буыннардан калган әдәби әсәрләр, әдәби хезмәтләр

ҮГИ КЫЗ

4 пәрдәдә, 6 күренештә

КАТНАШАЛАР:

Зөһрә — үги кыз, 13—14 яшьләрдә. Төскә матур, уңган, эш сөючән, җыйнак, ябык гәүдәле.

Хәйретдин — Зөһрәнең әтисе, ярлы крестьян, 50 яшьләрдә.

Залимә — Зөһрәнең үги анасы, 35 яшьләрдә.

Мәфтуха — Залимәнең үз кызы, 14—15 яшьләрдә, симез гәүдәле, иркә, тупас, шапшак, ялкау кыз.

Урман карчыгы — 80 яшендә, ябык, бөкре, башын бер якка селкеп сөйләшә.

Аю, бүре, төлке һәм күбәләкләр.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Уртача җыештырылган авыл өе. Түрдә сәке. Аның өстенә мендәр-юрганнар өелгән. Уң якта — мич, ишек, сулда — ике тәрәзә. Пәрдә ачылганда, Зөһрә белән Мәфтуха сәке өстендә яулык чигеп утыралар. Зөһрә акрын гына җырлый.

Зөһрә. Аккош аталар микән?
Итен саталар микән?
Бәхетсез булган балага
Бәхет саталар микән?

Пауза.

Мәфтуха. Нигә туктадың? Җырла, әйдә!
Зөһрә. Әнкәй мине тапкачтын,
Ак биләүгә биләгән,
Ак биләүләргә биләгән,
Бәхете булсын димәгән.

Мәфтуха *(ямьсез тавыш белән җырлый).*

Яулыкларым ал икән,
Әллә алар пар микән?
Берәр илдә, берәр җирдә
Миннән матур бар микән?..

(Көзгегә карап, кашларын сыпыра, чәчләрен төзәтә.)
Зөһрә. Безнең авыл зур авыл,
Килә кыйбладан давыл.
Бәлки, рәхәт көннәр булыр,
Хәзергесе бик авыр.

Мәфтуха. Син, Зөһрә, мин җырлый башлагач, авызыңны ачасы булма, җырлама, әниемә әйтермен.

Зөһрә. Ни өчен?

Мәфтуха. Синең тавышың әллә ничек моңлы. Ә мин җырлый белмим.

Зөһрә *(җырлап куя).*

Җырлый белеп җырламыймын,
Җырлыйм йөрәгем янганга.

Ә синең йөрәгең янмый, моң да юк синдә. Шуның өчен җырлый белмисең.

Мәфтуха. Әй, мактанмасана!

Зөһрә. Мактанмыйм. Дөресен әйтәм. Үз өең, үз әниең... Ә мин... Мин ятим шул.

Мәфтуха. Бар шул! Өебез дә бар, сыерыбыз да, атыбыз да. Әтиеңне дә, сине дә без туйдырып торабыз. Без булмасак, ачтан үләр идегез.

Зөһрә. Үләр. Эшләгән кеше үлми ул. Бар эшегезне әти эшли әле.

Мәфтуха. Хәерче булгач, эшләр шул. Фу, арыдым. Билләрем дә... *(Эшен ташлап, көнбагыш ашый башлый, кабыгын тирә-ягына төкерә.)*

Зөһрә *(җырлый).*

> Сайрый былбыл,
> Сайрый тургай,
> Баласын җуйган бугай...

Мәфтуха. Зөһрә!

Зөһрә. Кем тия?

Мәфтуха. Миңа әнә шул тастымалны алып бир.

Зөһрә. Нәрсәгә ул?

Мәфтуха. Авызымны сөртәм.

Зөһрә. Мин көнбагыш ашамадым, авызым чиста минем.

Мәфтуха. Иллә ялкау да соң син, Зөһрә.

Зөһрә. Үзеңә кирәк булгач, үзең ал инде син аны, Мәфтуха.

Мәфтуха (*кыланып*). Вакытым юк, көнбагыш ярам мин.

Зөһрә *(аның тоны белән).* Вакытым юк, эшлим ич.

Мәфтуха. Алып бирмәсәң, валлаһи, менәтерә энигә әйтәм.

Зөһрә *(тирән сулап).* Шуның белән генә куркытасың да. *(Тастымалны алып Мәфтухага ташлый.)* Сәкегә чүпләмә, ичмасам...

Мәфтуха. Өйрәтмә, себерерсең әле. *(Көнбагыш кабыкларын Зөһрәгә таба төкерә.)*

Зөһрә *(борылып утыра).* Үз чүбеңне үзең себерерсең.

Мәфтуха. Син хәерче — син себер! Ә безнең өебез бар, атыбыз, сыерыбыз.

Зөһрә. Байлык — бер айлык, масайма. И, бер эшем калган икән. *(Торып, тәрәзәләр сөртә башлый.)*

Мәфтуха *(чүпләрен учлап Зөһрәнең чигүенә ташлый, аннары төкереп куя).* Тагын бер эшең бар әле синең.

Зөһрә. Нәрсә?

Мәфтуха. Әнием нәрсә әйтте?

Зөһрә. Нәрсә?

Мәфтуха. Су алып керергә димәдемени?

Зөһрә. Әйдә, бергәләп.

Мәфтуха. Әйем-ләә... Сиңа кушты ич ул. Кузгаласым килми. Болай да ябыгам әле.

Зөһрә. Ябыгам түгел, ярылам, диген.

Мәфтуха. Ачуымны китермә минем. Кисәү агачын алуым булыр, берне кундыруым булыр.

Зөһрә. Кисәү агачы?.. Ике башлы ич ул.

Мәфтуха, сикереп торып, кисәү агачын алып, Зөһрәгә сукмакчы була. Зөһрә, бер дә исе китмичә генә, кисәү агачын тартып алып, Мәфтухага кизәнә. Мәфтуха чырылдап елап җибәрә. Зөһрә аны үчекләп, көлеп чыгып китә.

Мәфтуха. Валлаһи, менәтерә әниемә әйтәм. *(Яшьләрен тастымалга сөртә, Зөһрәнең чигүен ала.)* Каһәр суккан, ничек матур итеп чигә белә. Нишләп мин дә шулай матур итеп чигә белмим икән, әй?! (Үз *чигүен Зөһрәнеке урынына куя, аныкын үзенә ала.)* Менә хәзер минем яулыгым матуррак булды. Бирмим. Пычагым да танымас әле.

Зөһрә керә.

Мәфтуха. Нигә бик тиз кердең?

Зөһрә. Кое чиләген тапмадым. Кайда соң ул?

Мәфтуха. Әһәә... коега төшергән! Әниемә әйтәм.

Зөһрә. Бая кое тирәсендә үзең чуалып йөргәнсең ич.

Мәфтуха *(кычкырып)*. Гомеремдә. Кем әйтә?..

Зөһрә. Әти әйтә.

Мәфтуха *(халыкка карап)*. Карт эт, күреп калды микәнни? Валлаһи, мин түгел.

Зөһрә *(чигүен әйләндергәләп)*. Кара, кара аны, акыллы башны. Мәфтуха, бир үз чигүемне, шаярма!

Мәфтуха. Менә көпә-көндез саташа башлады, акай күз.

Зөһрә. Үз эшемне үзем бик яхшы таныйм мин. Бир. *(Тартышалар.)* Ертасың, бир.

Мәфтуха. Ертылсын, бирмим.

Ачуланып, атылып-бәрелеп, Залимә керә.

Залимә. Кайсыгызның эше ул?!

Мәфтуха. Нәрсә бар, әнием?

З ө h р ә. Әни, ни булган?

З а л и м ә *(ике кызга да йодрыкларын селкеп)*. Чиләк кайда безнең?

З ө h р ә *(мич яныннан чиләкне алып күрсәтә)*. Менә, Залимә апа.

З а л и м ә. Апа?

З ө h р ә. Әни.

З а л и м ә *(чиләкне алып, каты итеп яңадан үз урынына куя)*. Кое чиләге дим мин.

М ә ф т у х а. Кое чиләген Зөhрә коега төшергән.

З а л и м ә. Ә? Өр-яңа чиләк ие, яңа гына алган ием. Һай, әрәмтамак!

З ө h р ә. Мин түгел, әнкәй... Мәфтуха ялганлый.

З а л и м ә. Ә, әле син үз гаебеңне үзең танымыйсың дамыни?! *(Яңагына сугып җибәрә.)*

Зөhрә елый башлый. Х ә й р е т д и н керә.

Х ә й р е т д и н. Ни булды, кызым? Нигә елыйсың?

З а л и м ә. Чебен тимәс чер итәр. Акрын гына яңагыннан сыйпап алган идем.

Х ә й р е т д и н. Ни гаебе бар иде соң аның?

З а л и м ә *(чиләкләрне алып, каты итеп үз урынына куя)*. Су китермәгән, чиләкне коега төшергән, әләкләшә, алдаша, узына.

Х ә й р е т д и н. Ак эт баласе кара эткә дигәндәй...

З а л и м ә. Сез ул этләр. Ач этләр. Минем кызым ул кое янына барырга да курка.

М ә ф т у х а. Зөhрә әле минем чигә торган яулыгымны да үзенеке, ди.

З а л и м ә. Ә?.. Эт симерсә, иясен тешли, ди. Бәлкем, Мәфтуханың калфагы да синекедер, ә? *(Мәфтуханың калфагы белән Зөhрәгә суга.)*

Х ә й р е т д и н. И, анасы, юкка кызма әле, алай димәде, ич.

З ө h р ә. Әти, мин су алырга чыккач, Мәфтуха мин чигә торган яулыкны үзенә алган, үзенекен миңа куйган.

З а л и м ә. Күрдеңме, нәрсә ди ул?!

Х ә й р е т д и н. И, кызым, кызым!.. Кайсыгызга ышанырга инде.

З а л и м ә *(Мәфтухадагы яулыкны алып)*. Нинди матур итеп чиккән минем кызым! Сөбханалла! *(Зөhрә кулындагы чигүне алып.)* Һии... шул да булдымы эш. *(Ташлый.)* Аяк белән чиккәнмени?..

Хәйретдин *(чигүне ала).* И кызым, син алай түгел иең ич.

Зөһрә. Әткәй, әйтәм бит, монысы минеке түгел, дип. Кайчан ялган сөйләшкәнем бар минем?!

Хәйретдин. Кайсыгызга ышаныйк инде. Үрнәкләрегез бер үк төсле.

Залимә. Сөйләшеп торасың тагы, шуны кеше итеп.

Зөһрә. Әти, яулыкның дүрт почмагына дүрт язу чиктем мин. Шуннан беләм мин үз эшемне.

Залимә Мәфтуха янына килә, яулыкны карыйлар. Мәфтуханың колагына нәрсәдер пышылдый.

Зөһрә. Бир әле, Мәфтуха, хәзер укып бирәм.

Залимә. Бирмә, үзең чиккән булгач, үзең укып бир әле, кызым Мәфтуха.

Мәфтуха *(укый).* Ә... ә... әмә... бе... бе... ү... б-б-ү... ле... ле... әк... к... ә...

Хәйретдин. Я, Мәфтуха, әәлдәмичә генә әйт, ни дигән сүз була инде ул?

Залимә. Ие, тоташтырып укы инде, кызым.

Мәфтуха. Ә, ә...мә, бү...бү...

Хәйретдин. Син, Мәфтуха, яңа теле ачылган сабый бала шикелле итеп әәлдисең.

Залимә. Я, кысылма, син үзең сакаллы сабый.

Мәфтуха. Ләк, ләк-ләккә.

Залимә. Шулай, шулай, бүләккә дип язылган. Әниемә бүләккә дип чиккән минем кызым. Шулаймы, Мәфтуха?

Мәфтуха. Шул... шул... шу-ла-а-ай.

Зөһрә. Ышанма, әти, мин чиктем, әтиемә бүләккә дип чиккән идем мин аны. Менә карагыз. *(Яулыкны алып әтисенә күрсәтә.)* Әнием түгел, әтием. *(Елап җибәрә.)*

Залимә. И, чебен тимәс, чер итәр!.. Үзе алдаша да...

Зөһрә. Әти, ышанмасаң, мин яңадан яулык чигә башлыйм. Әнә минекен Мәфтуха үзе чигеп бетереп карасын. Шуннан соң күрербез кем алдашканын.

Хәйретдин. Монысы акыл. Әнисе, әйдә, кызларның һөнәрләрен күрик әле бер.

Залимә. Күрербез, күрербез. Ә хәзергә, хәерчеләр, эшегезгә. Син, атасы, кызың төшергән чиләкне ал коедан. Зөһрә мунчага су ташысын. Барыгыз, бар.

Хәйретдин *(чиләкләрне ала).* Әйдә, кызым.

Зөһрә *(әтисеннән чиләкләрне алып.)* Әйдә, әти. Мин төшермәгән булсам да, аны барыбер безгә аласы.

Чыга башлыйлар. Залимә килеп Зөһрәне чеметеп ала. Зөһрә кычкырып җибәрә, йөгереп чыгып китә.

Залимә. Сөйләнә але, җен баласы! Мин сине!..

Мәфтуха *(яулыкны күрсәтә)*. Инде нишләрбез, әнием?

Залимә. Чигеп бетерерсең.

Мәфтуха. Иң элек син, чигә беләсеңме, дип сора.

Залимә. Мәфтуха, бу каһәр суккан кыз безне тагын хур итәчәк.

Мәфтуха. Ничек?

Залимә. Менә дигән итеп яулыкны чигәр, ә синең?.. Яулыгың да булмас, ялганың да тотылыр.

Мәфтуха. И, әнием, нишлик, нишләтик ул Зөһрәне?..

Залимә *(ачуыннан чигүле яулыкны идәнгә ташлый, таптый, йөренә, урындыкка килеп бәрелә дә аны тибеп җибәрә)*. Чәнчелгере! Ничек котылыйм соң бу аяклы казадан?.. Берничә елдан кияүгә китәргә дә вакыт җитәр үзегезгә. Ә ул барында... ул барында сиңа кем карасын. И, Мәфтуха, әллә кемгә охшап тугансың инде үзең дә.

Мәфтуха. Сиңа охшаганмын. Үзең шулай дисең ич. Кияүгә? *(Акырып елый башлый.)* А...а...әем... мин кияүгә бармыйм. У... бармыйм. У... куркам!

Залимә. Ярый, ярый, бармассың. Сине алам дигән кеше дә юк әле. Кил әле, кызым, бер хәйлә таптым. Котылабыз шул Зөһрәдән, ләгыйньнән!

Мәфтуханың колагына пышылдап нәрсәдер әйтә. Мәфтуха бармаклары белән күз яшьләрен сөртә-сөртә елмая, аннары җитди төскә керә. Тагын елмая.

Залимә. Шак-шок, шак-шок, аңлыйсыңмы? *(Икесе дә ямьсез итеп көләләр.)* Иртәгә үк...

Мәфтуха. Мин дәме?

Залимә. Әйе, син дә, ул да, атаң да, мин дә...

Мәфтуха. Ай-яй, мин куркам!..

Залимә. Шаулама! Әнә үзләре дә керәләр.

Сулы зур-зур чиләкләр күтәреп, Зөһрә күренә.

У... каһәр суккыры! Актык көнең бүген. Иртәгә өемдә эзең дә булмас синең, җен кызы!..

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Аланлык. Яңа гына җиләк-җимеш өлгергән чак. Кошлар сайрый. Чикерткәләр черкелди. Ара-тирә кәккүк тавышы ишетелеп китә. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә берәү дә юк. Бераздан соң ат туктаган тавыш ишетелә. Сәхнәгә кызу атлап, кулына җиләк җыя торган туз савыт тоткан Залимә килеп керә. Ул ара-тирә җиләк алып каба.

Залимә. Җенем сөйми шул кызны. Күрәсем килми! Шул каһәр суккан үги кыз үз кызымны үземә дошман итеп бетерә инде. Үксез бала асрасаң, авызың-борының кан булыр, үксез бозау асрасаң, авызың-борының май булыр, дип юкка гына әйтмәгәннәр икән. *(Арба туктаган якка таба карап.)* Атасы, нәрсә анда уклау йоткан кебек катып торасың. Кил бире!

Чыбыркысын төенли-төенли, башын түбән иеп, Хәйретдин керә.

Хәйретдин. Ай, анасы, бер генә дә күңелем бармый бит бу эшкә!

Залимә. Һи, бозау, синең һаман да үз сиксәнең сиксән булыр инде. Мин кырыкмаса-кырык тапкыр әйттем сиңа: я кызың Зөһрәне өйдән куасың, я мин сине ташлап китәм, дидем. Бераз акылга утырып кайтыр. Пычагым да булмас. Аннары, бик исем китте тагы. Кызыңнан аерыласың килмәсә, иртәгәдән яшь хатыныңның йөзен дә күрмәссең. *(Пырылдап чыга башлый.)*

Хәйретдин *(кыюсыз гына аның артыннан бара)*. Алай чәпчемә инде, анасы. Бала бит, гөнаһсыз сабый бит.

Залимә, килешсез, ясалма рәвештә елмаеп, Хәйретдин янына килә башлый. Акрын гына атлап, җиләк җыя-җыя, Зөһрә керә. Аны күргәч, Залимә, чыраен сытып, читкә борыла.

Зөһрә. Әти җаным, кай тирәдәнрәк җыярбыз икән?

Залимә *(йөзенә ясалма елмаю чыгарып)*. Син, Зөһрәкәй, әнә теге тирәдәнрәк җыярсың. *(Уң якка күрсәтеп.)* Мин менә юл буеннан җыярмын. Җиләкне күп итеп җый, кызым, кайткач бик тәмле итеп җиләк сумсасы пешереп ашатырмын үзеңә.

Хәйретдин *(Зөһрәне сөеп)*. Мин, кызым, менә шушы җирдә утын кисәрмен, балта тавышы ишетелеп торыр.

Залимә. Савытың тулгач, балта тавышы ишетеп килерсең. Адаша күрмә, яме?..

Зөһрә. Ярар, мин савытымны тутырмый килмим, тик сез бик ерак китмәгез инде. *(Чыга башлый, Хәйретдин сискәнеп китә.)*

Залимә *(Зөһрә артыннан бара).* Менә, Зөһрә, сине үги кызым дип бер генә дә кимсетмим бит мин. Җиләккә дә алып килдем үзеңне. Үз кызым әнә өй саклап та калды әле.

Зөһрә. Рәхмәт инде, әни. *(Җиләк җыя-җыя чыгып китә.)*

Хәйретдин агачка сөялеп, күңелсезләнеп карап кала.

Залимә. Атасы, сиңа әйтәм, җебеп торма, эшеңдә бул. Тукмакларың әзерме?

Хәйретдин *(сискәнеп китә).* Нәрсә? Тукмаклармы? Әзер бугай, анасы.

Ике агач ботагына ике тукмак асалар, җил агач ботакларын селкетүгә, тукмаклар бер-берсенә бәрелеп шакылдый башлыйлар.

Залимә *(зәһәрле елмаеп).* Менә Зөһрәнең атасы утын кисә башлады. Үткен бит, атасы, үги ананың балтасы. Киттек, карткаем, артык бүкән башыннан котылдык.

Хәйретдин. Ай, бала, кызганыч бит ул, бала дигән нәрсә. *(Зөһрә киткән якка карый.)*

Залимә *(Хәйретдингә сырыша).* Әй, юләр, шундый яшь хатының белән иркенләп торырга теләмисеңмени?

Хәйретдин. Анысы шулаен шулай да... *(Карана, йөренә.)*

Залимә. Киттек, атасы! *(Халыкка карап.)* Саруымны кайнатып йөргән үги кыздан да котылам. Без хәзер кайтып китәбез, аны ач бүреләр озак яшәтмәсләр. Ике генә йотарлар. Киттек, карткаем, җебегәнем. *(Ирен җилтерәтә, Хәйретдин каерылып-каерылып карый, чыгалар.)*

Пәрдә.

Сораулар.

1. Бу бүлектә сезгә кайсы образлар ошады? Ни өчен?
2. Мәфтуха һәм аның әнисе турында сездә нинди тәэсирләр калды?
3. Зөһрәдән котылу өчен, әнисе белән Мәфтуха нинди план коралар?
4. Әсәрдә «Җырлыйм йөрәгем янганга» дип кем моңая? Бу юллардан сез ни аңлыйсыз?
5. Ялган — кеше өчен бик начар гадәт. Бу әсәрдә кемнәр ялганлый? Залимә һәм Хәйретдиннең ялганнары арасында аерма күрәсезме?

валлаһи — Алладыр, дип ант итү
масайма — мактанма
ябыгу — арыклану, суырылу, чандырлану
кисәү агачы — мичтәге янган утынны әйләндерү өчен, шулай ук күмер тартуда кулланылучы җайланма
каһәр суккан — каргау сүзе (проклятый)
хәерче — ярлы
җенем сөйми — яратмыйм, күралмыйм
уклау — камыр җәя торган җайланма
җебеп торма — *монда:* тик торма
тукмак — бер башы юан итеп, икенче башы тотар өчен җайлап ясалган агач кисәге (колотушка)

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук урман. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә берәү дә юк. Кошлар сайрый, сирәк-сирәк кәккүк кычкыргалап куя. Ерактан Зөһрәнең җырлый-җырлый килгәне ишетелә.

Җир җиләге ачы була,
Үз вакытында пешмәсә,
Кеше хәлен кеше белми,
Үз башына төшмәсә.

З ө һ р ә керә, ул төрле чәчәкләрне үреп башына кигән. Кулында җиләк белән тулган туз тырыс. Агач төбенә утыра, җиләген чүпли. Каршыда гына кәккүк кычкыра башлый. Зөһрә моңлы тавыш белән сузып кына җырлый.

Кычкырма, кәккүк, ай, каршымда,
Кычкырсана агач башында,
Моңлы да гына бала түгел идем,
Моңнар төште ич минем,
Моңнар төште ич башыма.

Тынлык. Тукмак тавышы ишетелә. Пауза. Кәккүк кычкыра.

Моңайма ла, кәккүк, ай, моңайма,
Моңайсаң да, ялгыз калырсың.
Ялгыз башың, кайгы-сагышың,
Кайларга гына очып,
Кайларга гына кайтырсың.

З ө һ р ә. Әти, мескен, һаман да утын кисә! Арып та беткәндер инде ул. Кисмәс иде дә бит... үги әни мине генә түгел, әти

мескенне дә җәберли. Әй, эти!.. Син миңа хәзер эти дә, әни дә. *(Яшен сөртә.)* Әнием исемә төшсә, еламый түзә алмыйм. Ай, бу ятимлек! Әнием исән булса, мин болай мәсхәрә ителеп йөрер идеммени? *(Яшен сөртә, җиләген чүпли, җырлый.)*

Кошлар кайларга гына очалар,
Канаткайларын талдырып,
Әнкәй ташлап китте,
Әнкәй ятим итте,
Ялгызымны калдырып.

Үлде шул минем әнием, үлде, әйбәтем! Әйбәт кешеләр нигә аз яшиләр икән? (*Пауза.*) Менә бу кып-кызыл, эп-эре, иң тәмле җиләкләрне этиемә дип калдырдым. Ул бит кайчаннан бирле әнә утын кисә. Арыгандыр да инде. (*Пауза.*) Караңгы да төшә башлады. Әтигә әйтим дә, кайтыйк инде. (*Торып, тукмаклар тукылдаган җиргә бара башлый, туктый.*) Эти, эти дим, кайтабызмы инде? Менә мин сиңа нинди тәмле, нинди эре җиләкләр... (*Кинәт, барган җиреннән туктап, агач башына карый.*) Тукмаклар! Мин бит аны балта тавышы дип торам. (*Елый.*) Алдаганнар! Адаштырганнар мине! (*Елый. Кире сәхнәгә керә, җиләк савытын кыйшайтып күтәргән килеш чыга башлый, каршысына, койрыгын болгый-болгый,* төлке *килеп керә. Зөһрә куркып кире чигенә, төлкене үтеп киттем дигәндә генә, эре мәһабәт адымнар белән каршысына* аю *килеп чыга.* Зөһрә: «Аю, аю!» — *дип кычкырып җибәрә. Кире чигенә.*)

Аю (*калын, тупас тавыш белән*). Син кем? Минем урманымда, минем рөхсәтемнән башка нишләп йөрисең? (*Килә башлый.*)

Зөһрә (*ялынып*). Аю бабакай, мин адаштырылган бер үги кыз, мин зарарлы кеше түгел. Аю бабакай, тимә син миңа!

Аю туктый, Зөһрәгә юл бирә. Зөһрә чыга башлый, ләкин шулвакыт каршысына тешләрен ыржайткан бүре килә, Зөһрә ачы тавыш белән кычкырып җибәрә: «Абау! Бүре!» — дип кире чигенә, бүренең каршысына аю төшә һәм урманның төрле ягыннан килеп чыккан күбәләкләр дә Зөһрәне бүредән сакларга тырышалар, ләкинерткыч бүре һаман да Зөһрәгә ыргыла.

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урманда яшәүче карчыкның өе. Бүлмә әкияттәгечә җыештырылган. Өстәл, урындыклар, мич үләннәрдән, ботаклардан эшләнгән. Стенада, тәрәзә төбендә төрле чәчәкләр, кош-корт карачкылары. Пәрдә ачылганда, урман карчыгы җеп эрләп утыра. Бераздан, Зөһрәне җитәкләп, аю керә дә Зөһрәгә һәм карчыкка башын иеп чыгып китә. Зөһрә дә аңа башын иеп кала, ләкин, карчыкны күргәч, куркып кире чигенә.

Карчык (*йомшак тавыш белән*). Курыкма, бәбкәм, түрдән уз, мин кешегә тимим.

Шулвакыт ишектән, тәрәзәдән төрле төстәге күбәләкләр очып керәләр һәм Зөһрә тирәсендә әйләнәләр, җырлыйлар.

Күбәләкләр җыры.

Кара урманда
Туып үскән,
Ялгыз калган
Бу карчык.
Хезмәт белән,
Намус белән
Гомер итә
Бу карчык.

Син курыкма
Бу карчыктан,
Бай карчыктан
Зөһрә, Зөһрә.
Хуш хәзергә,
Без китәбез,
Без килербез,
Зөһрә, Зөһрә.
(*Югалалар.*)

Карчык. Син, бәбкәм, кеше аягы басмаган җиргә ничек килеп чыктың?

Зөһрә (*елап*). Үги анам адаштырды мине, әбкәй.

Карчык. Үги анаң адаштырдымы? Анысы булыр. Үги ананың яхшысыннан да козгын тавышы килә, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул, бәбкәм.

Зөһрә. И, әбкәй, инде мин авылыма ничек кайтыйм?..

Карчык. Хәзер кич инде. Бүгенгә миндә генә кунарсың. Иртәгә мин сиңа юл күрсәтермен, кайтырсың, бәбкәм.

Зөһрә. Ярый, рәхмәт, әбкәй. (*Утырырга да, утырмаска да белмичә тора.*)

Карчык. Утыр, кызым, утыр.

Зөһрә (*утыра*). Рәхмәт, әбкәй.

Карчык. Бәбкәм, минем бик мунча керәсем килә иде. Үзем яга алмыйм, бик картайдым.

Зөһрә (*себерке алып, идән себерә башлый*). Утын каян алыйм соң, әбкәй?

Карчык. Лапаста ат-сыер тизәкләре бардыр. Шуларны як.

Зөһрә. Мин коры агачлар да табармын, әбкәй. Ә суны кайдан китерергә?

Карчык. Йорт уртасында җыелган яңгыр суы бардыр, бәбкәм.

Зөһрә. Бу тирәдә чишмә-фәлән дә бардыр әле. Чишмә суы белән юынырсың, әбкәй. (*Мич яныннан чиләкләр алып чыга башлый.*) Ә мунча себеркесе бармы?

Карчык. Корыган чыбык-чабыклар бардыр, шуларны бәйлә дә, чабынырга себерке булыр.

Зөһрә. Юк инде, әбкәй, алай ярамый, урманнан каен себеркесе сындырып алырмын, бик һәйбәтләп аркаңны чабармын. (*Чыгып китә.*)

Карчык (*Зөһрә артыннан карап кала*). Бу чибәр кыз уңган булырга охшый. Ничек кенә сынасам да, күңеле яхшылыкта күренә. (*Пауза.*) Алай да, адәм балаларына бик тиз ышанып булмый. Тагын сынап карарга кирәк булыр. (*Җеп эрли башлый. Пауза.*)

Зөһрә керә, кулында ямь-яшел каен себеркесе.

Зөһрә. Әбкәй, озакламый мунча да өлгерер инде.

Карчык. Рәхмәт, бәбкәм, кул-аягың сызлаусыз булсын. Шулай эшләп үсәргә кирәк. Эше барның, ашы бар, бәбкәм.

Зөһрә (*карчык янына утыра, орчыкка карый*). Орчыгың бик матур икән, әбкәй.

Карчык. Алтын орчык ул, бәбкәм. Бабаңның төсе итеп тотам мин аны. Без, кызым, бабаң белән бик тырышып эшләдек. Безнең урын-җир өстендә ятканны һичбер вакыт кояш күрмәде. Менә сиксән ел инде, кояштан соң ятам, кояштан иртә торам.

Зөһрә. Әбкәй, мине дә шулай эрләргә өйрәтсәнә?

Карчык. Өйрән, бәбкәм. Өнәрле үлмәс, өнәрсез көн күрмәс. (*Өйрәтә.*) Һай, рәхмәт төшкере, бик тиз өйрәнерсең, ахры, син, кулың ябышып тора. Менә шулай, син эрли тор, мин хәзер керермен, бәбкәм! (*Мич артына кереп китә.*)

Зөһрә. Нинди матур орчык! Үзе алтын, ди, бит әле. Әбидән сорасам, миңа бирмәс микән, ә? Бирмәс, бабаңның төсе итеп тотам, ди, бит. Сорамыйм, яхшы түгел. (*Мунча себеркесен ала.*)

Карчык керә.

Карчык. Һай, рәхмәт төшкере, арыдың дамы әллә?

Зөһрә. Юк, әби, ару кая ул, мунча узмасын дип куркам. Сине, әби, мунчага ничек алып барыйм?

Карчык. И, кулымнан тот та типкәли-типкәли илт, шуннан мин үзем барып керермен.

Зөһрә. Ай, карчык кешене алай ярыймыни? (*Карчыкны култыклап алып чыга.*)

Пауза. Бүреләр улый, аюлар акыра. Хәйретдин керә.

Хәйретдин (*каранып*). Әллә нинди йорт бу. Бер дә генә адәм баласы яши торган җиргә охшамаган. Йортында да, өендә дә җан иясе күренми. Урман эченнән тычкан уты кебек кенә булып ут күренгәч килгән идем. Монда да күренми. Ай, кызым, күз нурым! Каян гына табыйм икән сине? Юләрне чәчеп үстермиләр диләр иде, менә чәчми үскән юләр мин инде ул. Үз кызымны үзем урманда адаштырып калдырдым. Явыз хатын сүзенә ышандым. Хәзер менә бик үкенәм дә. Терсәк якын да бит, тешләп булмый. Соң шул. Ул мескен инде, бәлки... (*Яшен сөртә.*) Анасы мәрхүмә актык сулышын алганда: атасы, Хәйретдин, минем бер генә васыятемне үтәсәң иде. Кызымны, Зөһрәне, үзең дә рәнҗетмә, кешеләрдән дә рәнҗеттермә, какмый-сукмый гына үстерсәнә, дигән иде бит ул, мескен! Ә мин аның берләнбер васыятен дә аяк астына салып таптадым. Ай, кызым, Зөһрәкәем! (*Яшен сөртә, бүреләр улавы, аюлар үкерүе ишетелә. Сискәнеп.*) Әнә бүреләр улый, аюлар үкерә, кызым шуларның корбаны була күрмәсен. Чыгыйм, бәлки, коткарырмын.

Чыга. Пауза. Карчыкны култыклап Зөһрә керә.

Карчык. Һай, бәбкәм, ятим карчыкка яхшылык иткәнең өчен зур рәхмәт.

Зөһрә. Әйдә, мунчадан соң ял ит, әбкәй. Аннары тирли-тирли чәй эчәрсең. (*Карчыкны җитәкләп мич артына алып кереп китә, үзе әйләнеп чыга.*) Бигрәк тә кызык карчык инде! Мунчага кергәч: әби, сине ничек итеп чишендерим, дигән идем, (*карчыклар тавышы белән сөйли*) тарткала да йолыккала, бәбкәм, шуннан соң күлмәкләрем үзләре аерылып төшәрләр, ди. Карт кешене алай итәргә ярыймы соң? Әйбәтләп кенә чишендердем үзен. Шуннан соң: әби, сине ничек чабындырыйм, дигән идем, әбием әйтә: себеркенең яфраклы ягыннан тот та сабы белән чап, ди. Менә әкәмәт! Алай итәргә ярыймы

соң! Һәйбәтләп яфраклы ягы белән (*чабу хәрәкәте ясый*) чаптым үзен.

Карчык керә, чәчләре тузган. Зөһрә аны каршы ала, сәкегә утырта.

Зөһрә. Тарагың кайда, әбкәй? Чәчләреңне тарыйк әле.

Карчык. Әнә мичкә сөяп куелган.

Зөһрә (*зур агач тырма алып килә*). Печән җыя торган тырма ич бу!

Карчык. Тара, бәбкәм, шул инде минем тарагым.

Зөһрә. Ярамый, әбкәй. (*Тырманы мич янына алып барып сөйи. Мич куышыннан тарак алып килеп, карчыкның чәчен тарый башлый.*)

Карчык. Зиһенле кыз икәнсең, бәбкәм, рәхмәт!

Зөһрә. Әбкәй, бик тә әтиемне сагындым. Син инде миңа юл гына күрсәтсәнә.

Карчык. Ярый, бәбкәм, кайтырсың. Тик соңгы йомышымны гына үтәсәнә!

Зөһрә. Нәрсә, әбкәй?

Карчык. Минем чормада киптерергә куйган борчакларым бар иде. Шуларны таратып төш әле, кызым. Югыйсә күгәрә башларлар.

Зөһрә. Ярый, әбкәй. (*Чыга.*)

Карчык, чәчен үрә-үрә, мич артына кереп югала.
Бераздан соң Зөһрә керә.

Зөһрә (*халыкка карап*). Ай, белсәгез иде сез әбинең чормасында нәрсәләр барлыгын! Борчакларны таратырга дип менсәм, ни күзем белән күрим, ул алтын, ул алтын! Әбинең борчак дигәннәре алтыннар икән. Алтын борчаклар! Үзе әйткәч, таратып төштем. Әй, шуның, ичмасам, бер учы гына безгә булса, ә?! Мин үги ана кулыннан, әти ярлылыктан котылыр идек.

Йөткерә-йөткерә карчык керә.

Карчык. Әй, бәбкәм, бер аягың җирдә, икенчесе гүрдә булгач, җәй көне дә суык тия икән. (*Төчкерә.*)

Зөһрә. Сәламәт бул, әбкәй. Борчакларың кибә анда. Инде, әбкәй, мине кайтарып кына җибәрсәнә, юл күрсәтсәнә.

Карчык. Бу арада кәефем дә юк, бәбкәм, син инде бер биеп тә күрсәт.

Зөһрә. Ярый, әбкәй.

Карчык чиләк төбе кага, такмак әйтә.

Тыпыр-тыпыр биергә
Тимер идәннәр кирәк.
Синең кебек уңган кызлар
Бу дөньяда бик сирәк.

Зөһрә матур гына итеп бии.

Карчык. Ярый, кызым, мондый өнәрең дә бар икән. Инде әнә мич башында берсе кап-кара, берсе кып-кызыл, берсе ямь-яшел өч кечкенә сандык булыр. Шуларның кызылын алып кил әле.

Зөһрә. Ярый, әбкәй. (*Алып килеп, карчыкка бирә.*)

Карчык. Бәбкәм, менә бу кечкенә сандык сиңа тырышлыгың, туры хезмәтең өчен булсын. Тик син аны өеңә кайтып җитмичә ачма, мөһерен бозма. Менә сиңа аның көмеш ачкычы.

Зөһрә. Рәхмәт, әбкәй, тагын сиксән ел яшә!

Карчык (*елмаеп*). Тагын сиксән ел? Мин инде ашын ашаган, яшен яшәгән кеше. Инде сез, яшьләр яшәгез, тик михнәтсез, газапсыз яшәгез, күңелле, тыныч яшәгез.

Зөһрә. Ярый, әбкәй, рәхмәт. (*Ишеккә бара башлый.*)

Карчык. Юлда сиңа ач бүреләр очраса да, усал кешеләр каршы чыкса да курыкма, көмеш ачкычың белән кызыл сандыгыңа гына сук, шуннан алар үзләре сиңа баш иеп калырлар. Әйдә, хәерле юл, бәбкәм. Мин сиңа юл күрсәтермен.

Зөһрә. Әбкәй, сиңа бик зур рәхмәт.

Чыга башлыйлар. Шулвакыт тәрәзәләрдән, ишектән төрле төстәге күбәләкләр очып керәләр һәм Зөһрәне әйләндереп алалар. Аю кереп Зөһрәне җитәкли, күбәләкләр Зөһрәгә карап җырлыйлар, карчык Зөһрәнең башыннан сыйпап тора.

Ай янында якты йолдыз,
Ай батканчы бат инде,
Кара урманда бик күп йөрдең,
Үз өеңә кайт инде.

Биек тауның башларында
Туры киткән юл булыр,
Исәр җилләр, сайрар кошлар,
Бездән сәлам шул булыр.

Зөһрә, аю һәм күбәләкләр, баш иеп, карчык белән хушлашалар, чыга башлыйлар.

Пәрдә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук өй. Өй эчендә берәү дә юк. Бераздан соң тәрәзәдән **Мәфтуха** карый.

Мәфтуха. Абау, нинди куркыныч!.. Җен карчыгы күренми. Тизрәк кереп, баеп кайтыйм. Шушы өйдер, ахры. (*Керә, карана, һәрбер нәрсәне тотып карый, мич янына сөяп куелган тырмага баса, ул аның башына суга, мич өстендә борчак күреп ашый башлый, кесәсенә тутыра.*) Борчак. Кыздырып та куйганнар. Нинди тәмле! Безнең Зөһрә шушы өйдә баеп кайтты инде. Белсәгез иде, убырлы карчык Зөһрәгә бер матур кызыл сандык биреп җибәргән, ачып карасак, мин сиңа әйтим, эче тулы алтын-көмешләр, асыл күлмәкләр! Әй, әнинең ачуы килде дә соң! Шуннан мине дә куып чыгарды. Бар, күземнән югал, баемыйча кайтып керәсе булма, дип орышты-орышты да куып чыгарды. (*Алтын орчыкны күреп ала.*) Ай-яй, матур орчык! Алтын бит бу, әй! (*Карана.*) Убырлы карчык күрмәс микән? Күрмәс лә. (*Орчыкны кесәсенә сала.*) Менә байый да башладым инде.

Тамагын кыра-кыра, **карчык** керә. Мәфтуха бик тиз сәкегә барып утыра.

Карчык. Кунак бар икән, күрми дә торам. (*Каба янына барып утыра.*) Кызым, дөньяда сиксән ел торам, алай да һич эшләмичә тора алмыйм. Кая әле, кызым, минем алтын орчыгымны алып бир әле.

Мәфтуха (*эзләгән була*). Кая ие ул, әби? Юк ич.

Карчык. Аланлыкта онытып калдырдым микәнни? Шулайдыр әлисә. (*Торып, Мәфтуха янына килә, аңа туп-туры карый. Мәфтуха уңайсызлана, читкә борыла, карчык аның кесәсеннән орчыкны ала да урынына барып утыра, җеп эрли башлый.*) Без капчыкта ятмый, кызым. Кулың озын икән синең, симез кыз.

Мәфтуха. Мин алмаган идем, әби.

Карчык. Алай булгач, ничек синең кесәңә килеп кергән соң ул?

Мәфтуха. Үзе кергәндер, әби.

Карчык. Орчыкмы?

Мәфтуха. Әйе лә-ә...

Карчык. Һәй, алдакчы кыз, орчыкның аягы бармыни? Ярый, аңлашылды, кызый! Минем билләрем бик сызлый. Идәнемне генә себереп бирсәнә.

Мәфтуха. Әбәү, кеше идәнен себереп йөрергә! Мин бит кунак.

Карчык. Әлисә, чәчемне генә тарасана.

Мәфтуха (*халыкка карап*). Фу, туйдырды бу убырлы карчык. (*Карчыкка.*) Тарагың кайда?

Карчык. Әнә мичкә сөялгән.

Мәфтуха (*зур агач тырманы күрсәтә*). Шушымы?

Карчык. Шул, бәбкәм, тарасана.

Мәфтуха тырма белән карчыкның чәчен тарый башлый.

Мәфтуха (*каты итеп тарый-тарый*). Ай-һай, тарагы да тарагы! Әби, тарагың шәп икән.

Карчык. Җитәр, булмаса. Бик каты тарыйсың икән.

Мәфтуха. Үзең куштың ич.

Карчык. Шунда тырма янында тарак та бар иде бит. Ярый, кил, утыр, җеп эрләргә өйрән. Өнәрле үлмәс, өнәрсез көн күрмәс. Бер өнәрең артыр.

Мәфтуха. Ни пычагыма кирәк ул миңа. Мине әнием ашата.

Карчык. Әлисә син, ялкау кыз, чормага менеп, борчакларымны гына таратып төшсәнә.

Мәфтуха (*халыкка карап*). Ичмасам, борчак ашап төшәрмен. (*Карчыкка.*) Ярый, әби, киттем. (*Чыга.*)

Карчык (*әһелдәп-әһелдәп, биленнән зарланып, идән себерә башлый*). Ялкау кыз икән бу, карчык кешенең идәнен дә себереп бирмәде, һай, игелексез нәрсә.

Пауза. Шатланып, Мәфтуха керә.

Мәфтуха. Бик әйбәтләп тараттым, әби. Борчакларың азрак күгәрә дә башлаган булганнар.

Карчык. Шулайдыр шул...

Мәфтуха. Әби, минем өйгә кайтасым килә, син миңа юл гына күрсәт инде.

Карчык. Кайтасың килгәч, ник килдең соң?

Мәфтуха (*аптырап*). Ә, ник дип ... ә мин ятим кыз. Әнием адаштырды.

Карчык. Ай-һай, шулай микән?

Мәфтуха. Беләсең син пычагымны!

Карчык. Бигрәк «ягымлы» сөйләшәсең икән син.

Мәфтуха. Шулай шул.

Карчык. Кайтырсың. Шулай да әйт әле, синең берәр вакыт алдап сөйләшкәнең бармы?

М э ф т у х а. Юк, әби, гомеремдә дә юк.

К а р ч ы к. Иркә кыз! Син минем бер нәрсәмне дә алмадыңмы? Кайберәүләр сорамыйча гына кеше әйберен алгалыйлар.

М э ф т у х а (*куркып, кесәсен капшап куя*). Юк, әби, минем гомеремдә кеше әйберенә кагылганым юк.

К а р ч ы к (*Мәфтухага туры карый*). Син, кызым, каракның бүреге яна, дигәндәй, ни өчендер дерелдисең.

М э ф т у х а (*дерелдәмәскә тырыша, ләкин дерелди-дерелди җавап бирә*). Ю... юкк, әб-би, гомеремдә... дә-дә, әб-ббби...

К а р ч ы к (*йомшак тавыш белән*). Ярый, мин бит сынар өчен генә. Инде син матур иттереп биеп кенә күрсәт тә, аннан соң мин сине өеңә озатырмын.

М э ф т у х а. Анысы була, әби.

Карчык чиләк төбе кага һәм такмак әйтә.

Тыпыр-тыпыр биисең,
Үзең бии белмисең,
Өй башыннан алтын урлап
Баермын дип уйлыйсың.

Мәфтуха ямьсез итеп бии, биегән саен кесәләреннән, чәч толымнарыннан, җиң очларыннан челтерәп алтын-көмешләр коела, аны сизеп, Мәфтуха кинәт туктый.

К а р ч ы к (*чиләкне идәнгә бәреп*). Бу ни бу? Син бит, алама кыз, әле генә гомеремдә алдап сөйләшкәнем юк, кеше әйберенә тигәнем юк, дигән идең. Бу ни хәл бу?

М э ф т у х а (*елый башлый*). Мин ялгыш кына, әби, үзләре кергәннәрдер... Мин алмадым. Моннан соң алдашмам.

К а р ч ы к. Ярар, әнә мич башында ике кечкенә сандык булыр, шуларның кап-карасын алып кил әле. Ямь-яшеленә тимә. Минем күзләрем төсне аермыйлар инде. Карасын алып кил, ишетсен колагың.

М э ф т у х а (*халыкка карап*). Яшелен алма, ди, шунысындадыр инде ул алтыннар. (*Карчыкка.*) Ярый, әби, син әйткәнчә булыр. (*Яшел сандыкны алып килә.*)

К а р ч ы к (*сандыкны әйләндергәләп*). Синең тәүбәң тукран тәүбәсе кебек кенә икән. Яшелен алып килгәнсең ич.

М э ф т у х а (*елый*). Үзе минем күзләрем күрми диде дә...

К а р ч ы к. Дисә соң... Болай булсаң, син ата-анаңа да игелек күрсәтмәссең, кешеләргә дә файдаң тимәс.

М э ф т у х а. Мин дә төсләрне яхшы аера алмыйм шул. Әни мине, тавык күз, ди торган иде.

Карчык. Артыгы белән аңлашылды, озын куллы кыз. Бар, үзеңә тиешле кара сандыкны алып кил. (*Мәфтуха алып килә. Карчык аны алып, кире Мәфтухага бирә.*) Дөньяда, кызым, һәркем үз хезмәтенә күрә җимешен татырга, ни чәчсә, шуны урырга тиеш. Менә синең өлешеңә чыккан көмешең дә шул кара сандык инде. Монысы анның бакыр ачкычы.

Мәфтуха (*ала*). Ярый, әби.

Карчык. Тик, ишетсен колагың, өеңә кайтып җитмичә ачып карыйсы булма, мөһерен бозма.

Мәфтуха. Ярый ла инде. (*Чыга башлый, карчык аны ишек төбендә куып җитә.*)

Карчык. Актык сүз шул сиңа, иркә кыз, ялкау кыз, алдакчы кыз, озын куллы кыз, моннан соң кеше әйберенә тимәскә, алдап сөйләшмәскә вәгъдә бирәсеңме?

Мәфтуха. Бирәм, әби, бер түгел, мең вәгъдә бирәм.

Карчык. Анысы яхшы, симез кыз, тик берәр җиреңдә минем алтын кисәкләрем калмагандыр ич.

Мәфтуха. Юю-кк, әб-би, юкк...

Карчык (*Мәфтуханың башыннан сыйпап, йомшак тавыш белән*). Менә рәхмәт, инде алдашмый да башлаган ул. (*Мәфтуханың башын сыйпаган саен, чәч араларыннан учлап-учлап вак алтын тәңкәләр ала һәм аларны сәкегә ташлый.*) Бу ни бу?.. Алтыннар! Ах сине, алдакчы кыз!..

Мәфтуха (*елый*). Ялгыш кына, әби, үзләре кергәннәр, үзләре... Моннан соң гомеремдә дә...

Карчык (*анның сүзен бүлеп*). Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә ул, алдакчы кыз.

Пәрдә.

Сораулар һәм бирем.

1. Зөһрә һәрвакыт әби кушканның киресен эшли. Ни өчен?
2. Әби сездә нинди тәэсир калдырды? Ул нинди кеше?
3. Юлда усал бүреләрдән, аюлардан котылу өчен, Зөһрәгә әби нишләргә куша? Табигать Зөһрәгә нинди мөнәсәбәт күрсәтә?
4. Әбинең кеше «ни чәчсә, шуны урырга тиеш» дигән сүзен сез ничек аңладыгыз?
5. Зөһрәнең этисенә карата карашыгыз үзгәрмәдеме?
6. *Кулың ябышып тора, мунча узмасын* сүзләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.

орчык — җеп эрли торган эш коралы (веретено)
өнәрле — һөнәрле, эш белү, ягъни чигү, тегү һәм башка һөнәрләргә ия булу
мәрхүм — үлгән кешене әйтәләр
рәнҗеттерми — кыерсыттырмый
васыять — теләкләрен, ниятләрен әйтеп калдыру
зиһенле — аңлы
чорма — өйнең түбә асты
михнәтсез — авырлык күрмичә, кыенлык күрмичә

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге бүлмә. Пәрдә ачылганда, Зөһрә сәке өстендә карчык биргән сандыкны актара. Атасы идәндә камыт төзәтә.

Зөһрә (*сандыктан бер аксыл күлмәк алып*). Әти, хикмәтле сандыктан бер асыл күлмәк чыкты, ул сиңа ярамас микән? (*Атасына суза*).

Хәйретдин (*елмая, килә, кулын суза, тиз генә кире ала*). Мондый асыл күлмәкне, кызым, кулны бик һәйбәтләп сабынлап юмыйча тотарга ярамас. (*Комган алып кулын юа.*)

Зөһрә. Дөрестән дә, әти.

Хәйретдин. Я, инде, хәзер киеп карыйк. (*Җиңнәрен, иңнәрен үлчи дә кия башлый.*) Ата-баба күрмәгән асыл күлмәкне киик, килешер микән?

Зөһрә. Бик килешер, әти, без кемнән ким?

Хәйретдин. Агач күрке — яфрак, адәм күрке — чүпрәк, дип белми әйтмәгәннәр. Хәзер атаңны таныйсыңмы, кызым?

Зөһрә (*атасын кочаклап ала*). Нинди матур булдың, әти!

Хәйретдин (*кызын кат-кат үбеп*). Без, кызым, кешедән бер дә ким түгел. Тик менә бәхет юклык кына, ярлылык кына...

Зөһрә (*тагын бер күлмәк алып*). Бу күлмәкне, рәхмәт төшкән әбкәй, миңа дип биргән, ахры (*кия*).

Хәйретдин. Үзеңә үлчәп теккән кук.

Зөһрә. Алтыннарын кая куеп бетерербез икән, әти?

Хәйретдин. Безнең ише ярлының тишек-тошыгы күп була аның. Урын табылыр, кызым. Атсыз-канатсыз йөреп, азмы иза чиктек. Дилбегәне какмыйча ук (*дилбегә кагу хәрәкәте ясый, сызгырып җибәрә*), кош кебек очып торган бер ат алырбыз. Залимә золымнарыннан котылырбыз.

Зөһрә. Ай, нинди әйбәт булыр!

Залимә керә.

Залимә. Һе, болар аталы-кызлы мал бүләләр икән. (*Вак-вак атлап йөренә.*)

Хәйретдин. Анасы, кара әле, төшкә дә кермәгән асыл күлмәкне, иллегә җиткәч, Хәйретдинең дә киеп җибәрде бит! Шәпме, ә?

Залимә. Фу, дөягә камыт кигергән күк инде. (*Аскы иренен чыгарып.*) Һе, әни кешегә бер дә өлеш юкмыни?

Хәйретдин. Чыннан да, кызым Зөһрә, хикмәтле сандыгыңнан кара әле, анаңа да бирәр нәрсә юкмы?

Зөһрә. Карыйм, әти. (*Актара.*) Юк шул. Монда бар да миңа яраклык та, аннан ирләр әйбере генә.

Залимә. Кит аннан, хәчтерүш. Ник булмасын ди! (*Җилтерәтеп килеп, сандыкны алмакчы була, сандык сәке буйлап кузгалып китә, Залимә куркып кычкырып җибәрә.*) Әстәгъфирулла, кызың сихерче булып кайткан. Тфү, тфү...

Хәйретдин. Зөһрә ул андый кыз түгел, анасы. (*Елмаеп.*) Үги анага үги кыздан бүләк тиеш түгел, күрәсең.

Зөһрә. Әти, мин әнигә күлмәклек алырга алтын бирәм. (*Бер уч акча бирә, Залимә алмаган була.*)

Залимә. Бик исем китте, миңа кеше акчасы кирәкми. Менә үз кызым дөнья хәтле алтын алып кайтыр әле.

Хәйретдин. Ал инде, ал. Баланың кулын кире какма.

Залимә. Бик исем китте, бик исем китте. (*Ала.*) Бәлеш! Кара әле, атасы, әллә нишләп алтыннар каралып китте!

Хәйретдин. Ә, булмас!.. (*Карыйлар.*) Хикмәти Ходa, чыннан да каралганнар. Кая, кызым, миңа да биреп кара әле.

Зөһрә (*бирә.*) Мә, әти. (*Карыйлар.*)

Хәйретдин. Хикмәт!

Зөһрә. Каралмады!

Залимә. Әллә нинди сихерле акчалар. Тфү, тфү! (*Лач-лач итеп изүенә төкерә.*)

Хәйретдин. Аңлашылды...

Залимә. Нәрсә аңлашылды?..

Хәйретдин. Саф алтыннар кара эчле, усал кеше кулында карала торганнардыр, күрәсең.

Залимә. Пычагымны беләсең син. Кызың әллә нинди сихерче булып кайткан да... Менә мин бөтен хәрәм әйберләрегезне мичкә тыгыйм әле. (*Килеп, сандыкны алмакчы була, сандык кузгала башлый. Залимә, куркып, читкә тайпыла, ачы тавыш белән кычкырып җибәрә.*)

З а л и м ә. Абау, әстәгъфирулла, җен эше бу, җен эше. Тфү, тфү! (*Изүенә төкерә-төкерә чыгып китә.*)

Хәйретдин белән Зөһрә аптырашып калалар.

Х ә й р е т д и н. Бер дә исең китмәсен, кызым, төлке дә, йөзем җимешенә буе җитмәгәч, пешмәгән икән, дип әйткән, ди. Үги анаң да шулай булып калды. Тукта әле, нәрсә эшләп йөри икән? Берәр этлек уйламасын тагын. Мин чыгып карыйм әле (*чыга*).

Зөһрә, сандыктан бик матур яулык алып ябына да, җырлый-җырлый, өй җыештыра башлый.

Өй түрендәге талларны
Тирбәтә торган идем,
Моңлы бала нинди була,
Дип әйтә торган идем.

З а л и м ә керә.

З а л и м ә. Фәрештәләр качырып, нәрсә уларга тотындың? Үз башыңа булгыры!

З ө һ р ә. Җырлыйсым килгәч, ни эшлим соң? Җитәр инде, унөч ел буе елап яшәдем. Инде җырларга да ярый торгандыр.

З а л и м ә. Улый-улый, кызым Мәфтуханың башына җиттең инде.

Х ә й р е т д и н керә.

Х ә й р е т д и н. Мәфтуханың башына җитүче син үзең ул. Син бит аны, баемыйча кайтма, дип комсызланып куып чыгарып җибәрдең.

З а л и м ә (*Хәйретдингә карап*). Ат аягын дагалаганда, бака ботын кыстыра, дигәндәй, син нәрсә кысыласың?

Ишек артыннан кәрлә көчек өргән тавыш ишетелә, бар да аптырыйлар.

К ө ч е к. Ләң, ләң, ләң, ләң, баерга киткән Мәфтуха түтәй бөлеп кайта түгелме? Усал, ялкау, симез түтәй бөлеп кайта түгелме, ләң, ләң?..

Залимә тәрәзәдән башын тыгып карый.

З а л и м ә. Һәй, кадалгыры, кабахәт эт, бирермен мин сиңа, бөлеп кайтып киләне, баеп кайта диген! (*Уклау алып пырылдап чыгып китә, ишектә Мәфтуха белән бәрелешә.*)

М ә ф т у х а (*сүзен көчкә бүлеп-бүлеп сөйли*). Ай, харап булдым, әни! (*Төтеннәре чыгып торган кечкенә кара сандыкны идәнгә ташлый.*)

З а л и м ә. Ни булды, кызым?

М ә ф т у х а. Урмандагы карчыкның алтын орчыгын, алтыннарын сорамыйча гына алган идем, сүзен тыңламаган идем, алдашкан идем...

Х ә й р е т д и н. Кеше әйберенә тимиләр шул, эшләп яшиләр аны.

З ө һ р ә. Алдашырга да ярамый.

З а л и м ә (*Зөһрәгә*). Син кысылма әле, шуннан, кызым?

М ә ф т у х а. Өйгә кайтканда, теге әби миңа әнә шул кара сандыкны бирде, өеңә кайтмыйча ачма, диде.

Х ә й р е т д и н. Син тагын карыштың инде.

М ә ф т у х а. Эчендә алтыннары бардыр дип юлда ачкан идем. Ай, хәлем бетә, әллә нинди кап-кара төтен чыкты да, тыным кысыла башлады. Ай, башым әйләнә!..

З а л и м ә (*сандыкны алмакчы була*). Инде сихере беткәндер, кая, алтыннарын алыйк та чыгарып ташлыйк үзен. (*Сандыкны алуга хәле бетә башлый, икесе дә чайкалып торалар да егыла башлыйлар. Хәйретдин белән Зөһрә аларны сәкегә яткыралар.*)

Х ә й р е т д и н (*халыкка һәм Залимә белән Мәфтухага* карап). Ни чәчсәң, шуны урырсың, дип белми әйтмәгәннәр шул бабайлар.

Шулвакыт тәрәзәләрдән к ү б ә л ә к л ә р очып керәләр. Зөһрәне әйләндереп алалар һәм аны мактый-мактый җырлыйлар. Зөһрәгә чәчәк сузалар.

Ал чәчәк кадыйк әле,
Гөл чәчәк кадыйк әле,
Уңган, булган кыз икәнсең,
Сиңа дан җырлыйк әле.

Ал бәйлик беләгеңә,
Гөл бәйлик беләгеңә,
Синең кебек булса кызлар,
Ирешер теләгенә.

Бик каты ишек дөбердәтәләр, барысы да куркышып китәләр. Зөһрә ишек ача, а ю керә, баш иеп исәнләшә. Зөһрә: «Аю бабакай, түрдән уз, кунак булырсың», — дип чакыра, күрешәләр. Зөһрә күбәләкләргә карап җырлый башлый. Җырның азагына бар да кушылалар.

Сандугачлар сайрый ояда,
Оялары да гынай пыяла,
Сандугачлар күк сайрашып
Яшик әле дөньяда.

Пәрдә.

Сорауләр һәм бирем.

1. Зөһрәнең сандыгында нләр була?
2. Алтын акча Залимә кулында ни өчен карала дип уйлыйсыз?
3. Мәфтуханың әнисен автор ни өчен Залимә дип атый?
4. Усаллык (залимлек) нинди нәтиҗәләргә китерә?
5. Әсәрдә җырларның әһәмияте турында сөйләгез.

асыл — яхшы, әйбәт, затлы
хикмәтле — серле
хәчтерүш — булдыксыз, уңмаган
сихерче — сихерләү сәләте булган кеше (колдун)
бәлү — ярлылану, хәерчеләнү

«Үги кыз» әсәрен йомгаклау өчен сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрдә катнашучыларны санагыз. Шуларның кайсылары сезгә ошады? Ни өчен?

2. Матур булу өчен тышкы кыяфәт кенә җитәме? Сез ничек уйлыйсыз? Кешеләрдәге затлы сыйфатларны әсәрдән чыгып ачыклагыз.

3. Әсәрдә табигать кешегә кайбер очракта теләктәшлек итә, кайбер очракта куркыныч булып та әверелә, ни өчен?

4. «Кешегә баз казыма, үзең төшәрсең» дигән мәкальнең мәгънәсен аңлатыгыз. Әсәрдә бу ничек раслана?

5. Әсәрдәге мәкальләрне табып укыгыз һәм мәгънәләрен аңлатыгыз.

6. А. Әхмәтнең тагын нинди әкиятләрен укыганыгыз бар?

Портрет

Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен, йөзен, киемен, бизәнү рәвешен сурәтләү **портрет** дип атала.

Әсәрдә кешенең холык үзенчәлекләрен, күңел дөньясын сурәтләүне геройның **эчке портреты** дип әйтәләр.

Характеристика

Геройның дөньяга карашын, кешеләргә, хезмәткә мөнәсәбәтен, ихтыярын, сәләтен, хис-тойгыларын, омтылышларын, гореф-гадәтләрен тасвирлауны **характеристика** дип атыйбыз.

Драма әсәре

«Үги кыз» әсәрен без моңа кадәр өйрәнгән әсәрләр белән чагыштырып карасак, аның *диалоглардан,* ягъни кара-каршы сөйләшүләрдән торганын күрербез. Һәм ул сәхнәдә уйнау өчен язылган. Димәк, геройларның үзара сөйләшүләре рәвешендә булган һәм сәхнәдә башкарылу өчен язылган әсәр **драма әсәре** дип атала.

Драма әсәренең башында ук катнашучылар санап чыгыла. Хикәядә андый исемлек булмый. Бу исемлектә вакыйгаларда катнашучыларга кыска гына аңлатмалар яки геройларның тышкы кыяфәте турында тасвирлаулар бирелү мөмкин.

Драма әсәрендә һәр күренеш алдыннан вакыйганың барган урыны, аерым катнашучыларның сүзләрне ничек әйтергә, нинди хәрәкәтләр ясарга тиешлеге турында аңлатмалар бирелә. Ул аңлатмаларны *ремарка* дип атыйлар.

Муса Җәлил

(1906—1944)

Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

Муса Җәлил

Бу исемне телгә алуга, күз алдына ниндидер гадәттән тыш кеше килгәндәй була. Ул — ялкынлы шигырьләр язган шагыйрь дә, илнең азатлыгы өчен курку белмәс көрәшче дә, үлемне ирләрчә батыр каршылаган каһарман да.

Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елда Оренбург өлкәсе Мостафа авылында туа. Ул кече яшьтән үк зирәк һәм хыялга бай бала була. Күп укый, һәр нәрсәне белергә тырыша. Оста итеп мандолинада уйнарга өйрәнә. Рәсем ясарга ярата.

Муса Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Җәйне туган авылында үткәрә. Табигать матурлыгы аның күңелен үзенә тарта, соңыннан ул бу күзәтүләрен рәсем итеп төшерә.

Муса 10—11 яшьләрендә шигырьләр дә язып карый. Ләкин алар югала. Матбугатта иң беренче булып унөч яшендә язылган «Бәхет» шигыре (1919) басыла.

1922 елда ул Казанга килә һәм 1923—1925 елларда Казан педагогия институтының рабфагында укый.

1925 елда Җәлилнең «Барабыз» исемле беренче китабы чыга. «Иптәшкә» (1929) дигән шигырь җыентыгы аның шагыйрь булып җитлегеп килүен тагын бер тапкыр раслый.

Ул 1931 елда Мәскәү университетының әдәбият бүлеген тәмамлый. 1939 елда Җәлилне Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Сугышка кадәрге елларда шагыйрь

бик күп шигырьләр, җырлар, «Хат ташучы» поэмасын, «Алтынчәч», «Илдар» исемле опера либреттоларын яза.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул үзен фронтка җибәрүләрен сорый. Аның үтенече канәгатьләндерелә. Ләкин 1942 елның җәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Әнә шулай аның лагерь тормышы башлана. Шагыйрь әсирлектә дә көрәшне туктатмый. Яшерен оешмага керә, аның җитәкчеләреннән берсе була, бик күп әсирләр белән лагерьдан качу һәм партизаннарга барып кушылу ниятен тормышка ашырырга уйлый. Бер хыянәтче аларның серләрен фашистларга хәбәр итә. Шуннан соң Җәлилне һәм аның иптәшләрен Берлиндагы Моабит төрмәсенә ябалар. Шагыйрь анда да туган иленә тугрылыклы булып кала. Искиткеч рухи ныклык күрсәтә. Үлем җәзасы көтеп торганда да, туган илгә, халыкка тирән мәхәббәт белән сугарылган, фашистларга көчле нәфрәтен белдергән шигырьләр язып, аларны үзе ясаган кечкенә дәфтәрләргә теркәп бара. Җәлилнең әсирлектә язган шигырьләре бөтен дөньяга билгеле. Татарстанга аның ике дәфтәре кайтты. Аларны бөтен дөньяда «Моабит дәфтәрләре» дигән исем белән беләләр. Беренче дәфтәренә Муса Җәлилнең алтмыш шигыре теркәлгән һәм дәфтәрнең соңгы битенә васыять язылган: «Моны язды татарның билгеле шагыйре М. Җәлил. 1942 елны сугышка килде һәм әсир төште. Әсирлектә күп газаплар чигеп, сәяси яшерен оешмага катнашуда гаепләнеп кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлкем, аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра. Шуның өчен 115 енең 60 ын гына булса да күчереп калдырырга тырышты. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, акка күчер, сакла һәм сугыштан соң, Казанга хәбәр итеп, үлгән шагыйрьнең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул.

1943, декабрь».

Бу дәфтәрне 1944 елның февралендә Тегель төрмәсеннән Габбас Шәрипов исемле әсир алып чыга. Аннан ул аны Нигъмәт Терегулов дигән кешегә тапшыра. 1946 елны Н. Терегулов дәфтәрне Татарстан Язучылар берлегенә китереп бирә.

Икенче дәфтәрне М. Җәлил саклар өчен Бельгия партизаны Андре Тиммерманска биргән. Әлеге намуслы кеше 1947 елда аларны безнең илебезгә җибәрә.

Җәлилнең өченче дәфтәре дә булган дигән фикер бар. Ләкин әле ул табылмады, аны эзләү дәвам итә.

1944 елның 25 августында фашистлар М. Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен җәзалыйлар. Җәлилчеләр соңгы сәгатьләрендә дөнья белән кулларына мөселманнарның изге китабы — Коръән тотып хушлашалар.

Шагыйрьне үтерсәләр дә, фашистлар аның ялкынлы җырларын, көчле рухын юк итә алмадылар. Муса Җәлил илгә җыр булып кайтты.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язына.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Аның исемен халкыбыз мәңгеләштерде. Казандагы Татар дәүләт опера һәм балет академия театры Муса Җәлил исемен йөртә. Башкалабызның үзәгендә аңа һәйкәл куелды. Ул яшәгән фатирда музей ачылды. Татарстанда Җәлил исемендәге бистә бар. Муса Җәлилгә багышлап романнар, поэмалар, опера, җырлар, сынлы сәнгать әсәрләре иҗат ителде.

Җәлил исемен илебез халкы горурлык белән искә ала. Һәр буын аны йөрәгендә саклый. Аның көрәше һәм эшчәнлеге — күпләр өчен кыюлык һәм батырлык үрнәге.

Сораулар һәм биремнәр.

1. «Җырлап килдем тормыш язына» дигән сүзләр Җәлилнең кайсы шигыреннән алынган? Шигырьне аның тормыш юлы белән бәйләп аңлатыгыз.
2. Аның сугыштагы батырлыклары турында нәрсәләр беләсез?
3. М. Җәлилнең беренче һәм икенче «Моабит дәфтәре» турында сөйләгез. Алар кайчан илгә кайта? Анда нинди шигырьләр кергән?
4. Җәлил һәм аның иптәшләре, Коръән тотып, яшәү белән хушлашалар. Сез Коръән турында нәрсәләр беләсез?

яңрар — яңгырар
либретто — зур музыкаль әсәрнең (опера, оперетта һ.б.) әдәби тексты
һәйкәл — памятник
фатир — квартира

Чәчәкләр

Барыгыз болынга, балалар!
Йөгерегез, уйнагыз, көлегез!
Елмайсын күреп шат аналар,
Юансын боеккан күңелегез.

Болында күп матур чәчәкләр,
Барсы да татлы хуш ислеләр.
Нәркисләр, сөмбелләр һәм мәкләр
Нәкъ сезнең ирнегез төслеләр.

Җил көйләп тирбәтә аларны,
Иркәли кояшның нурлары.
Алар бит изге Җир-ананың
Сөекле кызлары, уллары.

Бу җирдә күп булды сугышлар,
Янгыннар, явымнар, давыллар,
Киселде күп батыр тормышлар,
Янды зур калалар, авыллар.

Ил өчен барды бу зур көрәш
Давыллы, дарылы елларда.
Сеңде бу туфракка күпме яшь,
Күпме кан тамды бу кырларга.

Шул каннар һәм яшьләр аркылы,
Ил бөек җиңүгә иреште.
Яз килде, дулкынлы, ялкынлы,
Чәчәккә төренде җир өсте.

Бу гөлләр шытты Җир-ананың
Яралы йөрәге түрендә.
Ничек ул йөрәкнең янганын
Мин күрәм аның һәр гөлендә.

Җыегыз, балалар, сез җирнең
Бу нәфис һәм иркә гөлләрен.
Китерегез данлыклы хөр илнең,
Тәбрикләп, шатлыклы көннәрен.

Сезнең дә, бәлки, бу сугышта
Үлгәндер атагыз, агагыз,
Хәтерләп сезне соң сулышта...
Һәм бардыр йөрәктә ярагыз.

Сез назлап үбегез гөлләрне,
Хуш истән күңелегез ачылсын.
Җир бирде сезгә шат көннәрне,
Йотып тир, кан һәм яшь тамчысын.

Балалар, сез гөлләр үзегез,
Чыктыгыз калкып җир карныннан
Һәм чәчәк аттыгыз, үстегез
Атагыз, агагыз каныннан.

Сез безгә шулкадәр кадерле,
Шулкадәр ягымлы, сөйкемле!
Ал таңы алдагы дәвернең
Йөзегездә чагыладыр шикелле.

Чәчәкләр, үсегез, чәчәкләр,
Дәрт биреп безнең шат күңелгә.
Сезгә бу шатлыклар, рәхәтләр
Бит җиңеп алынган гомергә.

Сораулар.

1. Шагыйрь бу шигырьдә балаларны нәрсәләр белән чагыштыра? Балалар белән чәчәкләр арасында нинди уртак якларны күрә?
2. «Ил өчен барды бу зур көрәш», — ди шагыйрь. Ул нинди зур көрәш турында яза?
3. «Җир-ананың йөрәге яралы» дигәнне сез ничек аңлыйсыз?
4. «Киселде күп батыр тормышлар,
Янды зур калалар, авыллар»
дигән юлларны укыгач, сезнең күз алдына нинди күренешләр килде? «Киселде» сүзен тагын нинди сүз белән алыштырып була?
5. Ни өчен шигырь «Чәчәкләр» дип атала?
6. Сезнең якыннарыгыздан кемнәр сугышта катнашкан? Алар турында ниләр беләсез?

дәвер — чор, гасыр
юансын — күңеле күтәрелсен
сөмбел — гиацинт
нәркис — нарцисс
йөрәк түрендә — күңел түрендә, һәрвакыт күңелдә

Чагыштыру

Язучы геройларның кичерешләрен тирәнрәк ачу, вакыйгаларны, күренешләрне, әйберләрне тулырак күрсәтү максаты белән төрле сурәтләү чараларыннан файдалана. Шундыйларның берсе — чагыштыру.

Бер әйберне яки күренешне икенче бер әйбер яки күренешкә охшатып, алардагы уртак якларны күрсәтүгә **чагыштыру** диләр. Чагыштырулар кешене, вакыйганы яки сурәтләнгән әйберне тагын да ачыграк һәм җанлырак итеп тасвирларга мөмкинлек бирә, укучыларның күзаллавын көчәйтергә ярдәм итә.

Чагыштыруларга мисаллар:

Җирне анага тиңләү, нәркисләрне иреннәргә охшату, балаларны гөлләр сүзе белән аңлату һ. б.

Сынландыру

Җанлы әйберләрдә була торган үзенчәлекләрне җансыз әйберләргә, табигать күренешләренә күчереп сурәтләүне **сынландыру** дип атыйлар.

Сынландыруларга мисаллар:

Җил тирбәтә, кояш нуры иркәли, ялкынлы җирнең йөрәге яралы, янган йөрәк, җир кан бирде, җир йотты.

КЫЗЫЛ РОМАШКА

Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,
Күзгә-күз караштылар.

Назлады җил аларны
Тибрәтеп ак чукларын,
Таң сипте өсләренә
Хуш исле саф чыкларын.

Чәчкәләр, кәефләнеп,
Җай гына селкенделәр
Һәм кинәт шунда гаҗәп
Бер яңа хәл күрделәр.

Ерак түгел моңаеп
Утыра ромашка кызы,
Тик чуклары ак түгел,
Кан шикелле кып-кызыл.

Ромашкалар бар да ак,
Аерылмый бер-береннән;
Ничек болай берүзе
Ул кызылдан киенгән?

Әйттеләр: «Син, сеңелкәй,
Ник үзгәрдең? Нишләдең?
Нигә кызыл чукларың?
Нидән алсу төсләрең?»

Әйтте кызыл ромашка:
«Төнлә минем яныма
Ятып батыр сугышчы
Атты дошманнарына.

Ул берүзе сугышты
Унбиш укчыга каршы:
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кулбашы.

Аның батыр ал каны
Тамды минем чукларга.
Минем кызыл күлмәгем
Бик охшады Чулпанга.

Егет китте, мин калдым
Канын саклап чугымда,
Көн дә, аны сагынып,
Балкыйм мин таң нурында».

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьне сәнгатьле итеп, рольләргә бүлеп укыгыз.
2. Шигырь вакыйга ягыннан ничә өлештән тора?
3. Ак чәчәкләр ни өчен гаҗәпләнәләр? Кызыл чәчәк нигә моңая?
4. Кызыл ромашка батыр сугышчыны (егетне) ничек итеп сурәтли? Бу чәчәкнең төп сыйфаты нидә?
5. Шигырьдәге сынландыруларны табыгыз. Шагыйрь ни өчен сынландыру алымын куллана, бу аңа ни өчен кирәк?

назлады — иркәләде, яратты
чуклары — таҗ яфракчыклары (лепестки)
чык — иртән үләннәрнең дымлануы, аларга кунган тамчылар
кәефләнеп — шат күңел белән
моңаеп — күңелсезләнеп, кәефсезләнеп
җай гына — уңай гына

«Муса Җәлилнең музей-фатирында» темасына сөйләшү өчен сораулар*

1. Татарстанда Җәлил исеме белән бәйле урыннар турында сөйләгез.

2. Каһарман шагыйрьнең мемориаль музей-фатиры кайчан ачылды?

3. Музейда нинди экспонатлар бар?

4. Муса Җәлил бюстының авторы кем?

5. Музейда Муса Җәлил шигырьләре басылган нинди китаплар бар?

6. Музейда күргәннәрегез һәм үзегез белгәннәр буенча, Муса Җәлилнең дөньяда иң танылган шагыйрьләрнең берсе булуы турында сөйләгез.

---

* Музейда булмаганнар, читтә яшәүче укучылар шагыйрьгә багышлап башка темага сөйләшү уздыра.

Зөләйха Хисмәтуллина
(1922—1994)

Халык күңелендә югалмас эз калдырган шәхесләр байтак. Шуларның берсе — Зөләйха Гатаулла кызы Хисмәтуллина.

1922 елның 22 ноябрендә Казан шәһәрендә эшче гаиләсендә туып үскән бу кыз баланың сәнгатькә килү юлы беренче карашка очраклы гына булган кебек. Тавышының матурлыгын бәяләп, музыка белгечләре аны 1939 елда радиокомитетка җыр ансамбленә эшкә чакыралар. Хор җитәкчесе аңа «Һаваларда йолдыз», «Кошлар кебек» исемле халык көйләрен башлап җырлауны тапшыра.

Көчле, саф, матур тавышы Зөләйханың зур җырчы булачагына өмет уята. Радиокомитетның музыка редакторы композитор Җәүдәт Фәйзи Зөләйхага музыка училищесына укырга керергә киңәш итә. Кыз 1940 елда Ленинград консерваториясе каршындагы музыка училищесының җыр бүлегенә укырга керә. Сугыш вакытында укуын Казан музыка училищесында дәвам иттерә. Өченче курста укыганда (1945), ул Н. Җиһановның «Түләк һәм Сусылу» операсында Аембикә образын тудыра. Шулай итеп, аның язмышы Татар дәүләт опера һәм балет академия театры белән бәйләнә. 1945 елда Казанда консерватория ачылгач, ул шушы уку йортына укырга керә. Шул ук вакытта театрда эшләвен дә дәвам иттерә.

Тырышлык, өлгерлек, түземлелек куанычлы нәтиҗәләргә китерә. 1949 елда Мәскәүдә яшь опера җырчылары конкурсында, «Евгений Онегин» операсыннан Татьяна арияләрен җырлап, Зөләйха Хисмәтуллина бүләккә лаек була.

Татар композиторлары үз әсәрләрендәге аерым партияләрне Зөләйханың җырчы буларак мөмкинлекләрен, тавыш

үзенчәлекләрен күздә тотып язалар. Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсында — Каракаш, Хөснул Вәлиуллинның «Самат»ында — Әлфия, «Дим буенда» әсәрендә — Фәридә, Җәүдәт Фәйзинең «Идел буенда» музыкаль комедиясендә Рәмзия образлары З. Хисмәтуллинаның зур иҗат уңышлары булып саналалар. Салих Сәйдәшев 1947 елда «Наемщик» музыкаль драмасын яңадан эшли. Зөбәрҗәтнең драматик кичерешләрен З. Хисмәтуллина искиткеч зур осталык белән җырлый. Җырчы сәхнәдә илледән артык образ иҗат итә. Бер үк вакытта ул концертларда чыгыш ясавын да дәвам иттерә. Аның башкаруында татар халык көйләре нәфис, матур яңгырый. Ул бигрәк тә романслар, лирик җырлар башкару остасы иде.

Зөләйха Хисмәтуллина алтмышынчы елларда эшчәнлегенең тагын бер юнәлешен башлап җибәрә. Казан дәүләт консерваториясендә җырчыларны укыта башлый. Аның җыр сәнгатендә ирешкән уңышлары өчен ул дәүләт тарафыннан югары бәяләнде.

Шагыйрь Әнвәр Давыдов Зөләйха Хисмәтуллинага багышлап мондый шигырь юллары язган иде:

Сокланамын Сездә мин шушыңа,
Ике агым бер ташкынга кушыла.
Сугыш күптән түгел беткән еллар...
Тын авылда Сезне тыңладым.
Тол аналар үксеп тыңладылар
Мадам Баттерфляй моңнарын.
Ераклардан килгән моң агымын
Тоташтырасыз яңа чорга Сез.
Моңнәр Сезне тыңлый дулкынланып,
Я, Зөләйха, тагын җырлагыз...

Казан дәүләт консерваториясе профессоры, Россия Федерациясенең һәм Татарстанның халык артисткасы Зөләйха Хисмәтуллина 1994 елда Казан шәһәрендә вафат булды.

Сораулар һәм биремнәр.

1. З. Хисмәтуллина сәнгатькә нинди юллар аша килә? Аның иҗат баскычлары турында сөйләгез.
2. Аның катнашуында куелган спектакльләрнең исемнәрен әйтегез.
3. Җырчының радио һәм телевидение аша чыгышларын тыңлаганыгыз бармы, аеруча кайсы җырларын яратасыз?

4. З. Хисмәтуллина сәнгатьтә, укыту өлкәсендә нинди биеклекләргә ирешкән?
5. Шундый күренекле җырчылардан тагын кемнәрне беләсез?
6. Зөләйха Хисмәтуллина язмаларында җырлар тыңлагыз.

өмет — берәр теләгән нәрсәнең киләчәктә булуын ышанып көтү
консерватория — югары музыка уку йорты
романс — җырлау өчен язылган кечкенә генә лирик әсәр
мадам Баттерфляй — итальян композиторы Д. Пуччини иҗат иткән «Чио-Чио-сан» операсының героинясы

Азат Аббасов

(1925)

Татар җыр сәнгате тарихында тирән эз калдырган талант ияләренең берсе, һичшиксез, Азат Зиннәт улы Аббасов. Ул — Татарстанның һәм СССРның халык артисты дигән мактаулы исемнәргә лаек булган җырчы, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының күренекле артисты.

Азат Аббасов 1925 елда Алабуга шәһәрендә туган. Казан шәһәренең 2 нче урта мәктәбендә җиде сыйныф тәмамлагач, авиация техникумында укый, заводта конструктор була. Сугыш елларында җитештерү өлкәсендә эшли.

Замандашларының сөйләвенә караганда, аның әтисе матур итеп җырлый торган кеше була, аларның өйләренә гаиләнең дусты мәшһүр композитор Салих Сәйдәшев килеп йөри. Бервакыт Азат әтисе һәм Сәйдәшев алдында җырлап күрсәтә. Салих абыйлары унтугыз яшьлек бу егетнең җырлавына таң кала һәм аңа җырчы һөнәрен сайларга киңәш итә. Әлбәттә, кеше кемнеңдер киңәше белән генә җырчы була алмый. Әмма Азатның күңелендә мондый теләк күптәннән йөри, композиторның бу сүзләре аның омтылышын тагын да ныгыта гына. Ул Мәскәү консерваториясенең милли опера студиясенә кабул ителә. Аны уңышлы тәмамлаганнан соң, Азат Аббасов бөтен гомерен һәм талантын татар опера сәнгатенә багышлый. Ул биредә бик күп партияләр: Нәҗип Җиһановның «Җәлил» операсында — Җәлил, «Алтынчәч»тә — Җик, «Түләк һәм Сусылу»да — Түләк, Дж. Вердиның «Риголетто»сында — Герцог, Ш. Гуноның «Фауст» әсәрендә — Фауст, А. Рубинштейнның

«Демон»ында — Синодал, П. Чайковскийның «Чародейка» әсәрендә Юрий партияләрен башкара.

Шулай да ул татар авторлары әсәрләрендәге партияләрне аеруча яратып җырлый. Нәҗип Җиһановның «Җәлил»ендә — Җәлил, Хөснул Вәлиуллинның «Самат» операсында Самат образлары шундыйлардан. Җырлау өчен шактый кыен булсалар да, Азат Аббасов аларны бик табигый башкара һәм тамашачының ихтирамын яулап ала.

Азат Аббасовның тавышы лирик-драматик тенорга керә. Аның иркен, саф тавышына сокланмый мөмкин түгел.

Бу җырчыбыз халкыбыз көйләрен, композиторларыбызның төрле жанрлардагы җырларын да яратып башкара. Татарстан радиосында аның башкаруында йөзләрчә җыр саклана, һәм алар бик еш эфирда яңгырый.

Сорау һәм бирем.

1. Җырчының иҗади үсешендә кемнәрнең ярдәме зур була?
2. Татар опера сәнгатендә Азат Аббасовның роле турында сөйләгез.

опера студиясе — опера җырчылары әзерли торган югары мәктәп
лирик — хисле
тенор — җырчының тавыш төре, ирләрнең югары тавышы

Рөстәм Яхин

(1921—1993)

Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы Яхин — безнең иң талантлы композиторларыбызның берсе. Ул тудырган музыкаль әсәрләр халыкның рухи байлыгына әйләнде.

Рөстәм Яхин 1921 елның 16 августында Казанда туа. Шунда музыка мәктәбенең фортепьяно классында укый. 1937 елны Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка мәктәбенә укырга керә, әмма сугыш елларында аның белем алуы бүленеп тора. Мәскәү дәүләт консерваториясенең фортепьяно һәм композиция классын ул 1950 елда тәмамлый.

Р. Яхинның романслары һәм җырлары халык арасында киң таралган. Романс — гади җырларга караганда катлаулырак жанр, ул тирән хис-кичерешләргә бай була. Аны уңышлы башкару өчен махсус музыкаль әзерлек кирәк. «Кем белер кадереңне?» (Габдулла Тукай шигыре), «Онытa алмыйм» (Мостафа Ногман шигыре), «Күңелемдә яз» (Гамир Насрый шигыре) кебек романслары халкыбыз тарафыннан үз күреп кабул ителде. Ул 450 дән артык романс һәм җыр язды.

Рөстәм Яхин татар музыка сәнгатендә романс жанрын югары дәрәҗәгә күтәрде. Бу аның иҗат үзенчәлеген тәшкил итә.

Р. Яхин музыкасы яңгырашы белән ягымлы, лирик, күңелгә ятышлы. Ул, күпләрнең йөрәгенә юл табып, аларны үзенә җәлеп итә. Шигъри телне яхшы сизеп, үзенең җырларында һәрбер шигырьгә хас үзенчәлекне дөрес чагылдырырга омтыла.

Рөстәм Яхин татар музыкасын яңа жанрлар белән тулыландырды, аны хисси яктан баетты. Фортепьянода уйнау өчен язган әсәрләре аеруча зур уңыш казанды. Милли музыкада

моңарчы булмаган тасвирлау чараларын тапты. Тирән дулкынлану, көчле ашкыну, дәртле омтылыш кебек хис-кичерешләрне нәфис итеп бирүдә Р. Яхин зур казанышларга иреште. Ул — Татарстан Дәүләт гимны авторы.

«Рөстәм Яхин — татар музыкасында беренче буларак рояль һәм симфоник оркестр өчен иҗат ителгән зур күләмле «Концерт» дип аталган әсәрнең авторы да. Әсәрләрен зур осталык белән үзе башкарган композитор»,— дип язды аның турында Татарстанның халык артисты, композитор Әнвәр Бакиров.

Татар музыкасын үстерүдәге хезмәтләре өчен Р. Яхин 1959 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССРның халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелде. Аның әсәрләре татар музыкасын Европа казанышлары дәрәҗәсенә күтәрде.

Ул бер үк вакытта бик оста пианист-башкаручы буларак та танылды.

Рөстәм Яхин 1993 елның 23 ноябрендә Казанда вафат булды. Кабере Яңа Бистә зиратында.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Рөстәм Яхинның тормыш юлы турында сөйләгез.
2. Рөстәм Яхин — романслар тудыру остасы. Романс жанры турында сез нәрсәләр беләсез?
3. Композиторның нинди әсәрләрен беләсез? Аларның кайберләрен дәрестә үзегез башкарыгыз яки язмада тыңлагыз.
4. Нәрсә ул Дәүләт гимны? Шул турыда сөйләшегез.
5. Татарстанның Дәүләт гимны язмасын дәрестә тыңлагыз.
6. Р. Яхинның татар профессиональ музыкасын үстерүдәге зур хезмәтләре ничек бәяләнде?

композиция классы — музыкаль әсәрләр төзү теориясен өйрәнү классы

жанр — *монда:* музыкаль әсәрләрнең төрләре (җыр, романс һ. б.)

симфоник оркестр — кыллы, тынлы (өреп), чирттереп яки бәреп уйнала торган уен кораллары оркестры (ансамбле)

Абдулла Алиш
(1908—1944)

Бөтен иҗатымны балаларга багышларга телим.

А. Алиш

Ватан азатлыгы өчен гомерләрен биргән каһарманнар арасында Абдулла Алиш та бар. Шул ук вакытта ул — татар балалар әдәбиятында зур хезмәт күрсәткән язучыларның берсе. Аның хөрмәтле исеме халык күңелендә саклана, әсәрләре кат-кат басыла, якты образы еллар үткән саен тулырак ачыла бара.

Илебезгә дошман яулары басып кергәч, А. Алиш Ватанны саклаучылар сафына басты: фашизмга каршы көрәшеп, соңгы сулышына кадәр Туган иленә, халкына тугрылыклы калып, батырларча һәлак булды.

Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә Спас районы Көек авылында туа. Әтисе игенчелек, умартачылык белән шөгыльләнергә яраткан. Балаларында да хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән, эшкә өйрәткән. Аларны белемле, тәрбияле итәргә тырышкан. Әнисе Газизә апа да шигъри күңелле булган, авылда бәетләр чыгаруга осталыгы белән танылган.

Малай укырга иң әүвәл әтисеннән өйрәнә. Көектәге башлангыч мәктәпне тәмамлагач, Ямбакты мәдрәсәсендә укый. Китап укырга ярата, бигрәк тә аңа әкиятләр һәм шигырьләр ошый. Үзе дә халык авыз иҗаты әсәрләрен җыя башлый. Тора-бара шигырьләр язарга керешә.

А. Алиш — балалар язучысы. Үзенең иҗаттагы урынын ул шул кызыклы һәм мавыктыргыч өлкәдә таба. Аның

әсәрләре балалар матбугатында да, аерым җыентыклар булып та басылып киләләр. «Отряд флагы» (1931) исемле беренче китабыннан соң «Якты күл буе» (1933), «Дулкыннар» (1934) һәм «Ант» (1935) җыентыклары дөнья күрә. Әлеге китаплар аны язучы, шагыйрь итеп таныта. Алиш бала күңелендәге нечкәлекләрне өйрәнергә омтыла, алар белән якыннан аралашып иҗат итәргә тырыша. А. Алишның язучылык таланты әкият жанрында киң ачыла. Аның беренче әкияте — «Капкорсак патша». Аннан соңгы әкиятләре «Нечкәбил» (1937), «Әкиятләр» (1937), «Ана әкиятләре» (1941) кебек китапларында тупланып чыгалар. Бу әкиятләр эчтәлек байлыгы, тематика төрлелеге һәм тормышка якын булулары белән аерылып торалар. Аларда балаларга гыйбрәт булырдай һәм кызыклы вакыйгалар сурәтләнә. Сугыш алды елларында Алиш кече яшьтәге балалар өчен күп кенә хикәяләр һәм әкиятләр иҗат итә.

Абдулла Алиш — балалар өчен сәхнә әсәрләре язуга да өлеш керткән каләм остасы. Аеруча «Кечкенә тоткын» пьесасы сугыш алды елларында мәктәп сәхнәләрендә күп мәртәбәләр куела.

Курчак театрына А. Алиш «Сертотмас үрдәк» әсәре буенча эшләнгән әкият-пьеса бүләк итә. Башка халыклар әдәбиятыннан балалар өчен язылган әсәрләрне туган телебезгә тәрҗемә итә.

Менә шулай илһамланып эшләп йөргәндә, сугыш башлана. Ул да, кулына корал алып, илне саклаучылар сафына баса, дошман белән батырларча көрәшә.

1941 елның октябреннән башлап, берничә ел дәвамында аның язмышы билгесез була. Шундый авыр чакларда да әнисе һәм туганнары аның Ватанга тугрылыклы булып калуына ышанып яшиләр, өметләнеп хәбәр көтәләр.

Әйе, аның намуслы исеме халкыбызга кайтты. Ул антына тап төшермәгән, дошман алдында тез чүкмәгән, авыр әсирлек шартларында да фашизмга каршы көрәштә катнашкан. Тирән лирик кичерешләр белән сугарылган шигырьләр язарга да рухи көч тапкан.

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын,—

дип язган ул «Үзем турында җыр» исемле шигырендә. Аның

тоткынлыкта иҗат ителгән шигырьләрендә Ватанга булган тугрылык, фашизмга нәфрәт хисләре, көрәш һәм өмет, җиңүгә ышаныч яңгырый.

Агым иркенә имәм башымны,
Көчле колачларны салырмын.
Халкым өчен, әгәр кирәк булса,
Агымга да каршы барырмын.

(*«Өметем зур минем киләчәккә»*)

...Көрәш белән тудык, көрәш белән
Керәбез дә, ахры, кабергә.
Язган икән соңгы сулышыбызны
Илебез бәхете өчен бирергә.

(*«Ничек килер үлем?»*)

Әйе, Абдулла Алиш үлемне батырларча каршылый. Туган җире, туган халкы, милләтенең теле, рухы, әдәбияты, үз гаиләсе аның өчен иң газиз нәрсәләр иде. Ул шуларны коткару өчен гомерен бирде. 1944 елның 25 августында башка җәлилчеләр белән бергә аны да вәхшиләрчә җәзаладылар. Ул да илгә җыр булып кайтты.

«Без соңгы сулышыбызга кадәр халкыбызга турылыклы булып калабыз...» ди ул соңгы хатында. Фашист палачлары кулыннан һәлак булганда, аңа әле 36 яшь тә тулып җитмәгән иде. Ул тормышны өзелеп яратты. Яшәргә, туган иленә әйләнеп кайтырга өмете зур иде.

Казанның үзәгендәге калку бер урында бик матур бина бар. Ул — Абдулла Алиш исемендәге балалар мәдәният йорты. Балалар биредә төрле түгәрәкләргә йөриләр, белемнәрен, һөнәрләрен арттыралар. Батыр абыйларының тормыш һәм иҗат юлын өйрәнәләр, әсәрләрен ятлап укыйлар, кичәләр үткәрәләр.

Ул туган Көек авылы кешеләре дә данлыклы якташларының исемен кадерләп саклыйлар. Авыл китапханәсе янында аның һәйкәле тора. Татарстан Язучылар берлеге ел саен балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүчеләргә А. Алиш бүләген бирә. Ул лауреатларга язучының туган авылындагы һәйкәл янында тапшырыла.

Казан шәһәрендә бер урам һәм 55 нче мәктәп аның исемен йөртә. Әлеге мәктәптә А. Алишка багышланган бай музей эшли. Бу — сөекле язучыбызны, каһарманыбызны хөрмәтләү, аның исемен мәңгеләштерү. Бу — Абдулла Алишның халык күңелендә яшәвен дәвам иттерүе.

Сораулар.

1. Ни өчен Абдулла Алишны балалар язучысы дибез? Балаларга әсәрләр язу өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк дип уйлыйсыз?
2. Язучы булып китүендә аңа кемнәрнең тәэсире булган?
3. А. Алиш кебек, әсирлек шартларында шигырьләр язган милләттәш язучыларыбыздан кемнәрне беләсез?
4. Алишның тоткынлыкта язган шигырьләрен укыганыгыз бармы? Нинди шигырьләрен беләсез?
6. А. Алишны халкыбыз хөрмәт итә, олылый, онытмый. Моны нәрсәләрдән күреп була?

мәдрәсә — мөселманнарда, ягъни ислам динен тотучы халыкларда, урта һәм югары сыйныфлары булган дини уку йорты
гыйбрәт булырдай — сабак алырдай, уйланырга мәҗбүр итәрдәй, акылга өйрәтердәй вакыйга, хәл
ант — ил, халык алдында биргән тантаналы вәгъдә (присяга)
тоткынлыкта — әсирлектә (в плену)
калку — биек, югары

ЯЛКАУЛЫК — ХУРЛЫК, ТЫРЫШЛЫК — ЗУРЛЫК

Чәчәкләр башлыгы бик зур ярыш үткәрергә булган. Шул турыда төрле якка хәбәр дә салган:

— Кем дә кем бал салырга яхшы савыт хәзерләсә, ул савытта бал бер дә бозылмаса, әчемәсә, барлык чәчәктәге балны шуңа бирәчәкмен,— дигән.

Бөҗәкләр көнне-төнне белмәгәннәр. Бар да тырышып савыт эшләгәннәр.

Күп тә үтмәгән, бөҗәкләр төрле яклап очып килгәннәр. Бар да үзләре эшләгән савытларны чәчәк башлыгына китергәннәр.

— Менә дигән савыт, балны кара салып,— дигәннәр.

Чәчәкләр башлыгы барысын да борып җибәргән:

— Ашыкмагыз, ашыккансыз, бик начар ясагансыз. Мондый савытлар миңа кирәкми. Шуңа күрә бал да сезгә эләкми,— дигән.

Шөпшә белән Бал корты иң соңгылар булып эшкә керешкәннәр, беренчелекне алырга өмет иткәннәр.

Бал корты көне буе бертуктамый эшли дә эшли икән: еракерак җирләргә очып бара, аллы-гөлле чәчәкләрдән бал суырып ала, аны алып кайтып, үзе хәзерләгән матур күзәнәкләргә сала икән.

Шөпшә дә чәчәкләрдән бал җыйган. Ләкин ул бик-бик ялкау булган. Иртән әзрәк кенә эшли икән дә, кояш кыздыра башлагач, оясына кереп йоклый икән.

Көннәрнең берендә Шөпшә Бал кортына очраган һәм аны өзелеп-өзелеп кунакка чакырган:

— Кил әле, кил, мин әзерләгән бал савытын да күреп китәрсең,— дигән.

— Ярый,— дигән Бал корты,— барсам барырмын, ләкин бүген миңа кереп чыгыйк, бераз күңел ачып утырыйк,— дип, Шөпшәне үз өенә алып киткән һәм бик шәпләп кунак иткән.

Шөпшә Бал корты эшләгән савытны кат-кат караган һәм аны бик-бик мактаган:

— Осталарның да остасы икәнсең, мондый шәп савытны ничек ясый алдың?— дигән.

— Серемне әйтсәм әйтим, дус кеше бит, сиңа белгертим инде,— дигән Бал корты,— көне-төне тырышып эшләгәч, бүгенгә эш торып торсын, ял итим әле димәгәч, бар авырлыкларны да җиңеп була икән,— дигән.

Көннәр үткән дә үткән. Бал кортының Шөпшәгә кунакка барыр вакыты да килеп җиткән.

Эштән кайтышлый, Бал корты Шөпшәнең өенә кергән, дустының хәлен белгән:

— Исәнме, Шөпшә дус, эштән соң ятып, бераз ял итәсеңме? Әллә юкса авырып торасыңмы? Бал савытларын илтер көн дә җитә бит, бик тырышып әзерләник,— дигән.

Шөпшә чалкан яткан, күзләрен акайткан. Аякларын югары сузган, мыекларын түбән салындырып, ул:

— Сәламеңне дә алыр хәлем юк, дустым,— ди икән. Кунакны сыйларлык түгел, туйганчы үзе ашарлык та балы юк икән. Ярты көн бал җыйса, шунда ук аны ашап бетерә дә барган. Башын шундый ялкаулыкка салган. Шуңа күрә бал савытын да эшли алмаган.

Ярыш көне килеп җиткән.

Бал корты балавыздан эшләнгән матур күзәнәкле бал савытын күтәреп очып киткән. Шөпшә дә үзенең аннан-моннан эшләнгән кәрәзен алып килгән.

Чәчәкләр башлыгы кәрәзләргә бал салып караган. Шөпшә кәрәзендә бал тормаган, ә Бал кортының кәрәзе акмаган.

— Тырышканнар, күп көч куйганнар, менә дигән кәрәз эшләп чыгарганнар. Шуңа күрә теләсә нинди чәчәктән теләсә никадәр бал җыярга бал кортларына рөхсәт бирәм,— дигән Чәчәкләр башлыгы.

Шул көннән башлап бал кортлары чәчәкләрдән бал ташый башлаганнар, ә шөпшәләр ялкаулыклары аркасында хурлыкка калганнар.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Тырыш кеше турында: ул Бал корты кебек эшли, диләр. Ни өчен?
2. Әсәрдәге ярышның шартларын аңлатыгыз. Савытлар нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?
3. Бөҗәкләр дә бик тырышлар. Әмма савытны яхшы итеп ясый алмаганнар. Сәбәбе нидә дип уйлыйсыз?
4. Шөпшә, сезнеңчә, ни өчен эшкә соңга калып керешкән?
5. Бал кортының савытны озак ясавының сәбәбе нидә?
6. Әкияттә шигъри яңгыраган җөмләләр бар. Шуларны эзләп табып, кычкырып укыгыз.

Шөпшә — Оса
оя — гнездо
балавыз — бал кортлары эшли торган ябышкак матдә (воск)
кәрәз — балавыздан ясалган күзәнәкләр оясы (сот, соты)
күзәнәкләр — кәрәздәге тишекләр (бал салу өчен вак-вак оялар)

«Хезмәт төбе — хөрмәт» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. «Хезмәт төбе — хөрмәт», дип әйтү халык авыз иҗатының кайсы төренә керә? Аның мәгънәсен ничек аңлыйсыз?

2. Ни өчен халык хезмәт турында мәкальләр иҗат иткән дип уйлыйсыз?

3. Нәрсә соң ул хезмәт? Ул төшенчәне ничек аңлыйсыз?

4. Хезмәт, хөрмәт, бәхет бердәмлеген ничек аңлыйсыз?

5. Халкыбыз хезмәт турында, мәкальләрдән тыш, тагын нәрсәләр иҗат иткән? Мисаллар китерегез.

6. Тырышлык, ялкаулык, хезмәт төшенчәләрен бергә бәйләп аңлатыгыз.

7. Түбәндәге мәкаль һәм әйтемнәрнең мәгънәләрен сез ничек аңлыйсыз?

Агач — җимеше белән, кеше — эше белән.
Данны эзләүче түгел, эшләүче таба.
Эшчәннән игелек көт.

Хезмәт белән яхшылык,
Ялкаулык белән яманлык бергә йөри.

Эшле килер — эш арттырыр,
Эшсез килер — эш калдырыр.

Ялкаулык — бәхет дошманы.
Кешенең кешелеге төсеннән түгел, эшеннән беленә.
Эшле кеше — көчле кеше.

Авыр эшкә беләк бар,
Кыю эшкә йөрәк бар.

Эшләгәнгә ышан, ялкаудан ерак кач.

Габдрахман Әпсәләмов
(1911—1979)

Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов хәзерге Мордва Республикасының Иске Аллагол дигән татар авылында 1911 елның 28 декабрендә туган. Аның яшүсмер еллары Мәскәүдә уза. Андагы татар мәктәпләренең берсендә белем ала. Шул елларда әдәбият белән мавыгып китә, үзе үк шигырьләр, хикәяләр яза башлый. Муса Җәлил җитәкчелек иткән әдәби түгәрәккә йөри. Беренче шигыре дә Җәлил редактор булып эшләгән «Октябрь баласы» журналында басыла. Әсәрләрен Казанда чыгучы журналларда шактый еш укырга мөмкин була.

Габдрахман Мәскәүдә һөнәр мәктәбендә укый, аннан соң заводларда слесарь һәм токарь булып эшли. Ләкин күңеле һаман да әдәби иҗатка тартыла. Бу эшнең серләренә тирәнрәк төшенергә омтыла. Мәскәүдәге Әдәбият институтына укырга керә һәм аны 1940 елда тәмамлый. Пьесалар, хикәяләр иҗат итә. Сугышка кадәрге елларда инде ике китабы басылып чыга.

Бөек Ватан сугышы башлангач, язучы, әлбәттә, үзенең урыны фронтта икәнен аңлый. Ул Карелия фронтында сугыша. Башта минометчылар командиры, 1943—1945 елларда «Ватан өчен сугышка» исемле Карелия фронты газетасының җаваплы сәркатибе була. Ә 1945 елда Ерак Көнчыгышта японнарга каршы сугышта катнаша.

Сугышның башыннан ахырына кадәр булу Г. Әпсәләмов иҗатына зур тәэсир итә. Ул бик күп әсәрләрендә сугыш хәлләрен сурәтли. Башта хикәяләр яза, аннан соң «Ак төннәр» (1946) повестен, «Алтын йолдыз» (1948), «Газинур» (1951), «Мәңгелек кеше» (1960), «Агыла болыт» (1977) романнарын — безнең ил кешеләренең явыз дошманга каршы көрәштәге

тиңдәшсез батырлыгы турындагы әсәрләрен иҗат итә. Ул әлеге әсәрләрдә сугышның фаҗигасен, тетрәндергеч күренешләрен сурәтли. Безнең сугышчыларны Г. Әпсәләмов кыю, батыр, бай рухлы итеп гәүдәләндерә. Аның геройлары гадәти генә кешеләр түгел. Алар тормышны, кешеләрне ихлас күңелдән яраталар, дошманнарын нәфрәтләнеп кұралмыйлар. «Миңа унтугыз яшь иде» (1968) повестеның баш герое Малик Газимов та шундый кеше. Илен, газиз Казанын, әти-әнисен, туганнарын, сөйгән кызын өзелеп яратучы бу егетнең батыр йөрәкле булуы бик табигый. Автор аны укучыга шулай тәкъдим итә дә.

Г. Әпсәләмов тыныч хезмәт кешеләренең дә бик матур образларын тудырды. Сөләйман («Сүнмәс утлар», 1958), Гәүһәр («Яшел яр», 1968), Гөлшаһидә («Ак чәчәкләр», 1966) һәм башка образларны укучылар аеруча яратты. «Сүнмәс утлар» романы өчен язучыга 1959 елда Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Аның әсәрләре бик күп телләргә тәрҗемә ителде, төрле халыклар аларны яратып укый.

Язучы 1979 елның 7 февралендә Казан шәһәрендә вафат булды.

Сораулар һәм бирем.

1. Габдрахман Әпсәләмовның тормыш юлы турында сөйләгез.
2. М. Җәлил яшүсмер Габдрахманга ничек ярдәм итә?
3. Язучының сугыш темасына күп кенә уңышлы әсәрләр иҗат итүенең сәбәбе нидә дип уйлыйсыз?

сәркатибе — секретаре
тетрәндергеч — күңелгә бик авыр һәм көчле тәэсир итә торган
нәфрәтләнеп — иң көчле дошманлык һәм кұралмау хисе белән

МИҢА УНТУГЫЗ ЯШЬ ИДЕ

(Повесть кыскартып бирелә)

Мине 1941 елның декабрендә Мәскәү янындагы сугышларда үтерделәр.

Үлгәннәрдән хат килми, алар белән инде сөйләшеп булмый, диләр. Ни үкенеч, исән чакта мин ватандашларым белән күзгә-күз карашып сөйләшә алмадым. Хәзер, соң булса да, әйтәсе

сүзләремне әйтмәсәм, исәннәр алдында бурычлы булып калырмын шикелле.

Мәскәүгә без сентябрь ахырларында килеп төштек. Төн иде, безне ниндидер караңгы урамнардан алып бардылар... Ә таң атканда инде еракта — урманда идек. Артыма борылып карадым: Мәскәү күренмәде.

Иртә белән мине сакка куйдылар. Әнә урман юлы. Тирә-як яшел, тик ялгызак каеннар гына саргайган... Сугышчылар яфраклар өстенә ятып ял итәләр. Тик постлар гына уяу. Тыныч, хәтта агачлар арасында ап-ак тоҗым җепләре күренә. Сугышның якында гына булуына ышанасы килми. Без, унтугыз яшьлек малайлар, дөньяда ни күргән?

Башта үземне бик һәйбәт сизгән идем, әмма тора-бара керфекләр авырая башлады, күзләр ихтыярсыз йомылалар. Ләкин йокы тәэсиренә биреләсе килми, башыңны селкеп тирәягыңа каранасың, агач төбендә таптанасың. Бераздан тагы йокы баса... Ләкин ярамый, син постта, дошман якын.

Ниһаять, мине алыштырдылар, ял итәргә куштылар. Агач төбенә бөгәрләнеп яттым да йокыга да киттем. Иптәшләрем миңа кайнар аш алып кайтканнар, уятып караганнар. Кая ул, күземне дә ачмаганмын.

Мин озын буйлы, киң җилкәле. Мине тылда ук Абрек дип йөртәләр иде. Ул заманнарда малай халкының төшләренә керә торган «Абрек Заур» дигән кинофильм бар иде. Күрәсең, бу картинаны мин бик тә ятраткамын, шуннан үземә кушамат та тагылып калган. Яшереп торасы юк, бу кушамат минем үземә дә ошый. Буйсынмас Абрек буласым килә. Казанка буйлары әле дә мине сагына торгандыр, мин аларны Абрек булып күп айкадым.

Көне буе юлда булдык, арылды, тамак кипте. Кичрәк кыска ялга туктадык, тамак ялгап алдык. Тирә-ягыбыз бер әрәмәлек, инеш буе. Минем яныма бергә уйнап үскән дустым, хәзер минем кебек солдат — Мөнир килеп утырды.

Әгәр Мөнир белән күптән таныш булмасаң, аның белән ничек сөйләшергә дә белмәс идең. Әнә кояшта янган йөзе җитди сыман, ә пилоткасын кыңгыр салган.

— Я, Абрек, кайчан сугышка керәбез инде? Илгә хатлар язасыңмы?

— Башта бераз сугышыйк.

Сафка тезелергә команда булды. Барыбыз да урыннарыбыздан сикереп тордык.

* * *

Казанда Арча кыры дигән борынгы урамны беләсезме? Шул урамда, Культура һәм ял паркы турысында, бер мәһабәт бина бар. Заманында анда Духовная академия булган, безнең заманда — мәктәп. Бинаның өске катларында кеше тормый, анда аудиторияләр, клуб, китапханә, спорт залы. Түбәндә, подвалда, җыештыручылар, мич ягучылар, шоферлар, тагын әллә кемнәр тора.

Мин менә шул подвалда үскәнмен. Әткәй — мич ягучы, әнкәй — идәннәр себерүче. Безнең нибары бер бүлмә, күп булса унбиш-уналты квадрат метр. Сеңлем белән мин кышын коридорда, җәен ишегалдындагы бакчада уйныйбыз.

Безнең подвалда аксөякләр юк, бар да эшли. Ак эш, кара эш дип сөйләүләрне белмибез. Әнкәй чиләге-чүпрәге турында кайгыртса, әткәй мичен, көрәген, күмерен белде. Мин әтигә яшьтән үк булыша идем. Үсә төшкәч, мичкә күмер дә ташлаштыргалый башладым.

— Вәт тәк, физкультура!— ди иде әткәй белән эшләүчеләрдән берсе.— Менә кайда мускуллар уйный ул. Я әле, Малик, беләгеңне күрсәт. О-о, таш кебек!— ди ул, минем беләгемне капшап.

Минем моңа кәеф килә, миннән бигрәк әти шатлана.

— Өйрәнсен!— ди ул.— Һөнәр ул — кешенең кесәсендә бетми торган мал. Яшьтән эшнең тәмен белсә, әпәйнең дә кадагы күпме торганын чамалый.

Мин, егетлегемне күрсәтеп, каерылып-каерылып мичкә күмер ташлыйм.

Мин, үзебездән ерак түгел, унсигезенче татар мәктәбендә укыдым. Укуым болай ару гына булса да, тәртип ягы аксады. Әледән-әле үземнең Абреклыгымны күрсәтә идем. Иптәшләрне Казанка буена алып китәм, су керәбез, көймәдә йөрибез, иң хәтәр чоңгылларга чумабыз... И ул Казанка буендагы уеннар! Бит-баш та күгәреп чыга, күлмәкләр дә ертыла.

Урта мәктәпнең соңгы классларында укыганда, мин буйга бик нык үсеп киттем, җилкәләрем дә киңәйде. Әллә ничек кенә булды, мин шаярулардан туктала төштем, укуга бирелдем. Әйткәнемчә, әни мәктәптә җыештыручы булып эшли. Кеше булмаганда, кичләрен әнигә ияреп, мин дә спорт залына керәм. Волейболга да, баскетболга да, гимнастикага да минем сәләт бар. Турникта атынганда, башкалардан уздыргалап та җибәргәлим.

Әнкәйдән үтенеп-үтенеп, спорт костюмы сатып алдырдым. Аякка ак тапочкалар да булды.

Берзаман шушы спорт залында нечкә генә гәүдәле, иңнәренә төшкән куе сары чәчле, зәңгәр күзле бер кыз күренә башлады. Бу мәктәпнеке түгел, моны без бик тиз белеп алдык. Кыз физкультурага ярыйсы оста, җитез. Турникта хәтта миннән уздыра. Минем базар шактый төште. Минем исем китә. Моны Мөнир дә сизеп алган иде.

— Я, Абрек, эшең бетте, Аллаһы әкбәр, ботарлады да салды үзеңне кыз бала,— ди.

Мөнир шулай шаяртып торган чагында кыз, чак кына кызарып:

— Нинди Абрек булсын ул, аның үз исеме бар. Шулай бит, Малик?— диде.

Абрек дигәндә, мин башкалардан нәрсә беләндер аерылам кебек, анда хәтта ниндидер сер, канатлы романтика бар сыман. Әмма Мөслимә әйткәч, минем үз исемем дә нурланып киткәндәй булды. Ләкин кызык хәл: мин кызга әйе дип тә, юк дип тә әйтә алмадым. Минем аптырауны кыз ачык сизде, ахрысы, йөзен чытып, читкә борылды...

Шулай берничә атна вакыт үтеп китте. Мәктәптә чыгарылыш имтиханнары якынлашып килә иде. Мин рәтләп хәзерләнә дә алмыйм. Көндез дә шул Мөслимә, күзгә күренмичә, һаман чебен кебек бәйләнә. Дәрес барганда да, мин аның көлүен ишетәм кебек. Тәмам уйга бирелеп киттем, ябыктым да. Беркөнне, мәктәптән чыгып, өйгә кайтканда, Мөслимәне очраттым. Ак алъяпкычтан, кулында кечкенә генә портфеле бар.

— Малик, син кайда югалдың? Нигә спорт залында күренмисең?

Әллә нәрсә генә әйтәсем килде бу чәнечкеле шөпшәгә. Шулай да мин... Мөслимәдән курка идем, яшерен рәвештә, беркемгә дә сиздермичә курка идем. Мин Мөслимәнең минем кебек бер укучы икәнен, тик рус мәктәбендә укуын белә идем. Университетның физмат факультетына керергә хыяллануы да миңа сер түгел. Ләкин минем төзүче буласым килә.

Мин кызарганнан-кызара барам. Мөслимә, минем кулыма кагылып, бик йомшак тавыш белән:

— Бүген кичкә спорт залына кил. Килми калма, бергә волейбол уйнарбыз,— диде дә бик нәфис итеп елмаеп китеп барды.

Мин дә үз юлыма киттем. Артыма борылып карыйсым килсә дә тыелдым. Ул көнне мин кичне бик түземсезләнеп

көттем, ләкин кич җиткәч... спорт залына кермәдем. Бакчага чыгып, куе агач башына мендем дә шуннан якты зал тәрәзәсенә карап тора башладым. Спорт костюмыннан гына булган Мөслимә бу юлы миңа бик матур, бик күркәм булып күренде. Мөслимә сәгатенә карый-карый уйнады. Ашыга идеме, кемнедер көтә идеме (мине көтүен башыма да китермәдем), Мөслимә сәгатенә тагын бер карап алды да залдан чыгып китте. Мин, әзрәк артка кала төшеп, Мөслимә артыннан бардым. Ул өенә кадәр, тирә-ягына карана-карана, ялгыз кайтты. Ишегалларына йөгерә-йөгерә керде. Курыкты, ахрысы. Мин урамның икенче ягыннан, күләгәдән карап калдым.

Минем юләрләнгән сыман йөрүләрем — зур мәхәббәтнең тууы, башы булгандыр, күрәсең. Мин Мөслимә турында көнтөн уйлый башладым.

Бер ун көннән соң Мөслимә белән дә татулаштык. Ул көнне без спорт залыннан иртәрәк чыктык. Чәчәк исе белән тулы бик җылы июнь киче иде. Безнең тыныч тормышта, исерткеч яшьлек гамьсезлегендә соңгы кичләребез булганын кем белгән ул чакта? Парк капкасы башындагы радио күңелле музыка уйный. Элек мин әкиятләрдә яшь егетнең күкрәгендә йөгәнле чаптар бар дигәнне ишетсәм дә аңламый торган идем. Хәзер беләм: коштай җитез атмы, башка бер нәрсәме, ләкин нәрсәдер бар егет йөрәгендә!

Без, Мөслимә белән, урам аша чыгып, паркка юнәлдек. Парк юлында Мөслимәне бик култыклыйсым килгән иде дә, кая андый батырлыкка җөрьәт итәргә! Мөслимәгә чак кына орынып китсәм дә, тәнемнән электр тогы үткәндәй була. Мөслимә дә, бераз уңайсызланган шикелле, ялтырап торган зәңгәр күзләрен юри миннән ераккарак яшерә. Шул үзара уңайсызлануны басар өчен булса кирәк, җыен юк-бар нәрсә турында сөйләшеп, сәбәпсез-нисез көлеп бардык.

Паркта кеше бик күп. Без кешеләрдән читкәрәк киттек, безнең табигать кочагында икәүдән-икәү каласыбыз килә иде. Менә инде без биек нарат төбендә текә ярда. Казанка елгасына карап утырабыз. Бакчалар артында елга. Ул батып барган кояш яктысында ялт-йолт итеп тора.

Инде караңгы да төште. Мөслимә минем янымда гына утыра... Ләкин мин аңа кагылырга да кыймыйм. Без шулай ярым сәер телдә бик озак сөйләшәбез. Безгә инде кузгалырга да вакыт. Күптән инде ай калыкты, йолдызлар җемелди. Мин, егет кеше, беренче булып җәһәт кенә урынымнан торам.

— Ой, мин тора алмыйм, аякларым оеган,— диде Мөслимә, көлә-көлә.

— Бир кулыңны.

Мин кулымны суздым. Мөслимә минем кулга тотынды да урыныннан сикереп торды. Ләкин шуннан соң ул кулымны ычкындырмады. Без култыклашып түгел, бер-беребезнең бармак очларыннан тоткан килеш кайттык. Бу вакытта паркта халык тагын да күбәйгән, җанлылык арткан, ләкин без үз сүзебез белән генә мәшгуль, бүтән бер тавышны да ишетмәдек. Мин кич буе, каян гына сүз чыгарамдыр, төрле мәзәкләрне чәчәм генә. Ә Мөслимә минем тузга язмаган сүзләремне чын ихластан кабул итә, эче катып көлә. Өенә кайтып җиткәнче көлде ул, капкадан да көлә-көлә кереп китте. Мин дә үземне асыл кош тоткан кебек хис иттем.

Утлары бар, тәрәзәләре ачык. Мөслимә дә тәрәзәдән күренер дип көттем. Дөрес, сүз куешмадык. Ләкин сөйгән күңел кайчан алдана? Мөслимә, ишектән керүенә, ачык тәрәзә янына килде дә, пәрдәне рәтләргә булгандыр инде, ләкин үзе сиздерми генә миңа кул болгап алды. Миңа тагын ни кирәк?

Эчке шатлыктан тилерә торган көннәр бик озак дәвам итсен дип теләгән идем мин. Ләкин булмады, озакламыйча Бөек Ватан сугышы башланды. Ул безнең, яшьләрнең, мөнәсәбәтләренә дә үзенең коточкыч кара күләгәсен төшерде. Сугышның беренче атнасында ук әти фронтка китте. Без бөтен семьябыз белән аны җыелу пунктына кадәр озата бардык. Мин әткәй турында күп уйландым. Иптәшләре аның хакында: чын батыр иде, дип язганнар.

* * *

Менә үзем дә фронтта инде. Әллә ничек кенә булды бу, гүя мин пилотка, шинель киеп туганмын, армия теле, командирлар теле минем үз ана телем шикелле. Мин ниндидер күләмдә үземне сугыш утыннан өстен куярга өйрәнә башладым. Хәтта кайчак узалдыма елмаям: политрук та, командир да мине мактап телгә алалар. Бигрәк тә яңа килгән солдатларга мине үрнәк итәләр. Мин моңа бик үк ышанмаган да булыр идем, ләкин күп тә үтмәде, мине аерым сапер батальонының разведкасына күчерделәр. Анда тикмәгә генә алмыйлар, бигрәк тә сугышлар барышында. Разведчикларга төнлә дә тынгылык юк. Хәер, безгә генә түгел, безнең подразделениеләр дә төнге

атакаларга торган саен кыюрак рәвештә күчә башладылар. Без күп нәрсәгә өйрәндек, бигрәк тә сугышырга. Танклардан да курыкмый башладык. Юләрләнеп йөргән малайларны хәзер беркем дә танымас. Киләчәк буыннар аларга бу кадәр ныклык каян килгән дип гаҗәпләнер. Дошман белән актык тамчы каныбызга кадәр якалашабыз.

Бүген безгә «тел» алырга куштылар. Бурыч куйганда: дошманның оборонасын ачыкларга кирәк, диделәр. Кем бу турыда тулы мәгълүмат бирә ала? Әлбәттә, немецларның саперы. Без инде аларның кая урнашканлыкларын да белә идек.

Сиздерми генә дошман тылына үтеп, саперлар урнашкан өйләр каршына чокырга яттык. Егерме-утыз адымда немец часовое йөренә. Сакчы сул аягына бераз аксый төшә. Әнә яндырылып беткән авылга ничек өстән карый. Кара, кара, хисап бирер көнең алда. И-и, баскан урынында йокымсырый лабаса! Менә куркып уянды, башын күтәреп, як-ягына карана. Ул-бу булмагач, тагын йөренә, бераздан тагын йокымсырый башлады, ахрысы, баскан җирендә чайкала.

Вакыт! Ай да болыт астында яшеренгән, фриц та безгә арты белән баскан. Шуышабыз, аннары мин сикереп торам, икенче секундта, немецның авызын учым белән каплап, аяктан егам. Без аның авызына чүпрәк тыгабыз, кулларын артка бәйлибез. Аннары, немецның коралын эләктереп, күздән югалабыз.

Штаб начальнигы андагы хәлләр турында әзрәк сораштыра да лейтенантка фрицны алып китәргә куша. Тегенең коты очкан, калтырана.

Без үз өйләребезгә кайтабыз, сәкегә сузылып ятабыз. Бик арылган, күзне йому белән йоклап та китәрбез кебек, ләкин нервлар әле тынычланмаган. Ничектер күз алдында үзеннән-үзе Мөслимә калка. Мин рәхәтләнеп аның турында уйлый башлыйм. Шундый авыр көннәрдә Мөслиманең дөньяда булуы — минем өчен нинди бәхет, моннан, ут эченнән, аңа карап торулары нинди сөенеч. Әгәр ул булмаса, мин үземне дөньяда рухи бик фәкыйрь итеп сизәр идем. Мин, туган ил белән сөйләшкән кебек, Мөслимә белән күңелемнән сөйләшәм, аның исеме белән сугышка керәм, аның исеме белән сугыштан чыгам.

Сугышка чаклы гармун уйнарга бик дәртем бар иде. Уйнарга өйрәнергә дә йөрдем, булмады. Әнкәй әйтә торган иде:

— Күңел бирмисең. Көзге алдында бу хәтле басып торганчы, гармун уйнасаң, өйрәнмәс идеңме? Аю әнә биергә дә өйрәнә ич!

Әйе, аю биергә дә өйрәнә, ә мин гармун уйнарга да өйрәнә алмадым. Кайтсам өйрәнер идем... Кайтсам... Бу мөмкинме?

Үзалдыма әкрен генә җырлап җибәрәм:

Әнкәй мине тапкачтын
Ак биләүгә биләгән.
Ак биләүләргә биләгән,
Бәхете булсын димәгән.

Ак чиләгем мөлдерәмә,
Сулары тамып тора.
Бергә чакта берни түгел,
Аерылгач сагындыра.

Башка татар солдатлары да моңланган чакларда туган җырны сузалар. Әллә нәрсәләр искә төшә, әллә нәрсәләр сагындыра.

Кинәт самолет тавышлары ишетелә, ул да булмый — дошман безнең тирәне бомбага тота башлый. Каһәр суккыры, нәкъ безнең өскә яудыра. Күз ачып йомганчы өйдән чыгып, якындагы «ярыклар»га сикерәбез. Әйтерсең җир тетри... Ниһаять, җир астыннан башны калкытабыз. Күр инде! Әле генә без ял итеп торган өй юк инде, тетелеп яна. Минем биштәрем дә юкка чыккан. Биштәр төбендә Мөслимәнең хатлары ята иде, мин аларның барысын җыя барган идем бит. Менә шул бик кызганыч булды.

...Әгәр гитлерчылар, елганы кичеп, плацдарм алсалар, безнең гаскәрләрнең хәле бик кискенләшә. Ә су минем муеннан. Пулялар бөтенләй якында ук оча башлады.

Шулвакыт минем күз алдыма Мөслимә килде. Миңа берьюлы җиңел булып китте. Елганың уртасын үттек бугай. Бер минут чамасы тын алдык та тагын алга киттек. Ләкин туңдыра башлады, безнең бит каска астындагы баш киемнәребез генә коры калган...

Шул көннәрдә мин хат алдым. Нинди җылы, нинди мәхәббәтле хат иде ул! Мин аны бер дә укыдым, ике дә укыдым. Иптәшләр хәтта шаярталар:

— Ну бу кызый! Гвардия өлкән сержантын ничек бөтереп алган, әйләнә дә хат укый, әйләнә дә хат укый!— диләр.

Әйе, укыган саен Мөслимәнең хатында яңа бер мәгънә ачам. «Синең турындагы кечкенә генә хәбәр дә кадерле бит миңа, Малик бәгырем...»

Мөслимә минем күңелемдә көннән-көн күбрәк, тулырак урын ала бара.

Сораулар һәм бирем.

1. Әсәрдә хикәяләү инде үлгән егет авызыннан алып барыла. Ул җирдә бары тик унтугыз ел гына яшәп калган. Бу егетне сез ниндирәк кеше итеп күз алдына китердегез?

2. Үлгән кеше тарафыннан хикәяләнсә дә, әсәр якты уйлар һәм хисләр белән сугарылган. Бу нилектән килә?

3. Малайның үз исеменә һәм кушаматына мөнәсәбәте нинди?

4. Малик хезмәт сөючән, таза малай булып үсә. Моңаниләр сәбәп булган?

5. Малик белән Мөслимә арасындагы мөнәсәбәт турында нәрсә уйлыйсыз?

6. Малик үзен сугышта нинди итеп таныта? Аңа нинди хәрби исем бирәләр?

7. Малик Мөслимәдән килгән хатларны юл капчыгында саклаган. Солдат тормышында туган илдән килгән хатларның әһәмияте нидә икән?

8. Матур итеп хат язу — кеше өчен бик кирәкле эш. Кемгә дә булса атап хат язығыз, бик сер булмаса, язган хатларыгызны сыйныфта кычкырып укуны оештырыгыз.

ялгызак — ялгыз
тоҗым җепләре — пәрәвез җепләре (паутина)
әрәмәлек — вак агачлык, куаклар үскән урын
сафка — *монда*: рәткә, стройга
Арча кыры — Арское поле (элек Казанның иң кырый урамы шушында булган, аннан кыр, басу башланган)
әпәй — ипи
кадагы — *монда*: гөрәнкә, фунт (409,5 граммга тигез булган авырлык үлчәве)
тәртип ягы аксады — тәртип начарланды
чоңгыл — төпкел (омут, водоворот, пучина)
чыгарылыш имтиханнары — мәктәпне тәмамлаганда тапшырыла торган имтиханнар
чаптар — чабышкы ат (скакун)
җөрьәт итү — батырчылык итү
«тел» алырга — немецларның берәрсен эләктереп алып кайтырга
рухи бик фәкыйрь итеп — эчке дөньямны бик ярлы итеп
дәртем бар иде — омтыла идем
чиләгем мөлдерәмә — чиләгем тулган

моңланган чакларында — күңелләре йомшарган, нечкәргән вакытларында
биштәр — юл капчыгы (котомка)
мәхәббәтле хат — бик җылы, күңелне рәхәтләндерерлек итеп язылган хат

* * *

...Мөнир соңгы көннәрдә бераз авырыбрак торды, ләкин медсанбатка барырга теләмәде. Мин аның хәлен белә килдем. Ни әйтсәң дә, без аның белән балачактан дуслар бит, фронтта бу дуслык тагын да ныгыды, үсте.

Мин ишекне ачтым, Мөнир ике катлы сәкенең аскы катында кырын яткан да патефон уйната. Йөзе уйчан, агарган, суырылган. Өйдә артык беркем дә юк, өйрәнүләрдә булса кирәк. Мине күргәч, Мөнирнең йөзе яктырып китте.

— Ничек соң, терелеп буламы, дус кеше?— дип сорадым мин.

— Әйдүк, Абрек. Мин сине баядан бирле көтәм. Менә сез юлга хәзерләнәсез дип ишеттем, ә мин, ялкау Сарбай шикелле, йомшак түшәктә калам,— диде ул, елмаеп һәм әрнеп.

— Терел, аннары сиңа да эш җитәрлек булыр. Каян бу музыканы таптың?— дидем, Мөнирне күңелсез уйлардан аерырга тырышып. Мин аны бик яхшы аңлыйм, үзем шундый хәлдә булсам, белмим, нишләр идем икән.— Моңы, малай, прямо йөрәкне чеметә.

— Белмим, синең йөрәгеңне уйнатырмы икән музыка, Абрек? Син таш күңелле ич.— Мөнир көлемсерәде.— Мин авыргач, иптәшләр каядыр хозвзводтан табып китерделәр.

— Ә татарча пластинкалары юкмы? Татарча җыр тыңлыйсы килеп китте.

— Әттә генәем!— диде Мөнир, уң кашын сикертеп.— «Сандугач» искә төштеме әллә? Соң ничек, сәлам хатлары килеп торамы үзеннән? Безгә бит хәзер шуннан артыгы әләкми инде.

— Килгәли,— дидем мин, канәгать икәнемне бер дә яшермичә. Хәер, моны яшерергә мөмкин дә түгелдер шикелле. Кычкырып тора.

— Менә тыңла,— дип, Мөнир патефонны борды да яңа пластинка куйды. Бераздан атаклы «Сагыну» көенең нәфис моңнары агыла башлады. Сагыну! Сагынмыйбызмы соң! Бу көй бит йөрәкләрне актара, күңелләрне талый, бигрәк тә якыннардан аерылгач.

Газиз моң. *Р. Сәйфуллина рәсеме*

Бу пластинканы өч-дүрт тапкыр әйләндердек. Әйләндергән саен, нииндидер яңа бер ягы ачыла кебек. Бу кадәр тирән ләззәтләнү белән моңарчы бер җырны да тыңлаганым юк иде шикелле. Әллә каян, күкләрдән төшкән бәхет булды бу. Каядыр биеккә күтәрде кебек үземне!..

Шул чакта өйгә бер сугышчы ашыгып керде дә, миңа мөрәҗәгать итеп, карлыга төшкән тавыш белән:

— Гвардия өлкән сержанты, сезне хәзер үк командир чакыра!— диде.

Мин урынымнан тордым. Мөнир белән кочаклашып саубуллаштык, аннары, мине чакыра килгән сугышчы белән бергә өйдән чыгып, командир янына киттек. Ялгышмадым, задание бирергә чакырган иде.

Караңгы төшкәч, юлга чыктык. Уналты кеше. Барыбыз да ак комбинезоннардан. Чаңгыда барабыз. Аркаларыбызда авыр капчыклар; танкларга һәм пехотага каршы кулланыла торган миналар, шартлаткычлар тутырылган. Бурыч ачык: дошманның чигенү юлларын миналарга, күперләрен шартлатырга кирәк. Иртәнгә кадәр барысы да эшләнеп беткән булырга тиеш, чөнки нәкъ җидедә безнең һөҗүм башлана.

Кар сибәли башлады. Моңа бик шатландык, буран безнең эзләрне каплый. Аннары инде тап син разведчикларны!

Бер сәгать чамасы киткәч, ниһаять, күпер янына җиттек. Бу күпернең алдагы ике күпердән зуррак икәне, аны саклаулары безгә билгеле. Ләкин күзәтү монда сакчы-фәлән булуын тапмады. Күпер өсте буп-буш. Нәрсә бу, сакчыларның салкыннан җылыга посуымы, әллә бер-бер хәйләме? Менә без күпер астында инде. Иплә кенә шартлаткычларны куябыз, запалларны тоташтырабыз. Күпер ярты сәгатьтән соң шартларга тиеш. Күпер астыннан чыккач, иркен сулыш алабыз. Ләкин бер нәрсә борчый: гитлерчылар кая киткәннәр? Дошман ул хәтле үк юләр булмаска тиеш, күпер хәтле күперне саксыз калдырмас.

Без урман кырыена туктыйбыз. Бик күп вакыт үтте шикелле, ә күпер шартламый. Бу ни хәл? Әллә, ашыгу сәбәпле, караңгыда берәр нәрсәне буташтырдыкмы? Мин төнлә дә яктырта торган сәгатемә карыйм. Әле биш минут вакыт бар икән.

Моннан күпер чак-чак кына шәйләнә. Анда һаман тыныч.

— Гвардия өлкән сержанты, кара!— дип пышылдый бер разведчик шул чакта.— Сакчы бугай.

Хәзер мин дә ачык шәйлим. Әнә ул күпергә ашыкмый гына якынлаша. Безнең эзләрне генә күрмәсен. Җитмәсә, буран да туктады.

Һәм кинәт, тирә-якны яңгыратып, күпер шартлады. Без күккә сикергән ялкынга бераз карап тордык та бер-беребезне кочарга, үбәргә, тәбрикләргә тотындык. Аннары кузгалдык. Хәзер капчыклар юк инде, кош кебек очабыз. Күңел күтәренке, кычкырып җырлыйсы килә. Урман үзе дә җырлый кебек. Җыры бик таныш сыман. Чү, бу «Сагыну» ич! Елмаеп, күз алдына Мөслимә килә. Миңа тагын да рәхәт булып китә. Шулай рәхәт кичереп, иптәшләр янына да килеп җитәбез. Алар шартлау тавышын ишеткәннәр, безне тәбрикләргә тотыналар, ә мин:

— Ә сездә эшләр ничек?— дип сорыйм. Җавап урынына бер-бер артлы ике шартлау ишетелә. Барысы да ачык. Мин иптәшләрнең кулларын кысам.

Күңел тынычлана барды. Ләкин разведкага кайдан нинди куркыныч янавын берәү дә алдан белми шул. Үзәнлек буйлап барганда, безгә кинәт ут ачтылар. Үзәнлекнең көнбатыш битендә ниндидер бер кечкенә авыл күренә. Анда да гитлерчылар тревога күтәрделәр, тәртипсез атышлар башланды. Безне урап алдылар. Башка чара булмагач, түгәрәк оборона тотып, без дә дошманга ут ачтык. Мин көчләрнең тигез түгеллеген күрдем. Ләкин иртә белән безнең частьлар һөҗүмгә күчәргә тиеш. Берничә сәгать тора алсак, шул җитә.

Ак кар өстендә гитлерчылар ап-ачык күренә. Алар берничә йөз кеше, без уналты! Калтырап төштекме? Юк! Ярты сәгать эчендә егерме-утыз дошманны кырып салдык. Ләкин гитлерчылар безне тереләй алмакчылар бугай. Юк, алмый торыгыз әле! Мин автоматтан чуплим. Башка иптәшләр дә тик ятмыйлар.

Булмады, мине яраладылар. Шуннан соң ни булганын, сугыш күпме дәвам иткәнен белмим.

Аңыма килгәндә, мин ниндидер авыл өендә идәндә ята идем. Күрәсең, инде таң атып килә, тәрәзә пыялалары зәңгәрләнгән. Өстәлдә керосин лампасы. Әле аңым ачыклана, әле тагын караңгы упкынга очып онытылам.

— Гут, гут,— диде немец офицеры, минем өстемә иелеп,— без сезнең нәрсә эшләп йөрүегезне беләбез... Совет гаскәрләре кайчан һөҗүм итә башлый? Безнең алга тагын нинди частьлар килде?

Мин дәшмәдем. Өстәлдә әллә нинди шешәләр тора. Күрәсең, мине аңга китерер өчен күп тырышканнар.

— Без илебезгә турылыклы!— дидем мин.

— Руслар кайчан һөҗүм итә башлыйлар, сәгате? Я, тиз бул!

Гитлерчының бу соравын мин кайдандыр, кара томан эченнән генә ишеттем. Мин аңа җавап бирмәдем. Мине кызган шомпол белән җәзалый башладылар. Үзләре һаман җикеренәләр, кычкырыналар, сүгенәләр. Аңны җуяр минутта минем колагыма «Сагыну» моңы ишетелде, күз алдыма Мөслимә килеп басты. Аның йөзе хәсрәтле. Мин аны юатыр өчен нидер әйтә башлаган идем, күз алларым караңгыланып китте, тәнемне тагын кызган шомпол белән көйдереп алдылар.

Гитлерчы үзенең соравын кабатлады, алар ашыгалар иде булса кирәк, һаман-һаман сәгатьләренә карыйлар. Карагыз, кара, кабахәтләр, актык сәгатьләрегез җитә.

— Я, соңгы мәртәбә сорыйбыз...

Мин эндәшмәдем. Мин тагын Мөслимә белән идем. «Бәгырем, Малик, мин сиңа ышанам!» — диде ул. Әйе, әйе, ышан, Мөслимә! Мин алдамам, мин илемә турылыклы булып калырмын!

Мин шыпырт кына гитлерчыны дәшеп алдым.

— Миңа сөйләве авыр, иелә төшегез, әйтәм,— дидем. Фашист тиз генә минем өстемә иелде. Мин аның кабахәт йөзенә лачт итеп төкердем дә:

— Эт!— дидем.

Гитлерчы ачуыннан шартларга җитте, пистолетын суырып алды да миңа таба атып җибәрде. Ләкин мин һаман үлмәгән идем әле. Еракта безнең артиллерия үкерә башлавын ишеттем. Аның гөрелтесе тоташ бер тантанага әверелде.

Үтәр еллар, бик күп еллар үтәрләр, ә без һаман унтугызда булырбыз. Бик күп буыннар, безнең мәңгелек һәйкәлләргә карап:

— Алар фашизмга каршы көрәштә гомерләрен кызганмаганнар, алар халыкларны коллыктан коткарганнар,— диярләр.

Безгә башка дан кирәкми.

Сораулар һәм биремнәр.

1. «Сагыну» җырын (З. Хәбибуллин музыкасы, М. Җәлил шигыре) язмада тыңлагыз. Аны үзегез дә җырларга өйрәнегез.

2. «Сагыну» җыры Маликкә ничек тәэсир итә? Туган моң сугышчыга бик авыр вакытларда да көч, дәрт өсти. Моның сәбәбе нидә дип уйлыйсыз?
3. Маликнең батырлыгы, түземлелегенең нигезе нәрсәдә?
4. Хикәянең бу соңгы өлешенә сез нинди исем бирер идегез?
5. Сугышчыларны хөрмәтләп куелган һәйкәлләр янына килеп баскач, сез нинди хисләр кичерәсез?
6. Авылыгыздагы, шәһәрегездәге сугыш каһарманнары истәлегенә куелган һәйкәлләрне карап-тәрбияләп торыгыз.
7. Әсәрне табып, тулысынча укып чыгыгыз.
8. «Сагыну» җыры» дигән темага сочинение языгыз.

йөрәкне чеметә — йөрәкне кузгата, хисләрне нечкәртә
«Сандугач» искә төштеме? — *монда*: яраткан кызың искә төштеме?
тирән сукалыйсың — *монда*: мәгънәле итеп сөйлисең
посуымы — качуымы
аңны җуяр — аңны югалтыр

БӨРЕЛӘНДЕ, ЧӘЧКӘ АТМАДЫ

(«Миңа унтугыз яшь иде» әсәре турында)

Унтугыз яшь — кеше гомеренең иң матур һәм бәхетле вакыты. Киләчәккә зур өметләр баглаган бер чор бу.

Әсәрнең каһарманы Малик — урта мәктәпне тәмамлаган Казан егете. Әти-әнисе — гади хезмәт кешеләре. Маликне дә хезмәт сөючән итеп тәрбиялиләр. Әтисе ярдәме белән ул тормышта кирәкле һөнәрләрне өйрәнә. Спорт белән шөгыльләнү юлын да аңа әти-әнисе күрсәтә.

Малик өчен әле тагын бер бик якын кеше бар, ул — Мөслимә исемле кыз. Мөслимә дә аңа битараф түгел.

Малик белән Мөслимә бик бәхетле булырлар иде. Ләкин 1941 елның 22 июнь таңында фашистлар Германиясе безнең илебезгә явызларча басып керде. Малик тә кулына корал алырга тиеш булды.

Өйдә чакта да бер эштән дә курыкмаган, спорт белән дә шөгыльләнгән егет өчен сугыш шартларына күнегү әллә ни кыен булмый. Дошманга каршы көрәшнең серләренә тиз төшенеп ала Малик. Аны разведчик кебек иң хәтәр хезмәтләрнең берсенә алулары да күп нәрсә турында сөйли.

Ләкин кеше нинди генә шартларда да кеше булып кала. Аңа әти-әнисе, туган теле, сөйгәне, халкының моңнары бик тә

кадерле. Шәһәрдәше Мөнир белән очрашкач, алар кат-кат «Сагыну» җырын тыңлыйлар, туган якның газиз моңы сагыну хисен тагын да көчәйтә. Малик сугышчан бурычны үтәгәндә дә, дошман кулында рәхимсез җәзаланганда да шушы җыр тәэсирендә була. Мөслимәсе һәм «Сагыну» җыры аның рухын ныгыта, көчен арттыра. Шушы җырның моңнары астында ул якты дөнья белән саубуллаша. Менә нинди могҗизалы көчкә ия ул җыр!

Хикәянең төзелеше дә укучыга тәэсир итү көчен арттырырга ярдәм итә. Иң әүвәл каһарман «Мине 1941 елның декабрендә Мәскәү янындагы сугышларда үтерделәр» дип әйтеп куя. Укучы сискәнеп китә. Кара әле, үзе үлгән, ә үзе башыннан кичергәннәре турында хикәя кыла. Алай була алмый бит!

Әйе, чын тормышта алай була алмый. Ләкин әдәбиятта һәм сәнгатьтә булуы бик мөмкин. Чөнки сәнгатьнең үз кануннары бар. Мисал итеп бәетләрне алырга була. Аларның байтагында сүз үлгән кеше авызыннан сөйләтелә. Мәсәлән:

Безнең сафлар бара иде дошманга таба омтылып,
Явыз немец пулясыннан калдым мин шунда егылып.

Дусларым, җансыз тәнемне туган җиремә күмегез.
Батыр булып үлде диеп өйгә хәбәр җибәрегез.

(*«Илем өчен җаным бирдем» исемле бәеттән*)

Болай язу әсәрнең укучыга тәэсир итү көчен нык арттыра. Г. Әпсәләмов та шушындый ук алым куллана.

Шушы җөмләдән соң хикәяләүче үзенең фронтка килүен, беренче сугышчан бурычларны үтәргә керешүен яза да малай чакларын искә төшерә башлый. Сугыш һәм тыныч тормыш капма-каршы куела, ягъни чагыштырыла. Моңа егет белән кызның мөнәсәбәтен сурәтләү дә өстәлгәч, гомумән, әсәр матурланып, балкып китә. Малик белән Мөслимәгә без инде гадәти кешеләргә караган кебек кенә карый алмыйбыз. Алар ниндидер серле, бик тә матур булып тоелалар. Шуннан соң сугыш тагын да кыргыйрак, кешелек өчен хас булмаган күренеш кебек тоела башлый. Сугыш араларында татар егетләренең бик газиз булган «Сагыну» җыры белән очрашулары әсәрне укучының күңелен тагын нечкәртеп җибәрә. Шушы ук җыр, унтугыз яшьлек егетнең гомере киселгәндә дә, аның колагында яңгырый кебек тоела. Биредә без җыр сәнгатенең кеше өчен никадәр зур тәэсиргә ия булуын күрәбез.

Теләсә кайсы сугышны без изге максатлы дип саный алмыйбыз. Әмма Малик, Мөнир кебекләр катнашкан Бөек Ватан сугышы изге сугыш иде. Чөнки анда халкыбыз үз туган җире, әби-бабалары, әти-әниләре, газиз балалары өчен сугышты. Бу сугышта Татарстаннан гына да йөзләрчә мең кеше һәлак булды. Алар арасында Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш кебек язучылар да бар иде.

Безнең җиңү әнә шундый миллионнарча корбаннар исәбенә яуланды. Шуңа күрә без аларны хөрмәтләп искә алабыз, данлыйбыз, беркайчан да онытмыйбыз.

«Батыр егет — ил күрке» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Батырлык дигән сүз үз эченә нинди сыйфатларны ала?

2. Суга батучыны коткару, үз тормышыңа хәвеф килү мөмкинлеген онытып, янгын эчендәге кешене алып чыгу кебек батырлыклар белән сугыш кырында ил азатлыгы өчен кылган каһарманлык арасында нинди охшаш һәм аермалы якларны күрәсез? Тыныч тормышта тагын нинди батырлыклар эшләп була?

3. Батырлык ир-егетләр эше генә, дип әйтү дөрес булырмы?

4. Батырлар турында нинди китаплар укыганыгыз бар, нинди кинофильмнар карадыгыз? Берсе турында сөйләгез.

5. Сезнең туганнар, дуслар арасында батыр исемен йөртерлек кешеләр бармы?

6. Түбәндә бирелгән мәкаль һәм әйтемнәрне сез ничек аңлыйсыз?

Батыр ярасыз булмас.
Батыр яуда беленер.
Батыр үзе өчен туар, кеше өчен үләр.
Батырлыкта — матурлык.
Батыр үзе үлсә дә, исеме үлмәс.

7. Батырлык турында тагын нинди мәкальләр, әсәрләр беләсез? Әңгәмәне дәвам иттерегез.

Һади Такташ
(1901—1931)

Бөек Тукайдан соң поэзиядәге күренекле бер вакыйга буларак... Такташ килеп чыкты. Эшләрне, укытуларны ташлап, Такташлы Казанга килдем.

Хәсән Туфан

Һади Такташка үзенең иҗат юлында бик катлаулы һәм каршылыклы юллар үтәргә, күп киртәләрне атлап чыгарга туры килә. Ул, барлык кыенлыкларны җиңеп, кыю адымнар белән әдәбият юлына таба баруын дәвам иттерә һәм егерменче гасыр башының ялкынлы җырчысы булу дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул — татар әдәбиятын алга таба үстерүгә зур өлеш кертүчеләрнең берсе.

Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга таба юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...—

дип язды ул. Болар чын күңелдән әйтелгән ихлас сүзләр иде.

Һади Хәйрулла улы Такташев (Һади Такташ) 1901 елның 1 гыйнварында элекке Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордва Республикасы Торбеев районы) Сыркыды авылында крестьян гаиләсендә туа.

Булачак шагыйрьгә бала чагында зур йогынты ясаган кеше аның әнисе Шәмсениса апа була. Шәмсениса апаның истәлекләрендә дә, хатларында да улына кайнар мәхәббәте, кайгыртучанлыгы ачык сизелә. Анасына мәхәббәте, тирән, матур хисләре шулай ук шагыйрьнең үз әсәрләрендә дә чагыла.

Шәмсениса апа белән Хәйрулла абый көчләре җиткән кадәр үз балаларын укытырга, алдынгы кешеләр итәргә тырышалар. Кечкенә Һади хәреф танырга үз анасыннан өйрәнә. Һади әнкәсенең җылы сүзләрен ишетеп, матур әкиятләрен һәм

җырларын тыңлап, сизгер күңелле бала булып үсә. Күпләгән авыл балалары кебек үк, Һади да кечкенәдән үк эшкә өйрәнә. Мал-туар карау, ат саклау, ат коендыру, җир тырмалау, печән чабу аның яраткан шөгыльләре була.

Һади башта туган авылындагы мәдрәсәдә белем ала. Бераздан ата-анасы Һадины Сыркыдыдан утыз чакрым ераклыктагы Пешлә авылы мәдрәсәсенә илтә. Һади моңа үзе дә бик шатлана. Чөнки Пешлә мәдрәсәсе якын-тирәдәге иң атаклы мәдрәсәләрнең берсе булып танылган, анда география һәм тарих фәннәрен дә укытканнар, шулай ук балаларның әдәби телне, әдәбиятны үзләштерүләренә дә аеруча игътибар биргәннәр. Булачак шагыйрь зур теләк белән укырга керешә. Малай биредә төрле фәннәр һәм матур әдәбият белән якыннан таныша башлый. Мәдрәсәгә килгән газеталар һәм журналларны да, яңа әдәби әсәрләрне дә укып бара. Аның яшь күңелендә бигрәк тә Габдулла Тукай һәм Сәгыйт Рәмиев шигырьләре тирән эз калдыралар.

Һади тырышлыгы, зирәклеге белән үзен бик тиз таныта, алдынгы укучыларның берсе була, иптәшләре аны яраталар, мөгаллимнәре дә хөрмәт итәләр. Ул кышларын Пешләдә укый, җәен авылына кайта, кыр эшләрендә һәм хуҗалыкта әти-әнисенә булыша.

Һадида бик яшьтән әдәбият белән кызыксыну уяна. Бала күңелендә шагыйрьлек чаткыларын әнисе кабызган. Ана улына халык җырларын, бәетләрне матур итеп җырлап һәм сөйләп күрсәтә торган булган. Шәмсениса апа үзе дә җырлар чыгарган. «Минем шагыйрьлегемә әниемнең дә зур тәэсире бар»,— дип яза Такташ үзенең бер истәлегендә. Һадиның әнисе халык шигърияттен якын иткән, гади вакыйгаларны да матур итеп, күңелгә үтемле итеп сөйләве белән танылган. Шәмсениса апаның улына язган хатларында да җырлар еш очрый.

Пешлә мәдрәсәсендә Һади өч кыш укый. 13—14 яшьләрендә инде Һади үзендә шагыйрьлек сәләте барлыгын тоя. Газизә исемле бер нәни кызга багышлап «Кара күзләр» дигән шигырь яза.

1912—1914 елларда алар тормышында зур гына кыенлыклар туа. Беренче бөтендөнья сугышы аларның хәлен тагын да авырайта. Хуҗалыклары тарала башлый, халык өстенә килгән кайгы-хәсрәт аларны да читләтеп үтми. Башта Һадиның абыйсы Хафиз эш эзләп читкә китәргә мәҗбүр була. Аннан соң Һадига да нәүбәт җитә: берәр байга хезмәтче булып үз тамагын туйдырыр һәм йортка да ярдәме тияр дип, аны

Бохарага озаталар. Байлар кибетендә ул хезмәтче малай булып эшли.

Бохарада Һади тормыш төбендә тапталып калырга теләми. Ул үзенең белемен күтәрергә омтыла, җәмәгать эшләрендә кайный, спектакльләрдә катнаша. Гомумән, яшьләр арасында мәдәни-агарту эшләре алып бару һәм үзенең мондый омтылышларына теләктәшлек иткән кешеләр белән аралашу Һадиның әдәби иҗатка булган дәртен тагын да арттыра. 1916 елда язылып та, үз вакытында басылмый калган «Газраилләр» һәм «Караңгы төннәрдә» кебек әсәрләрен Такташ иҗатының әнә шул чордагы беренче җитди иҗат җимешләре дип карарга кирәк.

1918 елның җәендә ул, туган якларына кайтып, берникадәр вакыт педагогия курсларында укый һәм Сыркыдыда укытучы булып эшли. Шигырьләр язуын да дәвам итә. Шулай да күңеле шәһәргә омтыла. 1920 елның көзендә Оренбургка китә. Монда язучы Афзал Таһиров белән таныша. А. Таһиров аңарда, әдәбиятка омтылган яшь егеттә, зур талант барлыгын күреп ала һәм аны «Юксыллар сүзе» газетасына сәркатип итеп урнаштыра. Монда да ул иҗат һәм җәмәгать эшендә өлгерлеген һәм тырышлыгын күрсәтә. 1921 елгы ачлык вакытында Һади Ташкентка китәргә мәҗбүр була. Әмма каләмен кулыннан төшерми. Аның «Онытылган ант», «Таң кызы», «Урман кызы», «Нәләт» һәм «Җир уллары трагедиясе» кебек романтик әсәрләре Ташкентта языла.

1922 елда Урта Азиядән Казанга кайткач, аңарда яңа фикерләр, яңа хисләр уяна, чынбарлыкны җырлауның моңа кадәр кулланылмаган мөмкинлекләрен эзләргә керешә. Башта ул театрда суфлер була, аннан соң «Чаян», «Авыл яшьләре», «Азат хатын», «Яңалиф» кебек журнал редакцияләрендә эшли. Һ. Такташ үзен өметле яшь талант итеп таныта. Ниһаять, 1923 елда аның «Җир уллары трагедиясе» дип аталган беренче җыентыгы басыла.

Һ. Такташ барыннан да элек шагыйрь буларак танылa. Әмма ул башка жанрларны да читт итмәде. Мәсәлән, «Күмелгән кораллар» (1927), «Югалган матурлык» (1928) һәм «Камил» (1930) исемле драма әсәрләрен һәм хикәяләр дә язды.

Газета-журналларда озак вакытлар эшләү дәверендә шагыйрьнең журналистлык таланты да ачыла. Заманның күп төрле темаларына багышлап, ул мәкалә, очерк һәм фельетоннар язды.

Әмма 1931 елның 8 декабрендә халыкның сөекле шагыйре вакытсыз вафат булды. Аны Казанның Үзәк мәдәният һәм ял паркындагы туганнар каберлегенә җирләделәр.

Бу татар әдәбияты өчен бик зур югалту булды. Такташка бары 30 яшь кенә иде. Аның бик күп җырланасы җырлары калды.

Иң әһәмиятлесе: аның мәңге сүнмәс иҗаты халыкта яши. Чын мәгънәсендә ул — халык шагыйре, татар халкының сөекле, ялкынлы җырчысы.

Сораулар һәм бирем.

1. Шагыйрь булып китүендә Һ. Такташка кемнәрнең йогынтысы булган?
2. Пешлә мәдрәсәсе Такташ өчен кайсы ягы белән әһәмиятле?
3. Һадины ни өчен Бохарага җибәрәләр?
4. Иҗатын ул кайсы шәһәрдә башлый?
5. Казанда яшәү аңа иҗатында ничек ярдәм итә?
6. Шагыйрьнең нинди әсәрләрен беләсез?
7. Һ. Такташ шигырьләренә язылган җырларны беләсезме?
8. Һ. Такташ тагын нинди жанрларда язган?
9. Такташның каберенә чәчәкләр салыгыз, шунда аның шигырьләрен укыгыз.

асылып — үрмәләп, асылынып
губерна — элекке Россиядәге өлкә
өяз — губернаның состав өлеше
нәүбәт — вакыт, чират
фельетон — тормыштагы теге яки бу кимчелекләрдән ачы көлеп язылган әсәр

ИПТӘШЛӘР

Беребезгә беребез нинди охшаганбыз,
Икебез дә соры шинельле,
Икебез дә шундый күңелле...
Син көләсең миңа карыйсың да,
Ә мин, тиле,
Кочакларга әзер үзеңне,
Танышлар да түгел үзебез,
Ләкин синнән
Ала алмый карыйм күземне.
Нинди охшаганбыз,

Ничек охшаганбыз,
Бертуганнар дисәң,
Мин — Тамбовтан, ә син —
Казан артыннан;
Мин бер мишәр улы, кыргый үскән,
Ә син
Күрше чуваш халкыннан...

Нинди охшаганбыз бер-беребезгә,
Икебез дә соры шинельле,
Киемнәр дә бер үк, теләкләр дә,
Бер үк хисләр чолгый күңелне.
Аерылганда миннән,
Туганыңнан аерылган күк моңсу калырсың;
Илне саклау өчен чакыру килсә,
Беләм,
Мин беренче барсам,
Син миннән дә элек барырсың.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьдә нинди иптәшләр турында сүз бара?
2. Иптәшләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте ничек сурәтләнә?
3. «Ала алмый карыйм күземне», «Бер үк хисләр чолгый күңелне» дигән сүзләргә нинди мәгънә салынды икән? Шуны ачыклагыз.
4. Ни өчен шигырьдәге бер дус «кыргый үскән» дип бирелә?
5. Чуваш милләтеннән булган дус әсәрдә ничек сурәтләнә?
6. Сезнең мәктәптә кайсы милләт балалары укый? Сез аларны нинди сыйфатлары өчен хөрмәт итәсез?
7. Шигырьне ятлагыз һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнегез.
8. «Минем дустым» темасына кечкенә күләмле сочинение языгыз.

иптәшләр — дуслар (товарищи, друзья)
охшаганбыз — уртак билгеләребез, сыйфатларыбыз бар (похожи)
соры — төсне белдерүче сүз (серый)
кочакларга — обнимать, обнять
бертуганнар — бер үк ата-ана балалары (родные)
теләкләр — берәр нәрсәне теләү, максат итеп кую (желания)
хисләр — күңел белән сизү, тою (чувства)
моңсу — кәефсез (грустный)

ДУСЛЫК ЯШЬТӘН БАШЛАНА

(«Иптәшләр» шигыре турында)

Һади Такташның «Иптәшләр» (1927) шигыре — балалар тарафыннан яратып укыла торган әсәрләрнең берсе. Без анда лирик геройның үз халкына, башка милләт вәкилләренә булган әйбәт карашын күрәбез, кешеләргә карата ягымлы мөнәсәбәтен сизәбез.

Шигырьдә уй-хисләрне һәм эчке кичерешләрне үз исеменнән сөйләп бирүчене **лирик герой** дип йөртәләр.

Лирик геройның кичерешләре аша бу очракта шул чорның аерым бер иҗтимагый төркеменә хас фикерләр, хисләр белдерелә. Шунлыктан шагыйрьнең мин дип язуын бары тик аның үз кичерешләрен белдерүе дип кенә карарга ярамый. Ул үз иҗатында гомумиләштергән образны — лирик геройны барлыкка китерә. «Иптәшләр» шигырендә Һади Такташ бөтен күренешне лирик герой кичерешләрендә сурәтләп бирә.

Ул халыкның көченә, төрле милләт кешеләренең бер-берсен аңлап яшәячәгенә, туган иленең гөрләп үсәчәгенә ышаныч белән карый. Татарлар белән чувашлар элек-электән тату, дус яшәгәннәр, Һ. Такташ та моны җырламый кала алмаган. Хәзер дә туган Татарстаныбызда төрле милләт кешеләре дуслык, тынычлык, муллык булдыру өчен тырышып эшлиләр, яхшы мөнәсәбәтләрне сакларга һәм үстерергә тырышалар.

«Иптәшләр» шигыре халкын, илен чын күңелдән яраткан шагыйрь тарафыннан язылган. Шигырьнең төзелеше дә бик үзенчәлекле. Һ. Такташ шигырьне тигез генә итеп, җырларга җайлаштырып язмый, бәлки сөйләүгә уңай итеп иҗат иткән. Әсәрнең яңгырашына, тукталышларына, төп фикерне ачучы сүзләргә басым ясый. Һ. Такташның сүзгә бай булуына, халык телен нечкә белеп эш итүенә, рифмалар төрлелеген куллану осталыгына сокланасың. Аның шигырьләре җиңел укыла, бик тиз хәтердә кала.

Нәрсә соң ул рифма? **Рифма** — шигырь юлларының аваздаш, охшаш яңгырашлы булып тәмамлануы.

Мәсәлән:

...Туганыңнан аерылган күк моңсу калырсың;
Илне саклау өчен чакыру килсә,
Беләм,
Мин беренче барсам,
Син миннән дә элек барырсың,—

дигән шигъри өзектә «калырсың», «барырсың» сүзләренең соңгы ике иҗекләре бер үк авазлардан тора. Рифма ачык һәм ябык иҗекле була. Рифмалашкан сүзләр тартык авазга бетсә, рифма — **ябык иҗекле**, ә сузык авазга тәмамланса, **ачык иҗекле** була. «Калырсың», «барырсың» сүзләре «ң» дигән ябык авазга бетә, шуңа күрә бу рифмалар ябык иҗекле була.

...Кочакларга әзер үзеңне,
Танышлар да түгел үзебез,
Ләкин синнән
Ала алмый карыйм күземне.

Бу мисалда исә рифмалашкан «үзеңне», «күземне» сүзләре сузык авазга тәмамлана. Димәк, ачык рифма була.

Дуслык, иптәшлек турында фикер алышу өчен сораулар

1. *Дуслык, иптәшлек* сүзләренең мәгънәсен ничек аңлыйсыз?

2. Ничек уйлыйсыз: дуслашу, танышу өчен кешеләрнең яшьләре, һөнәрләре, нинди милләттән булулары комачаулык итәме? Мисаллар белән сөйләп аңлатыгыз.

3. Татарстанда яшәүче күп төрле милләт халыкларының дуслыгы сугыш елларында ничек чагылды? (Өлкәннәрнең сөйләве, әдәби әсәрләрдән алган мәгълүматлар буенча аңлатыгыз.)

4. Дуслык, иптәшлек тыныч хезмәт шартларында ничек күренә?

5. Сезнең мәктәп укучылары арасында иптәшлек, дуслык, үзара ярдәмләшү ничек тора? Сыйныфыгыздагы иптәшлек, дуслыкны ничек бәялисез?

6. Сезнең мәктәптә дуслык клублары эшлиме? Башка дәүләтләрдә яшәүче яшьтәшләрегез белән хатлар алышасызмы, аралашасызмы?

7. Татар язучыларының сез укыган кайсы әсәрләрендә дуслык, иптәшлек хисләре мактала? Шулар турында сөйләгез.

Мәкальләр һәм әйтемнәр

Дуссыз башым — тозсыз ашым.
Кош — канаты белән, кеше дуслык белән көчле.
Начар дустан сөрем йогар.
Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсачы.
Дусың нинди — кадерең шундый.
Дусың булмаса — эзлә, тапсаң — югалтма!
Иптәшең үзеңнән яхшы булсын.
Дуслык калаларны ала.

Дус белән дус булганга шатлан,
Дошман белән дус булудан саклан.

Дусларның теле каты тоелса да, күңеле йомшак була.
Дуссыз кеше тамырсыз агач кебек.

Йөрәк үз дусын таныр.

Дус булсаң, дуслыгыңны күрсәт,
Бүрәнәнең авыр башын күтәр.

Дустың булса, сукмагына үлән үстермә.

Җәүдәт Фәйзи
(1910—1973)

Бу исем музыка сөючеләр күңелендә горурлык һәм соклану хисе тудыра. Чөнки аның татар музыкасына керткән өлеше бик зур.

Җәүдәт Фәйзи (Җәүдәт Харис улы Фәйзуллин) 1910 елда Оренбург шәһәрендә укытучы гаиләсендә туган. Башлангыч музыкаль белемне дә шул ук шәһәрдә ала. Егерменче елларда Түбән Новгород якларындагы Ишә авылында укытучы булып эшләгәндә, авыл үзешчән сәнгать көчләрен оештыру тәҗрибәсе туплый. Инде шул елларда ук үзенең беренче әсәрләрен дә иҗат итә башлый. Башта әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Хикәяләр һәм шигырьләр яза, алар басылып та чыга. 1932 елда Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлый. Ул икеләнеп кала: хокук белгечлеге буенча эшләргәме, әллә иҗат юлыннан китәргәме? М. Җәлил аңа болай дип киңәш итә: «Островский да, Чайковский да, Шуберт та юрист булганнар. Синең дә югары белемле булуың язучылыкка да, композиторлыкка да комачаулык китерми, киресенчә, зур ярдәм генә булачак. Әдәби талантыңмы, әллә музыкага булган зур мәхәббәтеңме — кайсысы җиңәр, анысын хәзергә билгеләп булмый, киләчәк күрсәтер...»

Җәүдәт Фәйзинең музыка дөньясы белән мавыгып китүенә Салих Сәйдәшев, Александр Ключаревлар белән аралашып яшәвенең дә йогынтысы зур була. Ниһаять, ул ныклы карарга килә: композитор булу аның күңеленә аеруча якын икән. Шуңа күрә ул 1934 елда Мәскәү консерваториясе каршында оештырылган Татар опера студиясенә укырга керә, аны 1938 елда уңышлы тәмамлый. Аннан соң Г. Камал исемендәге Татар

дәүләт академия театрының музыка бүлеге мөдире булып эшли.

Җәүдәт Фәйзи — татар музыкаль комедия жанрын үстерүгә күп көч куйган һәм шул өлкәдә уңышлы эшләп килгән композитор. Аның «Башмагым» музыкаль комедиясе татар һәм рус телләрендә илебезнең күп кенә сәхнәләрендә куелды һәм уңыш казанды. Ул — «Акчарлаклар» (Ә. Фәйзи либреттосы), «Идел буенда» (Г. Насрый либреттосы) музыкаль драмалары һәм «Тапшырылмаган хатлар» (Г. Кутуй повесте буенча) операсын язган, күпләгән драма әсәрләрен музыкаль аһәң белән баеткан композитор да. Аның җырларында татар халкының үткәне, хәзергесе, азатлык, тынычлык өчен көрәше, хезмәт уңышлары сурәтләнә. «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» (С. Хәким шигыре), «Гөлшаһидә җыры» (Г. Әпсәләмов шигыре), «Яшь наратлар» (И. Юзеев шигыре) һәм башка көйләре халкыбызның яраткан җырларына әйләнделәр.

Җәүдәт Фәйзи балалар өчен дә җырлар яза. Ул утызынчы елларда М. Җәлил белән бергә «Беренче дәрес», «Чишмә» җырларын иҗат итә. Талантлы ике автор иҗади дуслыкны алга таба да дәвам иттерәләр. Табигатьне яратырга, аның серләрен аңларга өндәгән «Әтәч», «Маэмай» җырларын балалар үз итәләр. «Карак песи», «Сәгать» кебек юмористик җырлары да еш башкарыла.

Җ. Фәйзи балаларны музыка кораллары белән таныштыруга да әһәмият бирә. Ул, мәсәлән, «Кызыклы кунаклар» исемле китабын яза. Әкият рәвешендә язылган бу китап малайларны һәм кызларны серле музыка дөньясына алып керә.

Җәүдәт Фәйзи — халык көйләрен җыю, өйрәнү, эшкәртеп халыкка кайтаруга да зур көч куйган композиторларның берсе. «Халык җәүһәрләре» китабының (1971) әһәмияте аеруча зур булды. Ул җыентыкка 235 җырның ноталары, сүзләре урнаштырылган. Аларның тарихы бирелү китапның кыйммәтен тагын да арттыра.

Җәүдәт Фәйзи Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, халык артисты, Республикабызның Габдулла Тукай бүләге лауреаты дигән мактаулы исемнәргә лаек булды.

Һ. Такташның үлүенә бер ел тулу уңае белән аны искә алу кичәсендә беренче тапкыр яңгыраган «Урман кызы» көен халык аеруча үз итте. Аны башка милләтләр дә яратып җырлый. Ә хәзер шушы җыр белән танышыйк.

Һади Такташ

УРМАН КЫЗЫ

Нигә, нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан тамалар?

Кайчак күзләреңнән көчләр алып,
Бөеклеккә таба ашам мин.
Ә кайчакта башым түбән иям,
Әй, Әминәм, синнән качам мин.

Син кем, белмим, синең шаян күзләр
Нигә, белмим, болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, әй, аппагым,
Керфек очларыңнан тамалар?

Сораулар һәм биремнәр.

1. Җәүдәт Фәйзинең иҗади табигатьле малай булуын ниләрдән күреп була?
2. Муса Җәлилнең киңәше турында ни уйлыйсыз?
3. Җ. Фәйзи һәм М. Җәлил тормышында Оренбург шәһәре нинди урын тота?
4. Җәүдәт Фәйзинең музыка дөньясына кереп китүенә нәрсә сәбәп була?
5. Композиторның беренче уңышлы әсәрен атагыз. Аның язмасын тыңлагыз. Үзегез дә җырларга өйрәнегез.
6. Композитор кайсы шагыйрьләр белән иҗади дуслыкта яши?
7. Җ. Фәйзи музыка сәнгатенең кайсы юнәлешләрендә эшли?
8. Җәүдәт Фәйзинең иҗаты һәм эшчәнлеге ничек бәяләнде?
9. Җ. Фәйзи тарафыннан язылган җырларның исемнәрен әдәбият дәфтәрегезгә языгыз.
10. Балалар өчен язган әсәрләрен табып тыңлагыз һәм өйрәнегез.

аппагым — яратып әйтә торган сүз (светик мой)
керфек — ресница

«Концерт тыңлагач» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Сез *концерт* сүзен ничек аңлыйсыз?
2. Концертта кемнәр катнаша?
3. Җырчы булу өчен нинди талантка ия булырга кирәк?

4. Җырчыларны кайсы югары яки махсус уку йортларында әзерлиләр?

5. Җырларны кемнәр иҗат итә?

6. Сез тыңлаган концертта кайсы композиторларның җырларын башкардылар?

7. Халык җырларын башкаручылар булдымы, булса, кайсы артист күңелләргә үтеп керерлек итеп башкарды?

8. Концерт программасын алып баручыны кем дип атап йөртәләр? Алып баручының роле нидән гыйбарәт?

9. Татар халкының нинди музыка уен коралларын беләсез, концертта шуларның кайсысын күбрәк кулландылар?

10. Нәфис сүз остасы дип кемнәрне әйтәбез? Татар халкында танылган нәфис сүз осталарын атагыз.

11. Концертта нинди биюләр башкарылды? Иң таралган татар халык биюләренең исемнәрен әйтегез.

12. Концертның уңышы, талантлы башкаручылардан тыш, тагын кемнәр эшчәнлегенә дә бәйле?

13. Тамашачы концерт белән мавыксын, аны яратып кабул итсен өчен, төп шарт булып нәрсә тора?

14. Эстрада җырчысы белән опера җырчысы арасында нинди аерма бар?

15. Син яратып карый торган концерт нинди булырга тиеш?

Ибраһим Гази

(1907—1971)

Татар әдәбиятының талантлы әдипләре арасында Ибраһим Гази исеме дә хөрмәт белән телгә алына. Моңа ул күп еллар буена өзлексез иҗат итүе, халык яратып укый торган әсәрләре белән ирешә. Балалар әдәбиятын да Ибраһим Газидан башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Ибраһим Гази (Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев) 1907 елның 4 февралендә Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Карамалы авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Әти-әниләре үлгәч, 1919 елдан 1924 елга кадәр Тәтеш балалар йортында тәрбияләнә. Шунда урта белем ала. Аннан соң Казанда җитәкчеләр әзерләүче өчьеллык мәктәптә укый, яшьләр оешмаларында эшли.

1929 елда аны Казанда чыга торган «Кызыл яшьләр» газетасының редакторы итеп билгелиләр. Бер үк вакытта ул «Авыл яшьләре» журналының да редакторы була.

«Бригадир кыз», «Кичке алтыда», «Көмеш сулы Нурминкә» кебек әсәрләрендә Ибраһим Гази яшьләр тормышының төрле якларын ачып бирә. Шул әсәрләре аны язучы итеп таныталар да.

Бөек Ватан сугышы елларында И. Гази фронтта була. Ул, хәрби корреспондент буларак, алгы сызыкта окопларда йөри, батырлык күрсәткән сугышчылар белән очраша, алар турында хәбәр, очерк, мәкаләләр яза. Аның «Алар өчәү иде» исемле повесте Бөек Ватан сугышына багышланган уңышлы әсәрләренең берсе булып санала.

Сугыштан соң әдип, җиң сызганып, хикәя, повесть, романнар иҗат итү эшенә керешә, мәкаләләр яза, зур җәмәгать эше башкара, әдәби хәрәкәтнең үзәгендә тора. Шул елларда

аның «Без әле очрашырбыз», «Алмагачлар чәчәк ата» исемле повестьлары, дистәләрчә хикәяләре басылып чыга. «Гади кешеләр» романы, «Онытылмас еллар» трилогиясе иҗат ителә.

«Онытылмас еллар» трилогиясе И. Газиның зур иҗади уңышы булды. Татар әдәбияты әсәрләргә бик бай. Әмма татар крестьяннарының 1917 елгы вакыйгалар һәм шуннан соңгы тормышы моңарчы бу кадәр киңлек, тирәнлек белән тасвирлап бирелгәне юк иде. Илдә барган хәлләрнең кешеләр язмышына ясаган тәэсире анда көчле чагылдырылган, гыйбрәтле итеп сурәтләнгән.

Бу роман өчен аңа Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде.

Ибраһим Гази кырык еллап дәвам иткән әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге дәверендә халкыбызның язмышы өчен әрнеде, аның омтылышлары, хыяллары белән рухланып яшәде, әсәрләрендә хезмәт ияләрен кызыксындырган, дулкынландырган мәсьәләләрне күтәрде. Аның кайсы әсәрен генә алма, һәркайсында халкыбызның тормышы, азатлык өчен көрәше, батыр хезмәте, рухының, җанының сафлыгы, иң матур сыйфатлары чагыла.

И. Гази — шул ук вакытта тәрҗемәче дә. Ул рус теленнән күп кенә әсәрләрне татарчага тәрҗемә итеп бастырды. Үз әсәрләре дә рус һәм башка телләрдә таралды.

Тел остасы да иде ул. Халык телен һәм әдәби телебезне бөтен нечкәлекләренә хәтле белүче иде. Шуңа күрә аның әсәрләренең теле саф, нәфис, матур. Ул сурәтләгән кешеләр бөтен үзенчәлекләре, йөреш-торышлары, эчке һәм тышкы сыйфатлары, сөйләшү үзенчәлекләре белән җанлы булып күз алдына килеп басалар.

Ибраһим Гази һәрвакыт әдәби хәрәкәтебезнең үзәгендә булды. Гомеренең соңгы елларында ул Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе булып эшләде.

Сораулар.

1. И. Гази турында «ул үз тормыш сукмагын үзе салган» дип әйтеп буламы? Ни өчен?
2. И. Газиның кайсы әсәрләрен укыганыгыз бар? Нинди телдә?
3. Язучы булу өчен нинди сыйфатлар кирәк дип уйлыйсыз?

әдип — әдәби әсәрләр иҗат итүче танылган олы язучы
трилогия — авторның гомуми эчтәлек белән бәйләнгән өч әдәби әсәре

ЙОЛДЫЗЛЫ МАЛАЙ

Аларны җир казырга алып чыктылар. Алып түгел, куып. Фашистлар бөтен авылны куып алып чыкты. Картлар, хатын-кыз, бала-чага... Барысының да кулында көрәк. Барысы да җиргә таба бөгелеп төшкән. Уттай кызган ташлы туфракны казыйлар. Кичә дә казыдылар. Өченче көнне дә... Бер атна инде, һөҗүм итеп килүче Кызыл Армия танкларын уздырмас өчен, немецлар тирән чокырлар казыталар.

Кешеләр шундый ябыкты, коры сөяккә калдылар. Бертуктаусыз кояш астында... Битләре кара көйде. Көчкә кыймылдыйлар. Ә фашистлар өзлексез кызулап тора: «Арбайт! Шнеллы!»

Илгизәр дә ябыкты, зур күзләре генә утырып калды. Ашау юк дәрәҗәсендә... Шулай да Илгизәрнең ашыйсы килми, эчәсе килә. Көрәк белән кызыл балчыкны каерып аткан саен, көйгән иреннәрен ялап куя... Бер генә тамчы су булса... Ә тир ага: маңгаеннан да, муеныннан да... күзләренә агып керә, авызына...

Күкрәк турысына автомат аскан, кыска муенлы, юан аяклы сакчы немец, симез үрдәктәй чайкалып, ары-бире йөренеп тора... Аның аксыл кашлары астыннан чекрәеп торган кургаш күзләре бик үткен: кем көрәгенә таянган, кем ял итәргә чамалый, шундук күреп ала...

— Э, э, арбайт!— дип кычкырып, кургаш күз шундук автоматын җилкәсеннән сала башлый.

Соңгы көннәрдә сакчылар бигрәк зәһәр кылана башладылар. Чөнки Кызыл Армия килә, гомерләре кыскарды...

Хатыннар балаларны, үз артларына яшереп, хәл алдыралар. Шулай итмәсәләр, бу галәмәткә бала-чага күптән егылган булыр иде инде. Ә Илгизәр хатыннар артына ышыкланырга хурлана: ир кеше ич ул, яше уникедә генә булса да, ир заты... Кайнар таш өстенә хәлдән таеп егылса егылыр, хатыннар артына яшеренмәс. Кызуга чыдый алмый башлагач, ул күлмәген салып ыргытты. Беравыкка җиңелрәк булып китте.

Баш күтәреп карарга ярамый. Илгизәр иелгән килеш кенә көрәгенә таянып ял итеп ала. Шулай ял итеп торганда, колак төбендә үк диярлек фашистның җан биздергеч тавышы ишетелде:

— Э, ком һиер! Ком, ду! (Әй, кил бире! Кил, син!)— дип, немец Илгизәрне үз янына чакыра иде.

Илгизәр коелды да төште... Бераз сулыш алырга туктаган иде, бетерә инде хәзер... Йөгереп китеп, хатыннар артына качасы килде, ләкин куркуын җиңде, качмады.

Немец, елмая-елмая, Илгизәргә таба килә иде. Малай шушы минутта үзенең хатасын аңлап алды. Күлмәген салып ул бик ялгышкан, тик хәзер соң иде инде. Немец килеп җитте дә, Илгизәрнең беләгендәге йолдыз сурәтенә күрсәтеп:

— Бист ду пионер?— дип сорады. Малай тизрәк беләген каплады да таш өстендәге күлмәгенә үрелде.

— Цие аус! (Сал күлмәгеңне!) — дип җикерде кинәт сакчы Илгизәргә. Малай, саласы килмичә, тартышып тора башлаган иде, немец бер йолкуда Илгизәрнең күлмәген изүеннән итәгенә хәтле аерып төшерде.

Малайны якламакчы булып, хатын-кыз чәрелдәшеп килә башлады. Немец тимердәй кулы белән Илгизәрне каптырып тоткан да чәүкәләрдәй чәрелдәшкән хатыннар өстенә җикерә:

— Вег! Вег! Цюрюк!— Инде автоматын да салды...

Бүтән сакчылар ярдәмгә йөгерешеп килеп җиттеләр. Илгизәрнең кулларын артка каерып тоттылар да алып киттеләр.

Подвалдагы караңгыга күзләре бераз ияләшкәч, Илгизәр чак кына кычкырып җибәрмәде: идәндә кап-кара кан җыелып тора иде. Стеналарга да кан чәчрәгән... Малайның күзләре зурайды... Сулышы кысылды... Ул чатырдатып тешләрен кысты да елап җибәрде...

Ничек ычкынырга хәзер моннан? Подвал тәрәзәсендә пыяла юк, ләкин чәнечкеле тимерчыбык белән чорналган... Тычкан гына үтсә үтә алыр. Малай череп беткән салам өстенә барып утырды, аркасын ташка терәде. Таш юеш һәм салкын иде.

Очлы таш аркасына төртеп тора... Ул бераз тынычланды. Аның һич гаебе юк ич. Бетми торган буяу белән беләгенә йолдыз сурәте төшергән икән, авылда бик күп малай төшерде ич аны... Сугыш-сугыш уйнаганда төшергәннәр иде. Әнкәсе бик каты ачуланган да иде әле шуның өчен: «Тән бозып, юләр...»— дип әрләгән иде.

Немец солдаты, аны монда алып килгәндә, «кых!» дип муенын сызып күрсәтеп, малайны куркытырга теләгән иде. Әллә бу подвалда, чынлап та, кеше суялармы икән? Аның тагын сулышы кысыла башлады. Йөрәге тарс-торс тибә... Күтәрелеп подвал тәрәзәсенә карады... Шул тимерчыбык арасыннан күбәләк булып чыгып китәргә... Стенага кемдер күмер белән:

«Бәхил булыгыз!» — дип язып калдырган. Илгизәр бүтән язуларны да табып укыды. Шул кешеләрнең канымы икәнни бу? Саташкан кешедәй, идәндәге канга карап-карап торды да йөгереп барып ишекне тартты. Бикле. Тәрәзәгә ташланды, сикерде, мендe. Куллары чәнечкеле тимерчыбыкка кадалдылар... Илгизәр кире шуып төште. Хәле бетеп, идәнгә утырды.

...Аны подвалдан алып чыккан чакта, кояш иңә башлаган иде инде. Көн сүрелгән иде. Автомат көпшәсе белән төрткәләп, малайны алып киттеләр. «Атарга!» дип, йөрәге әрнеп кысылды Илгизәрнең. Әнкәсе белми дә кала инде. Сеңлесе дә... Китаплардан укыганы бар, атканда революционерлар: «Яшәсен халык власте!» — дип кычкырып үлгәннәр. Курыкканны фашистка күрсәтмәскә кирәк. Өйалды баскычыннан менгәндә, Илгизәр гел елмаеп менде. Атарга алып баралар, шик юк, тик шулай да күңеле әле ышанып бетми. Үлмәс кебек, аны коткарырлар кебек. Әнкәсе йөгереп килер... Юк, әнкәсе килә алмас. Ул тимерчыбык белән чолганган лагерьда... Аны җибәрмәсләр... Кем коткарыр соң аны?

Үрмәкүч төсле кара свастика төшергән зур ишек, Илгизәрне йотып, тавышсыз гына ябылды. Тынлык... Кинәт йөрәк яргыч тавыш ишетелде... Ишек артыннан ишетелә... Илгизәр тавышы... Аны кыйныйлармы, нишләтәләр? Җан ачысы белән бик озак кычкырды Илгизәр...

Кичке кояшның алтын тузаны коридорга сибелде. Свастикалы ишек тавышсыз гына ачылып китте. Бусагага, абынасөртенә, Илгизәр килеп чыкты. Аның сыңар колагы киселгән, ә беләгендәге яңа гына уелган кып-кызыл йолдыздан кан тамчылап тора иде.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Фашистлар авыл халкын ни өчен җир казырга куып чыгаралар?
2. Илгизәрне сез нинди малай итеп күз алдына китердегез?
3. Ничек уйлыйсыз: Илгизәр ни өчен хатыннар артына ышыкланырга хурлана?
4. Малайның хатасы бармы?
5. Ни өчен фашистлар Илгизәрне ерткычларча газаплыйлар?
6. Подвалның эчке күренеше сурәтләнгән урынны табып укыгыз. Малайның кичерешләре турында сөйләгез.
7. Әнисенә карата булган җылы хисләрен искә төшерегез.
8. «Илгизәр — батыр рухлы малай» дигән темага сочинение языгыз.

бөгелеп — иелеп (согнувшись)
ябыкты — арыкланды (похудел)
кыймылдыйлар — селкенәләр (шевелятся)
көйгән иреннәр — кипкән иреннәр (растрескавшиеся губы)
зәһәр — усал (злой)
галәмәт — *монда*: бик авыр эш, хәл
ышыкланырга — яшеренергә (прикрываться)
чәрелдәшеп — кычкырышып, шау-шу килеп

КЫЮЛЫК

(*«Йолдызлы малай» әсәре турында*)

Безнең кешеләрнең фашистларга каршы аяусыз көрәш алып барулары, бу юлда күрсәткән каһарманлыклары Ибраһим Газины шул турыда хикәяләр иҗат итәргә илһамландыра. «Йолдызлы малай» әсәрендә дә өлкәннәрнең генә түгел, балаларның да үзләрен горур тотулары, буйсынмас табигатьле икәнлекләре сурәтләнә. Автор вакыйгаларның үзәгенә унике яшьлек Илгизәрне куя, аның кичерешләре ярдәмендә бер күренешне икенчесе белән оста итеп ялгап бара. Нәтиҗәдә аның холык-фигыле табигый һәм ышандырырлык булып ачыла. Фашистлар балалар, карт-корылар, хатын-кызларны үзләренә көчләп хезмәт иттерәләр, ләкин аларның йөрәкләрен буйсындыра алмыйлар. Җир казыту үтерү белән куркытып алып барыла. Бер генә минут та тукталып ял итәргә ярамый, шундук җәзалау, газаплаулар, мәсхәрәләүләр булуы шиксез.

Иң авыр, кыен мизгелләрдә Илгизәр әнисен күз алдына китерә. Бала өчен анадан да газиз кеше юк. Бу — бик табигый нәрсә. Әнисе аның янына килсә, аның авыртулары, тәнендәге җәрәхәтләренең сызлавы басылыр төсле. Ләкин бу хәлне Илгизәрнең әнисе белми, белсә дә нишли ала соң ул? Дошман мәкерле, шәфкатьсез, явыз, ерткыч. Ләкин ана кеше, үз гомерен биреп булса да, баласын коткару өчен бөтен көчен бирер иде.

Фашистлар Илгизәрнең тәненә пычак белән җәрәхәтләп йолдыз ясыйлар, колагын кисеп алалар, ләкин ул бу газаплауларга да кыюларча түзә, сыкранмый, рухын сындырмый. Аның күз алдына халык бәхете өчен көрәшкән каһарманнар килә. Алар да иң кыен, авыр мизгелләрдә дә дошманга буйсынмаганнар. Туган илләрен сатмаганнар, баш имәгәннәр,

кол булып калырга теләмәгәннәр. Ни өчен әле Илгизәр генә төшенкелеккә бирелергә тиеш? Юк, Илгизәр дә куркып калмаячак! Аның карары нык: үлсә дә, бу дөньядан бары тик батырларча гына китәчәк!

Шулай итеп, әсәрдә малайның дошманга булган нәфрәте бик уңышлы чагылдырылган. Иң әһәмиятлесе — малайның эчке дөньясын сизгер сурәтләү. Ибраһим Гази бу хикәясендә сугышның балаларга да иксез-чиксез бәхетсезлекләр алып килүе турында яза. Сугыш — ул кыргыйлык, кешеләргә хас нәрсә түгел. Тынычлыкны саклап калу өчен көрәш — кешеләрнең бәхете өчен көрәш ул.

Фуат Халитов

(1909—1981)

Әдәбиятта драматургия үзенә аерым бер урын алып тора. Драма әсәре уку һәм аны сәхнәдә кую өчен языла. Шуңа күрә аны сәхнә әсәре дип тә әйтәбез. Пьеса спектакль булып әверелсен өчен, театр бинасы, җиһазландырылган сәхнә, уенны башкаручы артистлар, аларга җитәкчелек итүче режиссер кирәк. Спектакль — күмәк хезмәт җимеше. Режиссер һәм артистлардан тыш, аны тудыруда рәссамнар, кием тегү осталары, композиторлар, ут кую осталары һәм башкалар катнаша. Аларның хезмәте хөрмәтләнергә тиеш.

Татар театрын үстерүдә үзеннән зур өлеш керткән шәхесләребезнең берсе Фуат Халитов. Җөмһүриятебезнең мәдәният дөньясы белән хәбәрдар булган һәркемгә бу исем яхшы таныш. Ярты гасыр буена сәхнәдә йөз иллегә якын роль уйнаган мәшһүр артист ул.

Фуат Ибраһим улы Халитов 1909 елның 18 февралендә Казанда зыялы гаиләдә туа. Аның бабасы Фатих Халиди беренче татар драматургларыннан була. Фуат яшьтән үк театр белән мавыга, үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә концертлар, спектакльләрдә катнашып йөри. Казандагы Вахитов исемендәге заводта эшләгәндә, шундагы драмтүгәрәк җитәкчесе Шакир Шамильскийдан Фуат сәхнә осталыгына өйрәнә. Казан театр техникумына керергә хыяллана. Ләкин, төрле сәбәпләр аркасында, бу теләге тормышка ашмый кала.

1930 елда Фуат Халитов тире эшкәртүчеләр әзерли торган курсларда укып чыга һәм Казан мех комбинатында эшли башлый. Тиздән биредә Татар мех эшчеләре театры ачыла. Ул ярым үзешчән, ярым профессиональ театр була. Аның

әдәби бүлегенә Галиәсгар Камал җитәкчелек итә. Ул үзе дә эшче театры өчен пьеса, скетчлар, интермедияләр яза. Бу чорда Фуат Халитов күренекле артист Хәким Сәлимҗанов ярдәмендә сәхнә серләренә төшенә, эстрада артисты буларак та камилләшә.

1932 елдан ул шушы театрда ныклап торып эшкә керешә. Озак та үтми, артистлар белән бергә, аны Мәскәүгә осталыгын камилләштерергә җибәрәләр. Анда безнең артистлар Художество театры кебек атаклы иҗат коллективларында сәхнәдә уйнау серләренә тирәнрәк төшенәләр.

1937 елда Фуат Халитов, ниһаять, Татар дәүләт академия театрында эшли башлый. Ул туктаусыз эзләнә, иҗат ялкыны белән яна. Биредә эшләүнең беренче көннәреннән үк ул җитди рольләр башкара. Мәсәлән, У. Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» әсәрендә — Ромео, Н. Погодинның «Мылтыклы кеше»сендә — Шадрин, Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында Бики бай рольләре һәм башкалар.

Фуат Халитовның иҗат мөмкинлекләре бик киң. Ул берберсенә охшамаган бик күп рольләрне оста башкара. Алар арасында төрле милләт кешеләре дә, яшьләр дә, картлар да бар. Артистның осталыгы елдан-ел арта.

1958 ел. Фуат Халитов Н. Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясендә патриот-шагыйрь образын иҗат итә. Шуннан соң ул Ә. Фәйзинең «Тукай» пьесасы буенча куелган спектакльдә — сүзсез сәүдәгәр, Н. Исәнбәтнең «Гөлҗамал»ында — Хафиз, А. Яхин белән А. Гыйләҗевнең «Шамил Усманов» драмасында — Сәгъдетдин, Т. Миңнуллинның «Ир-егетләр»ендә Әхтәм кебек рольләрне оста башкара.

Үзенең бөтен тормышын, барча сәләтен театрга багышлаган, сәнгать өлкәсендә зур уңышларга ирешкән Фуат Халитовка 1975 елда СССРның халык артисты дигән мактаулы исем бирелде. Җөмһүриятебез җәмәгатьчелеге үзенең яраткан артистын әлеге олы бүләк белән котлады, аңа уңышлар теләде. Казан каласының бер урамы яраткан артистыбызның исемен йөртә.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Алда үткәннәрдән искә төшереп, драма әсәрләренең чәчмә әсәрләрдән һәм шигырьләрдән кайсы ягы белән аерылуы турында сөйләгез.

2. Фуат Халитов академия театры артисты булганчы нинди юл үтә?

3. Фуат Халитов башкарган рольләрне санагыз:
а) ул татар драматургларының кайсы әсәрләрендә катнаша һәм нинди образлар иҗат итә?
б) башка милләт һәм чит ил драматургларының кайсы әсәрләрендә уйный?

зыялы — интеллигент

сәнгать — чынбарлыкны образлар ярдәмендә чагылдыру; сәнгать үзе төрләргә бүленә (музыка, рәсем, театр, бию, әдәбият (сүз сәнгате), кино һ. б.)

скетч — шаян эчтәлекле, үзара сөйләшүгә нигезләнгән әдәби әсәр

интермедия — концертларда уйнала торган кечкенә пьеса

Шәүкәт Биктимеров
(1928)

Татар театр сәнгатенең күренекле артисты булып танылганчы, Шәүкәт Биктимеровка күп еллар буе зур осталык мәктәбен үтеп чарланырга, иҗат тәҗрибәсе тупларга кирәк була. Яшьтән үк хезмәт сөю сыйфаты бу юлда аңа төп таяныч булгандыр, мөгаен.

Шәүкәт Хәсән улы Биктимеров Саба районы Миңгәр авылында туа. Укытучы әнисе аны китаплар дөньясына бик иртә алып керә, малайда әдәбият һәм сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли. Ватан сугышы башланганда, аңа әле ундүртенче яшь кенә була. Колхозда иң авыр эшләр яшүсмер егетләр җилкәсенә төшкән чак бу. Башкалар белән бергә Шәүкәт тә кая кушсалар шунда эшли. Малайның һәр эшкә диярлек кулы ятып тора. Мәктәптә дә аны зирәк, зиһенле укучы дип мактыйлар.

Сирәк булса да, авылның бертөслерәк аккан тормышына ямь биреп, театрлар килеп киткәли. Менә мондый көн Шәүкәт өчен чын бәхет инде: идәнгә тезләнеп утырган килеш, ул сәхнәдә барган вакыйгаларны, персонажларның һәр сүзен, хәрәкәтен үзенә сеңдереп бара, аңарда гомерен театрга багышлау теләге ныгый. Катгый бер карарга килүдә аңа якын кардәше — Татар дәүләт академия театрының сәхнә остасы Галимә Ибраһимова да этәргеч бирә.

1945 елның көзендә, Казанда театр техникумының яңадан ачылуы хакында ишеткәч, Шәүкәт Биктимеров башкалабызга ашыга. Техникумда сынаулар узганнан соң, аны режиссер Ширияздан Сарымсаков сыйныфына кабул итәләр.

Ул монда үзеңне сәхнәдә табигый тотуның, образга әверелеп яшәүнең серләрен ныклап үзләштерергә тырыша. Аның хезмәтләре бушка китми. 1949 елда техникумны уңышлы тәмамлаган Шәүкәтне башкалабызның иң абруйлы театрында эшләргә калдыралар.

Ш. Биктимеровның нечкә күңеллелек, эчкерсезлек, сизгерлек һәм зыялылык сыйфатлары үзе уйнаган күп рольләрдә чагылыш таба. Үз-үзен тотышы, уйнау алымнары төрле спектакльләрдә шулкадәр төрлечә була алыр икән! Тавышының ягымлылыгы һәм күркәмлеге аның уенына тагын да ямь өсти.

Биредә озак еллар эшләү дәверендә нинди генә рольләр башкармый ул! Алар арасында К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендә — Ишан, Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар»ында — Биктимер карт, М. Кәримнең «Ташлама утны, Прометей!»ында — Зевс, Ш. Хөсәеновның «Әни килде» әсәрендә Ислам һәм тагын әллә никадәр образлар бар. Бу кадәр образларны югары сәнгатьчә тудыру өчен гаять зур хезмәт кую һәм талантлы булу таләп ителә.

Ш. Биктимеров иҗаты турында сүз алып барганда, Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге Әлмәндәр роленә тукталмыйча мөмкин түгел. Спектакльнең үзәк герое Әлмәндәр картка туксан яшь тулып узган. Әлмәндәр халыкның йөзләрчә еллык акылын, зирәклеген һәм тапкырлыгын үзенә җыйган, ул тиз генә үләргә җыенмый әле. Әҗәл белән көрәш-тартышта картның бетмәс-төкәнмәс хикмәтле сыйфатлары, күңел хөрлеге ачыла. Ул — бөтен авырлыкларны ил белән бергә күтәргән, барлык бәла-казаларны башыннан кичергән кеше. Аңа япон сугышында да үлем янаган булган. Гражданнар сугышы көннәрендә дә Әҗәлгә бил бирмәгән ул. Туксан беренче яшендә дә ул намуслы, ачык күңелле кеше, тормышны, хезмәтне ярата.

Ш. Биктимеров бу образны гаҗәп матур бизәкләргә төреп бирә. Шундый күркәм сыйфатларның берсе — картның үз-үзенә җиңелчә көлемсерәп каравы.Ул үзенең картлыгыннан да кызык таба, оныгы белән ярышкан булып йөгерә, аңа кушылып бии, уйный. Ә тапкырлыгы, җор теллелеге чиксез аның. Әлмәндәр карт халыкның үз-үзенә ышануын, яшәү куәтен, күңел байлыгын гәүдәләндерә. Ш. Биктимеров спектакльдә каһарманын чынбарлыктагыча оста итеп яшәтә, образ әйтерсең актерның хезмәтеннән, тырышлык һәм ихтыярыннан

башка үзеннән-үзе хәрәкәт итә. Мондый җиңеллек, табигыйлек Биктимеровның сәнгатьтә ирешкән осталык дәрәҗәсе, иҗат мөмкинлекләре киңлеге, образлар тудырудагы камиллеге хакында сөйли.

Әнә шундый күпкырлы тырыш хезмәтен бәяләп, аңа Татарстанның һәм СССРның халык артисты дигән исемнәр бирелде. Ул республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Ш. Биктимеров бүген дә иҗат белән рухланып яши, сәхнәдән аерылмый, яшь буын артистлар белән тәҗрибә уртаклаша.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шәүкәт Биктимеровның сәнгатькә килүенә тормышындагы нинди вакыйгалар һәм кемнәр этәргеч бирә?
2. Шәүкәт Биктимеров башкарган рольләрне исегезгә төшерегез. Үзегезгә ошаган роле турында сөйләгез.
3. Туган халкы аның намуслы хезмәтенә нинди бәя бирә?
4. Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасын укып чыгыгыз һәм үзара фикер алышу оештырыгыз. Шул әсәр буенча куелган спектакльне карагыз.

табигый — ясалма түгел (естественный, природный)
әҗәл — үлем (смерть)
хөрлек — азатлык, ирек (свобода)

Зәки Нури
(1921—1994)

Зәки Нури (Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов) Чүпрәле төбәгендәге Татар Төкесе исемле авылда 1921 елның 24 декабрендә дөньяга килә.

Булачак шагыйрь Зәки Нуретдинов шушы авылның гүзәл табигате кочагында үсә, яшел чирәмнәрдә ауный. Бу, әлбәттә, аның шагыйрь җанлы күңеленә тәэсир итми калмый. «Кечкенә авылыбыз аны өч яклап ураган зур урман буена сыенган»,— дип сөйләргә ярата шагыйрь.

Урманым — җырым оясы!
Килде шундый уй миңа:
Син йөрәгемә сыясың,
Ә мин — синең куеныңа, —

дип тә өсти.

Туган төбәгендә җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул урман техникумына укырга керә. Кукмара районының Лубян авылындагы әлеге уку йортында белем алганнан соң, ул берничә ел Ерак Көнчыгышта эшли. Сугыш алдыннан инде туган якларында урманчы булып хезмәт итә. Илгә немец фашистлары басып кергәч, башта аңа артиллерист буларак, соңыннан Белоруссия урманнарында партизаннар сафында дошманга каршы көрәш алып барырга туры килә. Ул — Белоруссиядәге Орша шәһәренең мактаулы кешесе.

Сугышның буеннан-буена ут эчендә йөргән З. Нури өчен җиңү аеруча кадерле була.

Чәчәк ата кебек үзе күңел,
Таң шикелле хис саф, уй якты.
Мине бүген бомба шартлап түгел,
Сандугачлар сайрап уятты.

Тәрәзәмне тулы итеп ачтым:
Таныш урман, камыш, күл әнә...
Нинди рәхәт, җәйнең җиле керә
Блиндажыма түгел, бүлмәмә...

Аның беренче шигырьләр китабы 1945 елда — сугыш тәмамлангач ук чыга. Урман турында «Безнең яшел дустыбыз» (1949), партизаннар сугышына багышланган «Дан юлы» (1949), «Чын күңелдән сөйләшү» (1955) исемле шигырь китапларын укучылар яратып каршы алдылар. Күренекле шагыйрь Сибгат Хәким аның турында бик матур фикерләр әйтте: «Зәки Нури — безнең поэзияне үстерешүгә киләчәктә зур өлеш кертә торган талантлы шагыйрь».

З. Нури иҗатында балалар өчен язылган шигырьләр дә байтак. «Без инде хәзер зурлар», «Чаңгыларым кыска», «Саный беләм», «Тиздән-тиздән...», «Әй, яңгыр килсен иде» шигырьләре балалар өчен бик кызыклы.

З. Нуриның әсәрләре, туган теленнән тыш, казакъ, якут, рус, мари, белорус, азәрбайҗан телләрендә дә басылды. Ул үзе дә башка милләт шагыйрьләренең әсәрләрен татар теленә бик теләп тәрҗемә итте.

Зәки Нури «Казан утлары» журналының баш редакторы, Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе булып та эшләде.

Ул 1994 елда Казан шәһәрендә вафат булды. 2005 елда Чүпрәледә аның хөрмәтенә һәйкәл ачылды.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Зәки Нури туган Чүпрәле районын Татарстан картасыннан табыгыз. Нократ елгасы буена урнашкан кайсы авыл З. Нури тормышында аерым урын алып тора? Ни өчен?
2. Шагыйрь туган авылы турынданиләр әйтә? Сез дә үзегезгә якын һәм кадерле булган авылыгыз, шәһәрегез турында матур итеп сөйләп бирегез.
3. «З. Нуриның язмышы урманнан аерылгысыз» дигән фикерне аңлатып бирегез.
4. Шагыйрьгә ни өчен «Орша шәһәренең мактаулы кешесе» дигән исем бирелгән? Ул кайсы республика шәһәре?
5. Шагыйрьнең әсәрләре кайсы милләт телләрендә басылган?

төбәгендә — ягында
мактаулы кеше — почетлы кеше
Нократ — Вятка елгасы

ЯҢА ШӘҺӘР

Кыргый тынлык булган монда,
Ташландык бер яр булган...
Хәзер һөҗүм бара комга,
Ватан шәһәр сала шунда,
Инде урамнар туган.

Өлгергәч, бәлки, аларның
Исемен бөтен ил уйлар?!
Асфальтын сыйпап даланың
Тиздән җиләс җил уйнар.

Күчмә кош, кунып топольгә,
Аптырап канат кагар:
«Былтыр бар иде шушында,
Кайда ул палаткалар?..»

Киң түрдә, иркен бишектә
Елмаеп бала йоклар.
Яңа диңгез килүен көтә
Бу җиргә яңа йортлар.

Монда һәр ташчы кирпечен
Шат уйлар уйлап сала;
Туасын белә ил өчен
Зур кала, җыйнак кала.

Җыр белән салына һәр нигез,
Җырлап ябыла түбәләр.
Без инде, шәһәр бар, дибез,
Инде хатлар киләләр!..

Ялтырап күркәм төсләрдә
Карый шәһәр күзеңә.
Һәйкәл ул безнең эшләргә
Һәм гасырның үзенә.

Сораулар.

1. Соңгы унъеллыкларда безнең Татарстанда нинди яңа шәһәрләр үсеп чыкты?
2. Үзегез торган урам исеме турында ни уйлыйсыз? Ул исем сезне канәгатьләндерәме? Аның тарихын беләсезме?
3. Төзүчеләр, җырлый-җырлый, яңа шәһәр салалар. Нинди җырлар икән ул? Сез хезмәткә багышланган җырлар беләсезме?
4. Баланы йоклатканда, әнисе нинди бишек җыры җырлар икән? Сез бишек җырлары беләсезме?
5. Сезнең шәһәрдә бүгенге кешеләрне һәм киләчәк буыннарны сокландырырлык биналар бармы? Аларның кайсы сыйфатлары үзенә җәлеп итә?
6. Кайсы биналар сезгә ошамый? Ни өчен?

кыргый тынлык — *монда*: кеше яшәмәгән урын (дикая тишина)
һөҗүм — *монда*: максатка ирешү өчен актив эш, көрәш
җиләс җил — әкрен генә, йомшак кына исүче җил
былтыр — узган ел
күркәм төсләр — матур буяулар, бизәкләр
карый шәһәр күзеңә — шәһәр инде күзгә күренә
унъеллык — ун ел вакыт

«Казаным — башкалам» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. *Туган як* төшенчәсен сез ничек аңлыйсыз?
2. Безнең Республикабыз ничек дип атала?
3. Казан — Россия Федерациясенең иң борынгы шәһәрләреннән берсе. Бу турыда сезниләр беләсез?
4. Башкалабыз тирәсендә нинди елгалар һәм күлләр бар? Аларның хәзерге торышы турында ни уйлыйсыз?
5. Казан каласы ничә районга бүленгән, анда күпме халык яши?
6. Казанда нинди мәдәният сарайлары һәм театр биналары бар? Сезгә аларда булырга туры килдеме?
7. Сынлы сәнгать белән бәйләнешле нинди урыннарны беләсез?
8. Башкалабыздагы югары уку йортларын атагыз.
9. Туган як һәм Казан шәһәренә багышланган нинди шигырьләр, җырлар, хикәяләр беләсез?
10. Туган якка багышланган нинди мәкаль һәм әйтемнәр беләсез?

Сибгат Хәким

(1911—1986)

Татарстанның Әтнә районында Күлле Киме авылы, хисапсыз башка кечкенә авыллар шикелле, күпләр өчен билгесез булып калыр иде. Әмма бүген бу авылны әдәбият сөючеләр бик яхшы беләләр. Чөнки биредә 1911 елның 4 декабрендә булачак шагыйрь Сибгат Тажи улы Хәким туган. Шагыйрьнең дә нинди әле! Халык шагыйре! Әйе, Сибгат Хәким — шундый югары исемгә лаек булган сирәк талантларның берсе.

Әмма шундый шагыйрь булып танылганчы С. Хәкимгә шактый зур юл үтәргә туры килә әле. Күлле Кимедә җидееллык мәктәпне тәмамлый. Берничә ел авылда тора, крестьян хезмәте белән шөгыльләнә, беренче шигырьләрен дә шул елларда яза башлый. Әдәбиятны әйбәтрәк белү теләге белән 1931 елда Казанга килә. Аны эшфакка (рабфак) кабул итәләр. Аннан исә Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә күчерәләр. Укуын тәмамлагач, китап нәшриятында һәм әдәби журналда эшли.

Казанга килгәч тә, С. Хәким шигырьләр язуын дәвам иттерә. Ниһаять, аның «Беренче җырлар» исемле шигырь китабы басыла. Утызынчы еллар ахырына таба ул иҗади тырышлыгын тагын да арттыра төшә. Бөек якташы Габдулла Тукайга багышлап бер-бер артлы ике поэма яза. Алар «Пар ат» һәм «Шагыйрьнең бала чагы» дип аталалар. Шуңа күрә, Сибгат Хәким шигъриятькә пар атта килеп керде, диләр. Менә шулай күтәренке күңел белән иҗат итеп йөргәндә, фашистлар Германиясе безнең илгә каршы сугыш башлый. Шагыйрь Сибгат Хәким дә кулына корал ала. Ул сугышның иң хәтәр урыннарыннан берсе — Курск дугасы сугышында катнаша,

взвод һәм рота белән җитәкчелек итә. Күрсәткән батырлыклары өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә. Бары тик 1946 елда гына хәрби хезмәттән кайта ала һәм тыныч тормыш шартларында иҗатын дәвам иттерә.

С. Хәким барыннан да элек хис-кичерешләрне тирән итеп әйтеп бирү остасы, ягъни лирик шигырьләр язуга өстенлек бирә. Аның шигырьләре бик гади кебек. Ләкин С. Хәким беренче карашка катлаулы булмаган әсәрдә олы фикерләр әйтеп бирә белә. Бу — осталар эше.

Мәсәлән, 1921 елда Идел буенда, шул исәптән Татарстанда да, коточкыч ачлык була. Аның әтисе, тамак туйдырырлык ризык юнәтү максаты белән, эш эзләп китә. Ләкин кытлык елларда менә дигән балта остасына да эш табылмый. Аңа шул сәфәреннән кире әйләнеп кайтырга насыйп булмый, ачлыктан үлеп кала. С. Хәким 1939 елда шул турыда «Югалган эзләр» дигән шигырь яза:

> Тиз кайтырмын диеп киткән иде,
> Бик күп еллар узды хәбәрсез.
> Улың эзли сине, дип әйтерсез,
> Очратсагыз аны әгәр сез.

Бу шигырь юлларын укыгач, югалган әтисен табу өметен җуймаган малайның сагышын, хәсрәтен үз күңелең белән кичерәсең.

Сугыш елларында язганнары сугышчының иң ихлас хис-кичерешләрен гәүдәләндерә. Менә солдат өйдән килгән хат укый:

> Күп сәлам сезгә дип язган
> Хөрмәтле юллар да бар;
> Ниндидер рәсем төшергән
> Бик нәни куллар да бар.

Болай итеп шул хәлләрне үз башыннан уздырган кеше генә яза ала. Менә ни өчен С. Хәким язганнар ышандыра, дулкынландыра. Шулай да ул фронтта кичергәннәре турында сугыштан кайткач күбрәк һәм тулырак, кайта-кайта язды. Ниһаять, «Курск дугасы», «Дуга», «Дала җыры», «Күги» («Күке») кебек әсәрләре иҗат ителә. Шагыйрь сугыш дәһшәтен, шуның эчендә кайнаган кешенең күңел дөньясын, кешелек сыйфатларын, солдат дуслыгын, төрле милләт кешеләренең уртак омтылышларын җырлады.

Г. Тукай турында язуга да шагыйрь яңадан әйләнеп кайтты. «Тукай дәфтәре» дигән шигырьләр бәйләме һәм «Кырыгынчы бүлмә» исемле поэма язды. Аның тагын туган як, табигать, сагыш, юксыну кебек темаларга бик матур шигырьләре бар. «Туфан дәфтәреннән», «Суд залыннан», «Немец дәфтәреннән» һәм башка шигъри бәйләмнәре дә укучылар тарафыннан яратып укыла. Йөзләгән шигырьләре җыр булып яңгырый. «Таң атканда», «Фазыл чишмәсе», «Юксыну», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» кебек җырлары аеруча уңыш казанды.

Шагыйрь 1986 елның 3 июлендә вафат булды. Аның кабере Казанның Яңа Бистә зиратында.

Сораулар һәм бирем.

1. «Гомер итү — диңгез кичү» дигән халык әйтемен С. Хәким тормышы мисалында аңлатыгыз.
2. Күлле Киме Татарстанның кайсы районындагы авыл? Шагыйрьләр, язучылар, галимнәр һәм башка атаклы кешеләр туган тагын нинди авылларны беләсез?
3. Ни өчен С. Хәким турында «ул шигърияткә пар атта килеп керде» диләр? Тагын кайсы шагыйрьнең «Пар ат» исемле әсәре бар? Аларның кайсысы алданрак язылган?
4. Шагыйрьнең үткән тормыш юлы аның әсәрләрендә ничек сурәтләнә?
5. С. Хәким шигырьләренә язылган җырларны беләсезме?

хисапсыз — бик күп
лаек булган — күрсәткән хезмәтләре белән шушы мактаулы исем бирелерлек дәрәҗәгә җиткән
җидееллык мәктәп — җиде сыйныфны тәмамларга мөмкин булган мәктәп
Курск дугасы — Курск, Орел, Белгород шәһәрләре тирәләре
ризык — ашау, туклану әйберләре
кытлык ел — ачлык ел, иген уңмаган ел
балта остасы — йорт салучы (плотник)
сәфәр — сәяхәт кылу (путешествие)
өметен җуймаган — өметен өзмәгән, өметен югалтмаган
сугыш дәһшәте — сугыш куркынычы, бәла-казасы (ужасы войны)
шигырьләр бәйләме — берничә шигырь (алар, гадәттә, тема ягыннан уртак булалар)
үзән — елга яры буендагы уйсу җир, түбәнлек (долина, низменность)
вафат булды — үлде

ҖЫРЛАРЫМДА ТЕЛИМ...

Авыруыма врач кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын:
Һәр ел саен кайтып иснәп киләм
Авылыбызның чиста һавасын.

Язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе тәмлерәк.

Яннарына барам агайларның,
Фикерләрен ишетеп карарга.
Җырларымда телим гомерем буе
Алар рухы белән янарга.

Сораулар һәм бирем.

1. «Йөрәгемнең беләм дәвасын», «Шигъри хисләремә арышларның исе тәмлерәк», «Телим гомерем буе алар рухы белән янарга» дигән юлларны сез ничек аңлыйсыз?
2. Туган ягының саф һавасы лирик геройга табиб дәвасыннан да шифалырак икән. Сүз биредә һава турында гына барамы?
3. Уй, күңел, хисләр белән туган якка тартылуны белдерә торган сүзләрне, фикерләрне табып укыгыз.

врач — табиб
дәвасын — даруын, шифасын

БАКЧАЧЫЛАР

(Поэма кыскартып бирелә)

1

Хисләреңә синең киң ачылган
Иштуганның басу капкасы.
Яңа ак фермалар тирәсеннән
Китә җәелеп алма бакчасы.

Бакчачы соң үзе кайда йөри?
Эзләсәң дә син үз тирәңнән,
Табалмассың: елга буендагы
Юкәгә ул барып сөялгән.

Ак күлмәген җилләр җилфердәтә,
Эшләпәсен салган башыннан.
Онытылган бер көйне хәтерлиме
Чылтырап аккан суның таушыннан?

Озак еллар яшәр бу агачлар...
Узсаң әгәр алар яныннан,
Бер алмасын өз дә үлчәп кара:
Артыр, шиксез, кадак ярымнан...
Сәлим абзый ник борчуга төшкән?

2

Тыныч чакта, сугыш алдыннан,
Үсентеләр сорап, питомникка
Төрле җирдән кеше агылган —
Бәйрәм төсен алган көзге көннәр.

Шул көннәрне хәзер кичерә Сәлим,
Бер шик борчый аның йөрәген:
Озакламый җылы җәй авышыр,
Сизмәссең дә көзнең кергәнен.
Көз алмагач төпләрендә йөрер,
Яфракларын җилләр коярлар,
Үсентеләр алу вакыты җитәр, —
Аларны соң кая куярлар?

3

Узган көздә яшь алмагачларны
Төпләделәр, җиргә күмделәр.
Көз булмаса, язын алырлар дип,
Бакчачылар көтеп йөрделәр.

Килмәделәр, юк бит, килмәделәр.
Менә шуны тырыш оныткырга:
Бакчачылар ул алмагачларны
Үз куллары белән чокырга —
Тирән, зур чокырга аударды лар,
Оят инде, оят авылдан:
Сугыш елларының һәр көненнән
Хезмәт белән йолкып алынган

Шатлыкларын аудардылар шунда.
Караңгы баз бөтен бакчаңны
Йотар төсле... Сәлим күзләреннән
Ике бөртек анда яшь тамды.

4

Сугыш башланган ел. Беренче көз.
Авыр уйлар ята күңелдә.
Әзерли дә Ватан фронтына
Эшелоннар озата Бөгелмә.

Кызык та соң язмыш дигәннәре,
Хикмәтле ул язмыш, йөз катлы!
Билгесез бер якка, сугыш җиренә
Сәлим үзенең кызын озатты.

5

Бакча урыны... Интегүләр,
Газаплар азмы монда?
Ат керсә, ат батып калган
Иштуган сазлыгында.

Иштуганлылар кемнең дә
Дәшүен көтмәделәр,
Билдән су эчендә аның
Түмгәген төпләделәр.

Төпләделәр, куандылар,
Күреп сазның кипкәнен...
Ятмады Сәлим колхозның
Бушка ашап икмәген.

6

Сәлим абзый юлга чыкты,
Җигеп атның җирәнен.
Белеп кайтырга булды ул
Хәлен күрше-тирәнең.

Беренче авылга җитте.
Мәктәп яннарын карап,
Үстерсәң, күпме алмагач
Кирәк икәнен санап,

Исәпләп йөрде дә керде
Директорның катына:
Йомышым шул: бакча ясыйк
Сезнең мәктәп артына.

Һәр балага — бер алмагач,
Үстерсеннәр кадерләп.
Урыны — кояшка караган,
Бакчагыз торыр гөрләп...

Чәй эчеп маташмый Сәлим,
Китә бүтән авылга.
Ничек тыныч типсен йөрәк,
Шундый эшкә алын да!

Игеннәрегезгә карап
Күңелле үтүләре,
Сезнең фермаларның Зәйгә
Сибелгән көтүләре.

Яманламыйм... Бакчасы да
Булса иде «Алга»ның.
Агачлары миндә үсә
Сезгә дигән алманың.

Бакча кирәген сизәбез,
Кая аңа дәрманың...
Кайчандыр алмагачларны
Каты салкын алганын,

Шулчактагы бураннарны
Тагын бер кузгаттылар.
Калын боз калган оешып,
Әйтерсең боз ваттылар...

Һәвәскәр бакчачыларны
Эзләде, үгетләде.
Булышыр Сәлим, булышыр,
Сүнмәсен өметләре.

7

Питомник буена кызлар
Пар-пар булып тезелгән.
Син үзең дә яшәрерсең,
Йөрсәң алар эзеннән.

Яннарына туктал да син,
Кызлар сорау бирмәсен!
Утыра да тыңлый Сәлим,
Булешә тәҗрибәсен.

— Шул бакчада картайдым,
Уйладым мин төрлесен,
Үсентеләргә ялгагыз
Күбрәк шафран бөресен.

Иң соңыннан чәчәк ата,
Алмасы соң өлгерә;
Аның бер дә исе китми —
Ноябрь җиле өрә...

8

Салкын җилләр туңдырса да
Тәрәзә пыяласын,
Тоя иде кызлар тиздән
Бөреләр уянасын...

Әнә һәрбер тәрәзәдән
Карый кебек ятимнәр...
Гармунның дәртле тавышын
Тын гына сагына төннәр...

9

Басу юллары өстендә
Җилләр тузан өерде...
Сөрелгән рәт араларын
Сәлим тикшереп йөрде.

Ә яңгыр чиләклэп койды.
Булса әгәр телләре:
«Торгыз безне», — дияр иде
Ауган үсентеләре...

Тыңлый: нинди тавышлар ул
Өзек-өзек ишетелгән?
Шаулашып таулар буена
Йөгерә бөтен Иштуган.

Ашыкты ул да. Абынды.
Чәбәләнде карт җаны.
Әүвәлге гайрәте белән
Яңгыратып бакчаны

Кычкырасы килде. Юк-юк,
Теләми калышырга;
Бәхете шул таулар буенда,
Тормышы аның шунда.

10

Кешеләр үтте, кешеләр
Чуарлады тау янын.
Үсентеләрнең давылда
Имгәнгәнен, ауганын
Торгызалар берәм-берәм,
Сөртеп комын-балчыгын.
Китте ияртеп ташкыннар
Көнчелләрнең ярсуын.

Үстер дә югалт... Югалту
Уен түгел ул, туган.
Дерелди, калтырый әле
Яшь яфраклар куркудан.

Канау казыдылар читтә,
Юл эзләп су бөялде.
Уч төбен юеш ком уйды,
Өстәп яңа сөялне.
Зур канау... эшләрләр иде
Кимендә бер ай моны.
Җибәрергә тырыштылар
Ерып бөтен кайгыны.

11

Правлениедә Сәлимнең
Сыйпамаслар башыннан.
Кемнәр, ничек каршы алыр
Ишек бусагасыннан?

— Безнең уңайга түгел җил,
Килде быел авырга.
Кайгың зур, — диделәр, — синең...
Читен бөтен авылга.

Җаны бер дә риза түгел,
Уйлана Сәлим юлда:
Тынычлан, ял ит син, имеш,
Сүз диген инде шул да.

Нәрсә ул тикле, көн буе
Ул бит утын ярмаган.
«Кайгың зур...» өе турында
Кабатланды яңадан.

Ник кузгатылган урыныннан
Кызының өс киеме?..
Өстәлдә ята фронттан
Язган хатлар өеме.

Хатыны үкси Сәлимнең,
Иелгән дә хатларга.
Шул хатлардагы юллардан
Тап син аны, актар да...

Шомлы кәгазьне кулында
Сәлим гел бөтәрләде,
Куяр төш тапмады... Килгән
Ничә көн һәм ничә төн.
Үлем үзе суккан гүя
Өстендәге печатен...

Ай нуры төшкән сукмакка,
Түбә кыекларына.
Арганын белсә дә, Сәлим
Ышанмый йокларына.

Иске эз бакчага тартты,
Сөйри нинди хис кулдан?
Йоклый давылдан соң кырлар,
Йоклый инде Иштуган.

Сәлим йокламас, хәсрәте
Аны монда өстерәр.
Үсте кызы, кызы белән
Алмагачлар үстеләр...

12

Өзелде күпме гомерләр...
Сугыштан җан өшегән.
Кешесез күңелсез җирдә,
Аермасын кешедән.

Кешеләрдән сине тормыш
Мәңгегә аермасын...
Бүтән кем чыгарыр тартып
Сәлимне кайгыдан соң?!

Игенен дә, җимешен дә
Өлгертә җәй айлары.
Алдагы җиңү көннәрен
Көтә Зәй тугайлары.
Ил көтә.

Илем берүзе
Нинди йөкне күтәргән!
Исәннәр кайтыр... исәннәр
Бакча аша үтәрләр...

13

Сорты-сорты белән алма
Өелә кәрзиннәргә...
Көзге алма исе сеңгән
Моннан искән җилләргә.

Юл тынды, яфраклар посты,
Бөтен нәрсә зарыкты...
Кырык өченчене́ң көзе
Дәртләндерде халыкны.

Төш җитәр чакта, беркөнне
Төбенә кадәр капканы
Ачып куйды Сәлим, сорый:
— Кайсы колхоз атлары?

— Зәй колхозыннан.
— Бик әйбәт...
— Әле килеп бетмәгән.
Алмагачларың ишлеме,
Төпләгәнме?
— Төпләгән...

Юлчылар сөйләшә. Сугыш
Актарган бар хисләрен:
— Үстерик, тыныч елларда
Бирерләр җимешләрен...

Сугышны кысрыклый алар.
Җир канга буялмасын,
Алмагачлар һәр таң саен
Сискәнеп уянмасын.

Сораулар һәм бирем.

1. «Бакчачылар» дигән сүзгә әсәрдә нинди мәгънәләр салынган?
2. Сәлим абзыйны сез нинди кеше итеп күз алдына китерәсез? Сәлим абзыйдагы нинди сыйфатларны сез үзегездә булдырыр идегез?
3. Агач утырту, бала тәрбияләү — киләчәк турында кайгырту дигән сүз. Сез моны ничек аңлыйсыз?
4. Алмагачлар, чияләр, шомыртлар, җиләк-җимешләр үсеп, тирә-ягыбыз матур булсын өчен иң кирәкле шарт, сезнеңчә, ул нәрсә?
5. Мәктәп бакчасында, үз бакчагызда җимеш агачлары утыртыгыз, олылар ярдәме белән аларны карап-тәрбияләп үстерегез.

басу капкасы — авылдан чыгып китү юлындагы капка (околица)
юкә — агач исеме (липа)
үсенте — алма үсентесе (росток дерева)
питомник — яшь агачлар үстерә торган урын
җәй авышыр — җәй узып китәр
төпләделәр, җиргә күмделәр — үсеп утыра торган урыннарыннан казып алып, җиргә күмделәр
түмгәк — җир өстендә калкуланып торган урын (кочка)
җирән ат — җирән төстәге ат (рыжий конь)
катына — янына
«Алга»дан — «Алга» исемле колхоздан
дәрманың — *монда*: мөмкинлегең, байлыгың

бураннарны тагын бер кузгаттылар — *монда*: тагын бер искә төшереп сөйләштеләр
һәвәскәр — *монда*: алмагач үстерү остасы
тәҗрибәсен — үзенең белгәннәрен
шафран — алманың бер төре
бөреләр — агач бөреләре (почки)
чигү чигү — махсус җеп белән тукымага бизәк төшерү (вышивание)
сөял — *монда*: озак эшләүдән тиренең кабарып чыгуы (мозоль)
үкси — елый
шомлы кәгазьне — кайгы хәбәре китергән кәгазьне
җан өшегән — күңел газапланган, борчылган
Зәй — Татарстандагы елга
Зәй тугайлары — Зәй җирләре, болыннары, кырлары

КЕШЕ ҺӘМ АЛМАГАЧ ЯЗМЫШЫ

(*«Бакчачылар» поэмасы турында*)

Бер акыл иясеннән сораганнар:

— Дөньяда иң көчле ул нәрсә?

— Озак еллар яшәп, мин шуңа инандым: иң зур көч — яшәүгә булган омтылыш.

Чыннан да, әлеге акыл иясе хаклы булса кирәк. Үләнме, агачмы, башка бер үсемлекме — һәммәсе кояшка тартыла, әз генә мөмкинлек булу белән, тернәкләнергә, үсәргә омтыла. Табигатьнең акыллы җан иясе — кеше турында әйтеп торырга да кирәкмидер. Сибгат Хәкимнең «Бакчачылар» поэмасы да табигатьнең шушы күренешләре турында уйланулар нәтиҗәседер, мөгаен.

Әсәрдә кеше белән алмагач янәшә куелып сурәтләнә. Әйе, алар арасында тышкы охшашлык юктыр. Ләкин шагыйрь сәнгатьчә сурәтләү чаралары ярдәмендә аларның нииндидер уртак яклары булуын раслый. Беренчедән, алар — икесе дә табигать җисеме. Кешене дә, алмагачны да тәрбияләп үстерү өчен зур көч куярга кирәк. Бары шулчакта гына, билгеле бер вакыт җиткәч, алмагач татлы алма бирә, кеше исә хезмәткә яраклы булып җитлегә. Кешегә акыл, зирәклек, хезмәткә сәләтлелек кебек сыйфатлар бирелгән икән, аңа шул ук вакытта зур бурычлар да йөкләнгән. **Ул үзенә яшәү мөмкинлеге тудыручы табигать турында кайгыртырга да тиеш.**

Поэмада шундый кешеләрнең берсе — Сәлим абзый сурәтләнә. Кешенең кемлеге гадәти, җай гына бара торган тормышта ачылып бетмәскә мөмкин. Кемнең кемлеге киеренке, авыр шартларда ачыграк күренә.

С. Хәким дә, Сәлим абзыйның эчке дөньясын ачып күрсәтү өчен, аның тормышындагы иң кыен бер вакытны сурәтли. Сәлим абзый — бик игелекле кеше. Ул бер үк вакытта, ата буларак, инсафлы кыз тәрбияли һәм, бакчачы буларак, алмагач үсентеләре үстерә. Аның бөтен шатлыгы, кайгы-хәсрәте шулар белән бәйле. Ләкин ил өстенә афәт килә — сугыш башлана. Кызы да сугышка китә. Бик каты кышкы салкында алмагачлар өшиләр. Кешеләрдә бакча үстерү кайгысы калмый, күңелләрендә — дошманны җиңү теләге. Әмма Сәлим абзый алмагачларны да онытмый. Ул, авылдан авылга, мәктәптән мәктәпкә йөреп, кешеләрне алма бакчасы утыртырга димли, үгетли.

Көннәрдән бер көнне аңа берьюлы ике зур бәхетсезлек килә: кадерләп үстергән яшь алма бакчасын давыллап яуган яңгыр сындырып, аударып китә; кызының һәлак булуы турында фронттан хәбәр килә. Сәлим абзыйның бу олы кайгы-хәсрәтен яраткан хезмәте генә бераз җиңеләйтә сыман.

Кешеләрнең күңеле, кәефе илдә бара торган хәлләр белән нык бәйләнгән. 1943 елдан соң, ягъни безнең гаскәрләр немец-фашистларны үз якларына таба куа башлагач, тирә-яктагы авыллардан килеп, Сәлим абзыйдан алмагач үсентеләре алып китә башлыйлар. Тыныч елларда алар тагын да гөрләп үсеп китәрләр. Шулай итеп, С. Хәким яшәүнең дәвамлылыгын, аның бервакытта да туктальп калмавын раслый. Яшәү — үлемнән көчлерәк.

акыл иясе — акыллы кеше (мудрец)
җисем — әйбер, материя
гадәти — гади генә (обыкновенный)
киеренке — кискен (напряженный)
игелекле кеше — күңеле әйбәт, ягымлы, башкаларга ярдәм итәргә торган кеше
кәеф — кешенең халәте (настроение)

Һөнәрләр турында сөйләшү өчен сораулар

Безнең илдә юк оятлы
Һәм кадерсез һичбер эш.
Һәрбер эштә син алдын һәм
Данлы булырга тиеш.

М. Җәлил. «Хат ташучы»

1. Син *һөнәр* сүзен ничек аңлыйсың?
2. Нинди һөнәрләр бар?
3. Сиңа нинди һөнәр ошый? Син кем булырга телисең? Ни өчен?
4. Сезнең туганнар арасында нинди һөнәр ияләре бар? Шулар турында да сөйләгез.
5. «Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс» дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз?
6. Һөнәрләр турында сез тагын нинди мәкальләр һәм әйтемнәр беләсез? Аларның мәгънәләрен аңлатыгыз.

Ләбибә Ихсанова
(1923)

Авыл баласының иң зур бәхете — табигатькә якын булуындадыр. Бусаганы атлап чыгу белән аны яшел яфракларын лепердәтеп, ботакларын киң җәеп утырган өянкеләр, ак чәчәккә күмелгән шомырт, миләш, баланнар көтеп тора. Шунда ук уйнак-шаян бәтиләр, яшь бозаулар, бибиләре белән казүрдәкләр, маэмайлар һәм тагын әллә ниләр... Болар инде сиңа китап битләренә төшерелгән рәсемнәр генә түгел, һәркайсының җаны бар, теле бар... Авылны икегә ярып инеш агып ята. Анда исә үзенә бер дөнья. Авыл очыннан ук куе әрәмәлекләр башлана. Шуңа ук ялганып диярлек урманнары китә. Ерак та түгел Нократ суы... Ләбибә Ихсанова 1923 елның 23 августында табигатьнең әнә шундый бай һәм ямьле бер почмагына утырган Түбән Шөн авылында (Киров өлкәсенең Нократ Аланы районы) укытучылар гаиләсендә дөньяга килә.

Ләбибә хезмәт сөючән, тыйнак, сабыр, әмма максатка омтылучан кыз булып үсә. Югары сыйныфларга күчкәч, ул балалар оешмасына җитәкчелек итә. Урта мәктәпне тәмамлауга, аны колхоз бригадиры ярдәмчесе итеп куялар.

Аннары Казан дәүләт университетының география факультетындагы студент еллары, шул ук чорда әдәбиятка таба ясалган беренче адымнар... Ул табигый рәвештә сабыйлар дөньясына кайта. Аның әсәрләрендәге геройлар нәкъ үз дөньяларында яшиләр, үз холыкларына ятышлы рәвештә хәрәкәт итәләр. Ә бит, чыннан да, балаларның һәр кыланышында, олылар күзлегеннән караганда, беркатлырак күренсә дә, самими бер эзлеклелек, мәгънә, ихласлык була.

Л. Ихсанова әдәбиятка «Көмеш елга», «Җир астында җиде көн» кебек әсәрләре белән килеп керә. Әсәрләренең икесе дә бала чагында, мәктәп һәм студент елларында язучы үзе кичергән вакыйгаларга, шул вакыйгалардан алган тәэсирләргә нигезләнеп язылган. Аларда сурәтләнгән табигать күренешләре дә язучының туган авылы табигатен хәтерләтә.

Язучының әсәрләрендә үз башыннан үткән хәл-әхвәлләр оста файдаланыла. Алар, күзгә әллә ни бәрелеп тормыйча, вакыйгаларга табигый рәвештә үрелеп, сабыйларның, үсмерләрнең үзләренә хас дөнья тудырырга ярдәм итәләр. Шуңа күрә балалар әлеге хикәя һәм повестьларны бирелеп укыйлар да.

Ләбибә Ихсанова әсәрләре башкорт, чуваш, рус, украин, эстон телләренә тәрҗемә ителделәр. Ул — кырыктан артык китап авторы.

Язучының әдәбият өлкәсендәге уңышлары, иҗтимагый тормыштагы активлыгы югары бәяләнә. Ул Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемгә лаек булды.

1996 елда балалар әдәбиятын үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе бирелде.

Сораулар һәм бирем.

1. Л. Ихсанова иҗат өлкәсе итеп ни өчен әдәбиятны, бигрәк тә балалар әдәбиятын сайлый дип уйлыйсыз?
2. Әдип балалар әдәбиятына кайсы әсәрләре белән килеп керә?
3. Аның әдәбияттагы хезмәте ничек бәяләнә?
4. Л. Ихсанованың кайсы әсәрләрен укыганыгыз бар? Алар сездә нинди хисләр уятты?
5. «Саралан малайлары» әсәрен укыгыз һәм бергәләп фикер алышыгыз.

өянке — таллар семьялыгыннан булган агач (ветла, ива)
шомырт — черемуха
миләш — рябина
балан — калина
бәхет — тулы канәгатьләнү халәте, хисе
бозау — теленок
бәти, бәрән — ягненок, барашек
самими — эчкерсез, саф күңелле (искренний, сердечный, душевный)

ЛАЧЫН КЫЗ

Ул кызлар Зур театр алдындагы бакчада очраштылар. Көз көнендәгечә, аз гына буш һәм тын иде. Көмеш тамчыларын җемелдәтеп фонтан да атмый, агачлар да шәрәләнеп калганнар, аларның ялангач ботакларын салкын җил генә кыштырдата. Якаңны күтәреп, тиз-тиз атларга да, җылы өеңә кайтып, китап укып кына утырырга мондый көннәрдә. Ә алар очраштылар да кочаклашып күрештеләр, тирән дулкынлану белән бер-берен карашып, тын гына басып торалар.

Алар белән күрешергә мәһабәт гәүдәле, мөлаем йөзле маршал да килгән. Еллар аның чәчен чаларткан, йөзенә тирән сызыклар уйган. Күзләрендә шатлык яшьләре җемелдәгән маршал каршына күкрәгенә Алтын Йолдыз таккан саргылт чәчле, чандыр гәүдәле бер хатын килеп баса.

— Исәнмесез, авиация маршалы.

— Мәгубә Хөсәеновна! Иптәш Сыртланова! Хәтерлим, хәтерлим...

Күпме сулар акты, күпме җилләр исте ул көннәрдән соң. Шулай да, әле генә, кичә генә булган шикелле, барысы да күз алдында тора. Күз яше һәм кан коела, гөрселдәп ярылган туп тавышларыннан җир сыкрый, канлы ярасын тотып җиргә ауган совет сугышчысының соңгы авазы үч алырга, рәхимсез үч алырга чакыра иде ул вакытта.

Сугышның башыннан бирле санитар эскадрильясендә эшләгән очучы Мәгубә Сыртланованың да көрәшнең зуррак, җаваплырак, куркынычрак җиренә ташланасы, дошманны үз кулы белән тукмыйсы килә. Шундый хисләр, шундый теләкләр белән янып йөргән көннәрнең берсендә ул фронт газеталарыннан данлыклы Тамань полкының очучы хатын-кызлары турында укый. Үзен әнә шул Тамань полкына җибәрүләрен сорап, Төньяк Кавказ фронтының командующие булган генерал янына бара. Каршысында басып торган кечкенә генә чандыр гәүдәле яшь бер кызга генерал сынап карап тора.

— Булдыра алырсызмы соң? Анда эшләү бик кыен булыр. Самолетлар төнлә очалар бит. Очучылар машиналарын тәмәке утына карап кына утырталар, — ди генерал.

Әмма кыз кыю җавап бирә:

— Беләм, иптәш генерал. Ләкин анда минем кебек үк кешеләр оча бит. Алар булдырганны мин дә сынатмам дип уйлыйм.

Генерал риза була. Мәгубә Сыртланованы ул вакытта Грозный шәһәре янында торган Кызыл Байраклы Тамань полкына җибәрәләр.

1942 елның 3 декабре — беренче мәртәбә дошман өстенә очкан төн — аның хәтерендә бик нык саклана. Бу төнне Моздоктагы дошман гаскәрләрен бомбага тотарга бардылар алар. Дүрт мәртәбә очарга туры килде. Күнекмәгән шартларда эшләү бик ардырган, баш авырта, җитмәсә генералның сүзләре «авыр булыр бит, авыр бит!» дип колак төбендә чыңлап тора. Астан дошман зениткалары бәрә, ә анда пыран-заран килгән тимер юл станциясен, дошманның тимер юл эшелоннарын ялкын чолгаган.

Куркусыз татар кызы Мәгубә Сыртланованың сугышчан юлында бик күп була андый очышлар. Ул Кырымда да, Польшада да, Көнчыгыш Пруссиядә дә, Берлин янында да дошманны дәһшәтле утка тота. 182 төнге очыш, 782 мәртәбә үлем белән күзгә-күз, бугазга-бугаз килү иде бу.

* * *

Менә Тамань ярымутравы, Багирово станциясенә кереп оялаган дошман өерен бомбага тотарга кирәк. Диңгездән күтәрелгән куе томан җир өстен калын пәрдә белән каплаган, самолетны җир өстеннән 400—500 метр гына биеклектә алып барырга туры килә. Томан пәрдәсен кайчылаган прожектор нурлары самолетны тотып ала. Моторга пуля тия. Самолеты да, үзе дә яраланган Мәгубә көч-хәл белән Азов диңгезе янындагы кечкенә генә мәйданчыкка төшеп утыра. Мең бәла белән моторны төзәткәннән соң, икенче көнне генә ул дуслары янына очып кайта.

Тамань полкының батыр кызлары дошманга шундый курку салалар, хәтта аларның бу кызыл йолдызлы машиналарда хатын-кызлар түгел, ирләр очуына да ышанасылары килми.

Дошман гаскәрләре арасында бервакыт, совет генераллары самолетларга очучы кыяфәтенә кергән җеннәр утыртканнар, шуның өчен аларны җиңеп булмый, дигән сүз тарала. Шул көннәрнең берендә сугышчан дуслары белән бергә Мәгубә Сыртлановага Көнбатыш Белоруссия урманнарына кереп яшеренгән немецларны куып чыгарырга туры килә. Соңыннан, пленга алынган фашист солдатларына очучы кызларны китереп күрсәткәч, алар шашып калалар.

Лачын кызларның сугышчан юлы Берлиннан 80 километр ераклыкта Бруни шәһәре янында тәмам була. Очучыларның күбесен ялга җибәрәләр. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исемен алган Мәгубә Сыртланова сугышчан самолеты белән Мәскәүдә Җиңү парадында катнаша.

Сугышның буеннан-буена бергә булган, кайгысын да, шатлыгын да бергә кичергән сугышчан дуслар 1945 елның ноябрендә соңгы мәртәбә җыелышка киләләр. Менә шунда ел саен ике мәртәбә — 2 майда һәм 3 ноябрьдә Мәскәүнең Зур театры алдында көндезге уникедә очрашырга сүз куешалар.

Менә Мәгубә Сыртланова үзенең дуслары белән яңадан бергә. Әнә данлыклы полкның батыр командиры Вершанская, әнә Мәгубәнең дусты Тоня Розова. Полкка килгән Тоня яшь кенә, кыюсыз гына бер кыз иде. Очудан бушаган вакытларда Мәгубә аны штурманлык эшенә өйрәтте. Соңыннан алар икесе бер самолетта очып, аерылмас якын дуслар, сердәшләр булып киттеләр. Сугыштан соңгы тыныч тормышта да алар хезмәт алдынгылары булып килделәр...

Сораулар һәм бирем.

1. Әсәрдәге вакыйга кайда бара?
2. Кем ул Мәгубә Сыртланова? Ул нинди батырлыклар эшли, Ватан аның батырлыкларын ничек бәяли?
3. Ни өчен хикәя «Лачын кыз» дип исемләнгән?
4. Мәгубә Сыртланова һәм очучы хатын-кызлар турында тагын нинди әсәрләр укыганыгыз бар?
5. Язучы Шамил Рәкыйповның очучы хатын-кызларыбыз турындагы «Кызлар-йолдызлар», «Кипарислар җыры» повестьларын укыгыз, әңгәмә үткәрегез.

шашып — *монда*: нишләргә белмичә
Җиңү парады — парад Победы
Зур театр — Большой театр
Алтын Йолдыз — Золотая Звезда
хәтерлим — элек булган хәлләрне истә тотам (помню)
гөрселдәп — каты тавыш белән (с грохотом)
пыран-заран килү — тар-мар килү, вак кисәкләргә таркалу
җеннәр — табигатьтән өстен явыз зат (чéрти)
Каһарманы — Герое

КУРКУ БЕЛМӘС ТАТАР КЫЗЫ

(«Лачын кыз» хикәясе турында)

«Лачын кыз» хикәясе — халкыбызның легендар кызы Мәгубә Сыртланова турындагы әсәр. Гвардия өлкән лейтенанты, эскадрилья командиры урынбасары, Советлар Союзы Герое М. Сыртланова сугышчан дуслары, полкташлары күңеленә гадел, туры сүзле дус һәм иптәш, ялкынлы, кыю, курку белмәс батыр очучы булып уелып калган.

Мәгубә Сыртланова төнге бомбардировщиклар полкы очучысы булган. Бу — дөньяда хатын-кызлардан торган бердәнбер шундый сугышчан полк. Ул бирегә үзе теләп килгәндә, кайбер очучыларның инде йөздән артык очышлары була. Мәгубә үзенең кыю, курку белмәс йөрәге белән беренче көннәрдән үк абруй яулый.

Әсәрдән күренгәнчә, кыю хатын-кызларыбыз караңгы төннәрдә, болытлы һава шартларында, чатнама суыкларда, карлы-яңгырлы, җилле төннәрдә дә очалар. Һәм дошманнан үч алалар. Мәгубә Сыртланова шундый очышларда 782 тапкыр катнаша. Татар кызы һәркайчан тәвәккәллеге һәм батырлыгы белән иптәшләренә үрнәк була. Самолеты көчле ут өермәсе эчендә калганда да, моторы зарарланганда да, Мәгубә җиңүче, тәвәккәл булып кала.

Аның образы халкыбызның хәтерендә батырлык үрнәге булып саклана.

БҮЛӘК

Рәшит контроль эш дәфтәрен укытучы өстәленә куйганда, звонок шалтырады. Эшләрен бетергәннәр дә, бетермәгәннәр дә урыннарыннан куптылар. Класста шау-шу башланды.

— Сабыр! Аз гына сабыр итегез, балалар, — диде Мөнәвәрә апалары, ике кулын аларга табан сузып. — Минем сезгә үтенечем бар. Дәресләр беткәч, ун-унбиш минутка калып торыгыз әле. Рәшит, син дә китмәссең.

Мөнәвәрә апалары — класс җитәкчесе. Берәр нәрсә булса, ул аларны җыеп киңәшергә ярата. Үзе бер вакытта да калыгыз, эшләгез дип, дорфа итеп әйтми, шулай җайлап кына, үтенеп кенә сөйләшә. Укучылар әллә шуның өчен яраталар инде аны, әллә бу сөйләшүләр, чыннан да, кызык була, класс җитәкчесен

беркайчан тыңламый калмыйлар. Бу юлы да карышмадылар. Рәшит тә калыр иде, билгеле. Исемен атап әйтмәсә дә.

Нигә шулай дип әйтте икән ул? Күзенә кирерлек булып өстәл янында торганга күрә генәме? Әллә берәр гаебен сизгәнгәме? Кичә алар чак кына дружинниклар кулына эләкми калдылар. Мөнәвәрә апасы әллә шул турыда беләме? Хәзер бөтен класс алдында шелтәләргә телиме? Әнисе бер генә әйтмәде Рәшиткә, уйнамагыз шундый юньсез уеннар, таш ватылып күзегезгә керсә, диде, гомергә гарип калырсыз, диде. Дөресен генә әйткәндә, ул көнне Рәшитнең чыпчык борыны хәтле дә гаебе юк иде бу эштә. Ишегалды малайлары таш ярыгына шырпы күкерте тутырып «бомба» шартлатканда, аның узып барышы иде. Ләкин... узып китә алмады. Бар, ышандыр инде син хәзер укытучыны, күкертне мин тутырмадым, тимер белән сугучы да мин түгел идем дип әйт. Мөнәвәрә апасы барыбер ышанмас, башын чайкап торыр-торыр да шул ягымлы, йомшак тавышы белән:

— Рәшит, алдаларга өйрәнмә, үтенәм синнән, — дип әйтер. Шулай да озак баш ватып торучылардан түгел иде Рәшит. Борчулы, ямьсез уйларны озак уйлап торырга яратмый иде ул. Дружинниклар турында оныту өчен дә дусты Фәритнең килеп дәшүе җитте. Өстендәге тузанны кагып төшерделәрмени, шик-шөбһәләре коелды да бетте.

Мөнәвәрә апалары ишектән үк елмаеп керде. Кулындагы ачык конверт белән зәңгәр тартманы өстәлгә куйгач та әле, ак тешләрен күрсәтеп укучыларга карап алды.

— Безнең класска күңелле хәбәр килде, балалар, — диде ул, үзе шул хәбәрне берьюлы әйтеп салырга ашыкмыйча, әкрен генә конвертны ачты.

Барысы да үрелеп аның кулына карадылар. Менә хәзер шушы конверт эченнән сөенечле хәбәр ак күгәрчен булып очып чыгар кебек тоелды.

Рәшитнең дә бу турыда тизрәк беләсе килә иде. Сабыр гына көтеп тора алмады, партадашы Фәритнең янтыгына төртте:

— Бәхәсме? Тартма эчендә микроскоп.

— Булган ди сиңа, бар. Бик беләсең килсә, сәгать әле ул.

— Син үзең сәгать! Күкеле сәгать! Күк-күк!

Фәрит дустының үртәвенә түзеп калмас иде, Рәшиттәге тел анда да бар. Класс җитәкчесенең тавышын ишетеп кенә тыелды. Шулай да күрсәтер әле аңар Фәрит күкеле сәгатьнең ни икәнен. Кайтырга гына чыксыннар.

— Рәшит, бәлки, син безгә үзең сөйләрсең, — диде укытучы, кулындагы хатны күрсәтеп. — Монда кыска гына язганнар.

Рәшит тә, Фәрит тә, укытучының тавышына сискәнеп башларын күтәрделәр һәм шунда бөтен классның үзләренә карап торуын абайладылар. Мөнәвәрә апалары да аларга карап нидер көтә иде. Нәрсә көтә алар? Рәшит нәрсә сөйләргә тиеш? Бәхәсләшеп, малайлар сүзнең ни турында барганын аңламый калганнар иде. Хәзер шуңар аптырап утыралар. Дәресен әзерләми килгән вакыттагы кебек, Рәшит теләр-теләмәс кенә торып басты. Нәрсә әйтергә белмичә, укытучыга карап куйды, Фәриткә карады, класска.

— Ну, мин... без... ни...

— Син, Рәшит, каушама, — дип укытучы ярдәмгә килде. Ул малайны әле генә әйтелгән хәбәрдән телсез калган, дулкынланган дип уйлый иде. — Ашыкмыйча гына сөйләп күрсәт, колхозда нәрсәләр эшләдегез?

Менә тагын бер табышмак. Колхозда эшләүнең монда ни катнашы бар әле? Җәй көне колхозда эшләгән малайлар бер ул гынамы әллә? Әнә Фәрит ай буе дәү абыйсының комбайнына утырып йөрдем дип мактанды. Андый машиналарның якынында да булмады Рәшит. Җәй буе чөгендер үстерделәр. Аның нәрсәсен сөйлисең инде? Әллә ниләр уйлап чыгара бу Мөнәвәрә апа...

Ну... авылга барды, ди. Барса соң. Җәйге каникулда балаларның күбесе я авылга, я дачага китә. Рәшитләрнең дачалары юк, ул ел да әбисе янына, авылга кайта. Андагы малайлар белән дуслашып бетте инде ул. Укулар беткәч, Рәшит кайчан кайта дип, әбисен йөдәтеп бетерәләр икән. Колхозда эшләве дә инде... Иптәшләре эшкә йөргәндә, өйдә берүзе ятсын димени, бөтен кызыгы да аның — иптәшләрең белән бергә булуда.

Алар колхозының чөгендер басуы Ташлы елга буенда. Менә елга дисәң дә елга инде ул. Күргәч, малай шаккатты. Катарсың да шул. Бүтән елларны аның суы табан астын чылатырлык кына була торган иде. Ә быел Идел хәтле булып җәелгән. Пароход җибәрсәң дә йөзәрлеге бар. Малайлар әйтәләр, чөгендер белән кукуруз басуын сугарыр өчен колхоз буа ясады, диләр. Төбен үлчәп караганнар икән, өч метрлы бау җитмәгән.

Коенып та карадылар инде ул җәйне малайлар, дельфин балыгы кебек чума-чума, сикерә-сикерә йөзәләр. Йөзә белмәгәннәр

яр читендә чупырдаша. Барыбер рәхәт. Шулай да бар дөньяны онытырга ярамый. Малайлар дигәндә дә, чүп-чар бала-чага түгел инде алар. Өлкәннәр тәгәрәп бетеп эшләп йөргәндә, елга буенда уйнап яту оят булыр. Үзебез үстерәбез дип колхоз идарәсенә сүз биреп, бүлеп алган чөгендер җире дә бар бит әле. Шуны утап, сирәкләп чыгасы бар. Ә басу бәләкәй түгел, чөгендере дә әкрен үсми, чүбе дә аннан калышмый. Утый башласаң, сирәкләргә соңарасың, сирәклим дисәң, чүбе алып уза. Койрыгын алса, башы ябыша, башын алса, койрыгы ябыша торган саескан турындагы мәзәк кебек. Ә вакыт үтә тора. Бер көнне әбәт ашап утыралар иде шулай, Рәшит үзе дә сизмәстән сикереп торды да:

— Ризамы! Чөгендерне бетермичә авылга кайтмыйбыз! Төнлә шушында кунабыз да иртүк торып тагын эшкә тотынабыз! Ризамы шуңар? — диде ул, баш түбәсендәге кояштан да ныграк кайнарланып.

Ат саклап төн кунган малайлар турында хикәяләр укыганы бар иде аның. Кызыга иде ул аларга. Кап-караңгы төн. Төн карасыннан пошкырынып, атларның үлән кыркыганы ишетелә. Чатыр-чотыр учак яна. Ә учакта... бөтен пирожныйларыңнан, морожныйларыңнан да тәмлерәк булып, бәрәңге пешә. Шул учактан чәчрәп чыккан утлы күмер кебек йолдызларга карап чалкан ятасың да малайларның берсеннән-берсе куркынычлырак әкиятләрен тыңлыйсың. Хәзер авылда ат сакларга йөрмиләр икән инде. Сакларлык атлары булмагач, кая йөрсеннәр. Ташлы елга буенда болай гына төн куну да начар булмас иде ул.

Рәшит кебек чәчрәп төшмәсәләр дә, иптәшләре бу тәкъдимгә риза иде. Авылдан читтә, ачык һавада төн куну алар өчен кызык түгелме әллә? Тик бу әйбәт сүзнең үз авызларыннан түгел, шәһәр малаеннан ишетүләренә генә аптырап калдылар. Каян башына килгән диген! Бик тиз күтәреп алсалар да, җиңел генә җайланып китмәде бу эш. Иң элек кызларны әниләре җибәрмәде. Колхоз агрономы палаткалар табып китергәч кенә риза булдылар. Ашау-эчүякларын да карыйсы бар иде. Шуларның барысы да эшләнгәч, балалар үзләре адәм көлкесенә калдылар. Беренче кичне, учак ягып, бик озак сөйләшеп утырганнар иде, иртәгесен тора алмадылар. Агроном килеп:

— Йокы чүлмәкләре, торыгыз инде, торыгы-ыз! — дип уятмаса, төшкә тикле йоклыйсылар икән.

Шуннан соң чиратлашып дежур торырга булдылар. Күпкә түгел. Ташлы елга буеннан бер чумып кайтуга, вакыт үтә дә китә. Шуннан палаткага кереп, берсенең аягыннан тартып торгызасың да җылы урынына ятып изрәп китәсең.

Бер төнне Рәшитнең чираты таң алдыннан, йокының иң тәмле чагына туры килде. Ай, читен икән ул таң алдыннан торулары! Күзне ачып булмый. Аның каравы, авызың йомылып тормый. Исни-исни яңаклар авыртып бетә. Табан астыннан салкын менеп тәнне чымырдата. Шулай да Рәшит түзә. Ярты сәгать түгел, төн буе дежур торасы булса да, сүз әйтмәс иде. Үзе башлаган эш бит.

Бөтен дөньяны ак томан баскан иде ул таңда. Палаткалар да, яр буендагы таллар да — барысы да томан эчендә. Рәшит кая таба атларга белми аптырап торганда, шул томан пәрдәсе артыннан әкрен генә бер тавыш ишетелде:

— Син кайда — ау?

Рәүфә тавышы. Агроном кызы. Кызлар ягыннан ул дежурга чыкты.

— Мин монда — ау!

Икәү бергә күңелсез түгел. Рәүфә сөйләшергә ярата.

— Минем эти сине мактады, — ди. — Әйбәт малай, дип әйтте.

Мактаганны бар да ярата. Рәшиткә дә күңелле. Тагын бер тапкыр ишетәсе килеп, әйбәтме соң, дигән була.

— Әйбәт шул! — ди Рәүфә.

Сөйләсәң сөйләрлек сүзләр бар инде, анысы, Рәүфә турында әйтеп тормасаң да. Каушап калу гына эшне бозды.

— Чөгендер... үсте инде ул...

Ярый әле Мөнәвәрә апалары хәлгә керде. Малайлар инде авыз җыра башлаганнар иде, Рәшитне кызганып кире утыртты.

— Менә шулай, балалар, җәй көне колхозда тырышып эшләгәне һәм чөгендердән зур уңыш алуда булышканы өчен «Якты таң» колхозы Рәшит Батыршинны фотоаппарат белән бүләкли, — диде һәм балаларның күзен кыздырып торган зәңгәр тартманы ачты.

Җилкәгә аса торган озын каешлы фотоаппаратны күргәч, класс аһ итте.

— Шә-әп!

— Чын фотографларда гына була бу.

— Менә бәхет!

Рәшит тә укытучы кулындагы бүләккә карап шаккатып утыра иде. Бу юлы аның янтыгына Фәрит төртте:

— Бар инде, ал бүләгеңне.

«Якты таң»нан килгән бүләкне алганда, Рәшитнең колагына Рәуфә тавышы ишетелгәндәй булды:

— Әйбәт шул!

Сораулар һәм биремнәр.

1. Хикәядә вакыйга кайда бара?
2. Ни өчен Рәшит, Мөнәвәрә апалары дәрестән соң калырга кушкач, бераз шүрләп кала?
3. Рәшит җәйге ялны кайда һәм ничек уздырган?
4. «Якты таң» колхозы Рәшит Батыршинны ни өчен фотоаппарат белән бүләкли?
5. Хикәядәге «әйбәт шул» сүзләре кемгә карата һәм нинди вакыйгага бәйле әйтелә?
6. Таң алдыннан булган табигать матурлыгы турындагы юлларны табып, кычкырып укыгыз. Сезнең таң атканны күзәткәнегез бармы? Бу күренешне үз сүзләрегез белән тасвирлагыз.

звонок — кыңгырау
сабыр — тыныч, ашыкмыйча (терпеливо, спокойно)
дорфа — тупас (грубо, невежливо)
шелтәләргә — ачуланырга (укорять, упрекать)
ишегалды — йорт тирәсе (двор)
гарип — берәр җире имгәнгән, зәгыйфьләнгән кеше (калека)
алдаларга — дөресен сөйләмәскә (обмануть)
янтык — гәүдәнең ян ягы (бок)
йокы чүлмәге — йокларга яратучы (засоня)
төшкә тикле — көн үзәгенә кадәр (до обеда)
җилкәм — ике кулбаш арасы (плечо)
чөгендер — яшелчә (свекла)
шүрләп — куркып

ҖӘЙГЕ ЯЛ ИСТӘЛЕГЕ

(«Бүләк» хикәясе турында)

Язучы балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне әйбәт белеп яза. «Бүләк» әсәрендәге Рәшит, Фәрит, Рәуфә кебек образларның үз-үзләрен тотышлары нәкъ шул яшьтәге үсмерләргә хас

булганча сурәтләнгән. Ә бит, чыннан да, үсмерләрнең һәр сүзендә, эш-гамәлендә алар өчен генә гадәти, табигый булган үзенчәлекләр була. Рәшит тә бик аз гына вакыт эчендә үзе белән булган хәл-әхвәлләрне тиз генә искә төшерә, аларга үзенчә бәя бирә.

Шәһәрдән җәйге ялга кайткан Рәшит кул кушырып, кояшта кызынып ятучы малай түгел. Ул үзендә өлкәннәргә булышырлык көч сизә. Рәшит — һәр нәрсәне төптән уйлап, җае белән хәл итәргә яратучы тыйнак табигатьле малай. Ул авылдагы дуслары белән чөгендер җирен эшкәртү эшенә керешеп китә. Кырда кунып-төнеп алар чөгендер җирендә чүп утыйлар. Колхозга зур ярдәм күрсәтәләр.

Менә каникуллар бетә, Рәшит тә шәһәргә кайта. Мәктәпләрдә укулар башлана. Рәшит һаваланып, мактанып йөрүче малай түгел. Әмма тырышлык бәя алмый калмый. Колхозда яхшы эшләве өчен классташлары алдында бүләк алу аңа бик күңелле була. Монда да ул тыйнак булып кала. Әнә шул тыйнаклыгы аны сөйкемле итә дә.

Хикәядә кеше гомеренең мәктәп елларына туры килә торган бер мизгеле сурәтләнә. Әлеге чорда балалар һәм үсмерләр аеруча хәрәкәтчән була, көчләре ташып тора. Ләкин бу хәрәкәтчәнлек аларны уңай якка да, тискәре юнәлешкә дә алып китәргә мөмкин. Рәшит бер файдасыз гомер уздыручыларны яратмый. Авылда һәммәсе хезмәткә хөрмәт белән карый, ул да күмәк эштән читтә кала алмый. Димәк, яшь кешегә әйләнәтирәдәгеләр нык йогынты ясый икән. Киләсе җәйдә ул тагы да тырышыбрак эшләр дип уйларга кирәк.

Рәшитне фотоаппарат белән бүләкләгәндә, сыйныфта утыручылар да үзләренә нәтиҗә ясамый калмаганнардыр: җәйне, димәк, файдалы хезмәт белән уздырырга кирәк. Иң бәхетле бу мизгелдә Рәшит авылда калган Рәүфә исемле кызны исенә төшерә. Бергәләшеп эшләү аларны шулай бер-беренә якынайткан. Әйбәт дусларың булу — үзе зур бәхет.

Равил Фәйзуллин

(1943)

Халык талантларга бик бай. Егерменче гасырда гына да милләтебез Г. Тукай, Дәрдемәнд, М. Гафури, С. Рәмиев, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, С. Баттал, Н. Арслан, С. Хәким, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Р. Харис, Ф. Яруллин кебек шагыйрьләрен үстерде. Алтмышынчы елларда әдәбиятка Равил Фәйзуллин дигән шагыйрь килде.

Казаннан ерак та түгел Балык Бистәсе районы бар. Ул Чулман (Кама) елгасы буена сыенып утырган. Равил 1943 елның 4 августында табигатьнең бик матур урынында урнашкан Балтач дигән авылда дөньяга килә. Ул кечкенәдән үк зирәк акыллы була. Гадәти генә күренешләр турында да кызыклы, көтелмәгән сүзләр әйтеп, олыларны еш кына таң калдыра. Котлы Бөкәш авылындагы урта мәктәптә укыганда, ул тел, әдәбият һәм тарих дәресләрен бик ярата. Аның Казан университетындагы татар теле һәм әдәбияты факультетына укырга керүе дә очраклылык булмый. Бу мәһабәт уку йортында югары белем алып чыгуга ук, аны Язучылар берлегенә кабул итәләр. Димәк, аның шагыйрь булып җитлегүен рәсми рәвештә дә таныйлар.

Равил Фәйзуллин баштан ук яңача уйлануларга нигезләнгән шигырьләр иҗат итте. Аның әсәрләрен, татар укучыларыннан тыш, башка милләт кешеләре дә яратып укый. Шигырьләре башка телләргә дә тәрҗемә ителде. Г. Тукай, М. Җәлил исемендәге бүләкләргә ия шагыйрь — хәзерге әдәбиятыбыздагы төп иҗат көчләребезнең берсе. Аңа Татарстанның халык шагыйре дигән исем бирелде.

Шагыйрь Р. Фәйзуллин шигырьләрендә фикерне бик җыйнак һәм тирән итеп әйтеп бирә. Бу аның дөньяны, табигатьне, кешеләрне үзенчә күрүеннән, аңлавыннан һәм бәяләвеннән килә.

Ул балалар өчен дә матур-матур шигырьләр яза.

«Рәсем ясыйм», «Чәчәкләр үстердем», «Якты моң» исемле шигырь китапларын балалар бик яратып укыйлар.

Башкарган эшеңә
ни дияр —
    Ватаның,
    әтиең,
    әниең?
Аларның хөкеме —
иң гадел — бердәнбер!

Әтиең, әниең
куанып туя алмас,
Әйтсәләр кешеләр:
«Ул егет — илдә бер!
    Илдә бер!»

(*«Бердәнбер»*)

Күрәбез, ул, балалар өчен язганда, тәрбияви максатны, аларның акылын, уйлау сәләтен үстерүне күздә тотып иҗат итә.

Равил Фәйзуллин шигырьләренә композиторларыбыз көйләр дә язды. «Сагыш», «Тимим күңелемә», «Аккошлар», «Менә без дә үсеп җиттек, әни» җырлары әнә шундыйлардан.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Равил Фәйзуллинның әдәбиятка килү юлы турында сөйләгез.
2. Шагыйрь ни өчен Ватанны, әти-әнине иң гадел бәя бирүчеләр дип атый? Моның шулай булуына үз тормышыгыздан мисаллар китерә аласызмы?
3. «Ул егет — илдә бер!» дигән җөмләне сез ничек аңлыйсыз?
4. Шагыйрь сүзләренә язылган җырларны тыңлагыз, аларның үзенчәлекле якларын аңлатыгыз.
5. Р. Фәйзуллинның иҗаты ничек бәяләнде?

очраклылык булмый — юкка гына булмый, бер сәбәпсез генә булмый
мәһабәт — данлыклы, мәшһүр
рәсми — официаль
җитлеккән — өлгергән
хөкеме — карары, уе, фикере
янчык — бәләкәй капчык
бердәнбер — бер генә (единственный)

КҮМӘЧ ПЕШЕРҮЧЕЛӘР ҖЫРЫ

Сез кем, дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!
Кешеләрнең йөзләренә
Шатлык төшерүчеләр без!
Күмәч кебек йомшак түгел,
Үзебез каты куллыбыз:
изә, баса, туглыйбыз;
йоп-йомшак камырны
кайнар мичкә юллыйбыз.
Күмәчләрнең йөзе килсә,
бөркелеп хуш исе килсә,
нечкәрә күңелебез:
сөенәбез, көләбез —
бик сабый күңелле без.

Күмәч пешерүчеләр без!
Пешерәбез йөземлесен,
мәклесен һәм мәксезен,
түгәрәген, сырлысын...
Табыныбыз мул булсын!
Әйдә, кайчак он кунсын,
куллар камырда булсын!
Тик эшебез эшчәннәрнең
хезмәте чаклы булсын,
күзләрдә чаткы булсын,
йөзебез якты булсын!

Сез кем, дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!
Без күп телләр белмибез,
күп илләрне гизмибез,

алтын белән диварларда
язылмый исемебез,
икмәк кебек гап-гади,
күмәч пешерүчеләр без!
Эшебез, ай-яй, тыгын,
сөйләшмибез артыгын,
кабарт, из, бас тизрәк,
әвәлә, сал тизрәк!
Күмәч кирәк! Күмәч кирәк!
Эшчегә, язучыга да,
саллар агызучыга да,
очкыч җибәрүчегә дә,
пыяла өрүчегә дә,
терлек карауычыга да,
полярник, аучыга да,
речь сөйләүчегә дә,
чалгы көйләүчегә дә,
хөкүмәт башлыгына да —
барысына да, барысына да
күмәч кирәк, күмәч кирәк!
Кабарт, из, бас тизрәк,
әвәлә, сал тизрәк!

Күп кешеле зур чатлар,
светофор-маяклар,
машина-самокатлар,
авырсынмый юл бирсен!
Әбиләргә, бабайларга,
әтиләргә, әниләргә,
сеңелләргә, энеләргә,
абыйларга, сабыйларга
чәйгә күмәч өлгерсен!
Иртән дә күмәч булсын,
көндез дә күмәч булсын,
кичен дә күмәч булсын,
урта бер җирдә
табынның
кояшы булып торсын!
Сез кем, дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр без!

Кешеләрнең йөзләренә
шатлык төшерүчеләр без!
Сез кем, дип сорыйсызмы?
Тәнгә, кул-аякларга
хәрәкәт бирүчеләр без!
Сез кем, дип сорыйсызмы?
Тереклеккә гел яшәргә
куәт бирүчеләр без —
күмәч пешерүчеләр без!
Ә соң сез
үзегез
кем?

Сораулар һәм бирем.

1. Ни өчен күмәч пешерүчеләр үзләре турында «Кешеләрнең йөзләренә шатлык төшерүчеләр без» диләр?
2. Икмәк кеше тормышында нинди әһәмияткә ия? Халкыбыз аңа ни өчен аеруча хөрмәт белән карый?
3. «Үзебез каты куллыбыз» дигән фикерне сез ничек аңлыйсыз?
4. Күмәчнең йөзе килү нәрсә ул?
5. «Икмәк кебек гап-гади, күмәч пешерүчеләр без» дигән юллардан сез ни аңлыйсыз?
6. Икмәк өстәлебезгә килсен өчен, тагын кемнәрнең хезмәте кирәк?
7. Авыл кешеләренең икмәккә аеруча хөрмәт белән каравының сәбәбе нидә?
8. «Күмәч пешерүчеләр җыры» шигыренең үзегезгә аеруча ошаган өлешләрен яттан сөйләргә өйрәнегез.

күмәч — ак оннан пешерелгән икмәк, ак ипи
йөзе килсә — кызарып пешсә
йөзем — җимеш (виноград)
мәк — чәчәк (мак), *монда*: мәк орлыгы
терсәк — локоть
сал — плот
пыяла өрүче — өреп пыяла әйберләр ясаучы (стеклодув)

Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс

ИКМӘК ЙӨЗЕ

Без еш кына космонавтларны, атаклы галимнәрне, язучыларны, артистларны зурлыйбыз, алар белән хаклы рәвештә горурланабыз. Бу шәхесләрнең тормышы да безгә ниндидер серлелек белән өртелгән кебек тоела. Ләкин шул ук вакытта

И. Рәфыйков. Ана һәм бала



Р. Заһидуллин. Казан. XVI гасыр башы

Х. Якупов.
Терлекче
М. Галиуллина
портреты

безнең әйләнә-тирәбездә никадәр кызыклы кешеләр яши. Аларның һөнәрләре дә гадәти генә булырга мөмкин: игенче, эшче, терлекче, табиб, укытучы, сатучы һәм башкалар. Һәммәсе дә үз урынында бик кирәк һәм кадерле. Күз алдыгызга китерегез: без көн саен өстәлдә ипи күрергә гадәтләнгәнбез. Ипи булмаса, табынның яме калмый, аннан башка тамак туймый. Икмәк — бөтен ризыкларның да иң кирәклесе.

Без һәр көнне кибеттән икмәк сатып алабыз. Кибеткә исә ул бик ерау юллар үтеп килә, аңа күпләр зур хезмәт куя.

Игенче җирне эшкәртә, йомшарта, чәчә, игенне тәрбияләп үстерә, урып ала, җилгәрә. Ашлыкны тегермәндә он итеп тарталар. Шуннан соң гына ул икмәк пешерүчеләр кулына килеп керә.

Икмәк пешерү — гаять мәшәкатьле һәм осталык таләп итә торган эш. Авылларда кайбер гаиләләрдә ипине әле дә үзләре пешерәләр. Ипи салган көн (ипи пешерүне ипи салу дип әйтү гадәткә кергән) өйдә үзенә күрә бәйрәм кебек була. Моңа әзерлек кичтән үк башлана. Әби яки әни бик әйбәтләп, пөхтәләп кул-битләрен юа, әйтерсең лә операциягә әзерләнүче хирург. Ул әлеге эшкә керештеме, өйдәгеләр һәммәсе аңа буйсыналар, аның кушканнарын төгәл үтиләр. Башта күәс чиләгенә баш ясап куела, ягъни әче камыр әзерләнә. Аннан соң бик һәйбәтләп он иләнә. Он җылынгач, аны теге әче камыр өстенә, ягъни күәс чиләгенә салалар, тозын, башка тәмләткечләрен салып, бер төерчеге дә калмаслык итеп болгаталар. Күәс чиләген һава кермәслек итеп каплап, чиста япма белән бәйләп куялар. Икмәк салучы әле моның белән генә канәгатьләнми, төнлә торып, күәс чиләгенә колагын куеп тыңлап-тыңлап ала. Камыры әйбәт кабарамы-юкмы, шуны тикшерә. Иртән иртүк торып, миченә ягып җибәрә. Монысы — үзе бер зур эш. Өйдәге ир-атлар ипи салу өчен утынның корысын, әйбәт яна торганын, күмерне күп төшерә торганын сайлыйлар. Кичтән өйгә кертеп, мичкә уңайлап тутырып куялар. Кирәк вакытта шырпы сызып, каен тузына ут төртеп җибәрерлек кенә булсын.

Мич була башлагач (ягъни мич кызып җиту дәрәҗәсенә якынлашкач), ипи салучы камырга он өсти-өсти бик әйбәтләп изә, ипиләрне әвәли, мичнең төбен чистартып, ипиләрне шунда тыгып куя. Балалар өчен кечкенә ипиләр салырга да онытмый.

Ипи пешкән арада, өй тәртипкә китерелә, хәтта идәннәр дә сөртелеп алына. Өйдәгеләрнең кәефе шат, чөнки мичтә ипи

пешә! Аның хуш исе бөтен өйгә тарала. Алай гына да түгел, әлеге өй турыннан узып баручыларның да борыннарына ипинең хуш исе керә.

Ниһаять, иң тантаналы вакыт җитә. Ипи салучы бу мизгелне бик борчылып көтә: ризыгы уңганмы, юкмы? Менә мич капкачы ачыла. Ипи уңган, йөзе килгән булса, хуҗа хатынның күзләре нурлана, йөзе куанычыннан алсуланып китә. Бу вакытта инде өстәлдә самавыр җырлап утыра. Яңа пешкән икмәкнең хуш исенә кушылып, чәйнең гаҗәеп затлы тәме бөтен өйгә тарала. Һәммәсе дә өстәл янына тезелешеп утыралар. Беренче икмәкне гаилә башлыгы бик кадерләп кулына ала, бисмилласын әйтеп, сындыра-сындыра өлешләп бирә (мичтән генә чыккан кайнар ипине, гадәттә, кисмиләр). Һәммәсе икмәктән авыз итә, тәмләп-тәмләп чәй эчә. Шул рәвешле, ипи салган көн гаилә бәйрәменә әверелә.

Әлбәттә, икмәкне кибеттән генә алып керү безне күп кенә гадәт-йолалардан мәхрүм итә. Икмәкне гадәти генә ризык дәрәҗәсенә төшерә. Ләкин икмәк пешерүчеләр үзләре бу изге эш белән горурланалар, аны яратып башкаралар. Шагыйрь Р. Фәйзуллин да моның шулай икәнен бик матур итеп сурәтләп биргән. «Кешеләрнең йөзләренә шатлык төшерүчеләр без!» — диләр алар.

урау юл — әйләнечтән салынган юл; *монда*: күп мәшәкатьләр белән бәйле юл
күәс чиләге — камыр куя торган зур чүлмәк яки агач кисмәк
бисмилласын әйтеп — берәр төрле эш башлар яки юлга чыгар алдыннан әйтелә торган изге сүз
гадәт-йолалардан — *монда*: өйдә ипи салуга бәйле эшләрдән
йөзләренә шатлык төшерүчеләр — кешеләрне шатландыручылар (кеше шатлана икән, аның йөзе дә балкып, матурланып китә)

Фатих Хөсни

(1908—1996)

Бирем һәм сорау.

1. 5 сыйныфта үткәннәр буенча Фатих Хөснинең тормыш юлын искә төшереп сөйләгез.

2. Алдагы сыйныфларда Фатих Хөснинең кайсы әсәрләрен укыдыгыз? Бу әсәр сезгә ошадымы? Ни өчен?

СӨЙЛӘНМӘГӘН ХИКӘЯ

Бу хәл минем балалык дустым Биктимер башыннан узган бер хәл булганга һәм ул тарихны кешегә сөйләргә Биктимер ризалык бирмәгәнгә, хәзергә чаклы беркемгә дә сөйләми йөрдем. Дөрес, аны сөйләргә телем кычыткан минутлар аз булмады, ләкин ничә әйтсәң дә бер сүз, без Биктимер белән бик дус идек шул. Хәзер инде Биктимер үсте, чабатачы Әхми малае сипкелле Биктимердән инженер Биктимергә әйләнде. Әллә кайчан булып узган бер тарихны кешеләргә сөйләп бирүем өчен ул миңа, шәт, үпкәләмәстер. Тагын шул чаклысы да бар: Биктимер минем тел бистәсе булуымны, лыгырдарга яратуымны бик яхшы белә. Шуларны искә алып, ул мине гафу итсен, сөйлим дә бирәм.

...Моннан байтак еллар элек, революциягә чаклы ук, Биктимернең әтисе Әхми абзый, ул вакыттагы алама гадәт буенча, «Чабатачы Әхми» яисә «Төк кунмас Әхми» дип йөртелә торган чакта, көннәрнең берсендә, Биктимернең әнисе Маһруй җиңги коймак пешерергә уйлый. Тукта әле, безнең авыз да коймак ашап карасын бер, дип үзеннән-үзе сөйләнеп ала ул һәм, шулай итеп, коймагына баш ясап куя. Коймак бик яхшы булып әчи, кабара, бер сүз белән әйткәндә, «менә авызга керәм... менә керәм» дип чымырдап тора башлый. Шуннан соң ул,

әлеге безнең Маһруй җиңги, коймакны пешерү нияте белән, мич ягып җибәрә. Мич яккач таба кирәк, коймакны бит учта пешереп булмый. Аларның исә мич астында күгәреп беткән ярык бер табалары гына бар.

— Ай Алла! Тагын кешегә барырга кирәк,— дип тирән генә көрсенеп куя Маһруй җиңги. Ләкин, нәрсә генә булмасын, башлаган эшеннән кире кайтырга һич кенә дә уйламый.

Мич башында кыштыр-кыштыр килеп чабата киндерәсен ялгап маташа торган кечкенә Биктимергә кычкыра:

— Бар, Биктимер, хәзер үк Чат Җамалиларга йөгер, әни таба сораган иде, табагызны биреп торыгыз әле, диген.

Яшереп булмый, Биктимернең сүз тыңлый торган гадәте кече-кечкенәдән бар иде. Андый шатлыклы көнне, әйтик, коймак пешерелә торган көнне, аның ул гадәте бигрәк тә көчәеп киткән, күрәсең. Анасы әйтү белән Биктимер, чабата киндерәләрен дә бәйләп тормыйча, мич башыннан атылып төшә дә иске бишмәте белән иске бүреген тиз генә эләктереп, чыга башлый. Ләкин ул чыгып өлгерми, Маһруй җиңги, аны туктатып, тагы бер кат бик ныклап тукый:

— Аягың тигән җиргә тисен, тимәгән җиргә тимәсен, югыйсә камырым ташый, хәзер үк кайт. Ишеттеңме?

— Ишеттем,— ди Биктимер.

Тагын бер кат «Ишеттеңме?» дип сорый Маһруй җиңги, тагын бер кат «Ишеттем» дип җавап кайтара Биктимер.

— Ишетсәң шул, бер җирдә дә тукталып торма, йөгереп бар да йөгереп кайт,— дип, өченче кат тукый анасы. Биктимер тәмам чыгып киткәч, капка төбенә килеп җиткәч, Маһруй җиңги аны тагын туктата:

— Болай гына булмас син ачык авыздан. Син, Биктимер, барганда да, кайтканда да авыз эчеңнән «Әнинең камыры кабара, әнинең камыры кабара» дип кабатлап бар. Ишеттеңме?

— Ишеттем,— ди Биктимер һәм шул минуттан башлап «Әнинең камыры кабара»ны кабатларга да тотына. Чат Җамалиларга барып җиткәнче кабатлап бара. Чат Җамалиларның ишек төпләрендә дә гел кабатлап тора. Хәер, аңа Чат Җамалиларда озак торырга туры килми. Табалары буш булганлыктан, тегеләр зур гына бер табаны Биктимергә тоттырып җибәрәләр. Кайтырга чыга Биктимер. Үзе йөгерә, үзе һаман «Әнинең камыры кабара»ны авыз эченнән кабатлап кайта. Күрәсез, бөтенесе ал да гөл булып, коймак дигәнең авызга үзе шуып керергә тора.

Шулай итеп, безнең Биктимеребез авыз эченнән әлеге дә баягы «...кабара»ны кабатлап, ә куллары белән зур табаны кочаклап кайтып килгәндә, бәхеткәме, бәхетсезлеккәме каршы, аның юлы Чишмә тавына килеп чыга, ә тауда су сибеп катырган, көзгедәй шугалак була. Шугалакта бала-чагалар шау-гөр килеп чана шуып уйныйлар. Бу чаналы малайлар Биктимернең иптәшләре булмасалар да, аларның кычкыра-кычкыра чана шуулары Биктимерне кызыктыру өчен җитә кала. «Эх... минем дә чанам булса...» дип, эчке яну белән уйлап куя Биктимер. Ләкин аңа карап Биктимернең чанасы булмый. Ә чанасы булмауга карап, Биктимер шулай ук мәлҗерәргә һич тә уйламый. Балаларча кызыгу белән кызыгып, озаклап карап тора. Бу минутта аның кечкенә йөрәге күкрәген бәреп тышка чыгарга теләгәндәй тыпырчына. Ләкин, аның күзләре матур дип, аңа берәү дә үз чанасын китереп тоттырмый. Чаналы малайларга сер бирәсе килмәгән Биктимер, аны-моны уйлап тормастан, кулындагы табасын куя да, шуңа утырып, шугалактан тау астына шуып төшеп китә. Тел белән сөйләп, каләм белән язып бетерә алмаслык бәхет эчендә күмелеп кала Биктимер. Тагын менә, тагын төшә, менә, тагын төшә. Бөтен нәрсәне, шул җөмләдән ашауны да, шул җөмләдән «Әнинең камыры кабара»ны да онытып, шуып уйный башлый ул. Биктимернең табасы, чаналардан уздырып, үзенә бер тавыш белән зыңгылдап шуа. Бу нәрсә башка малайларның күзләрен яндыра. Малайлар, чаналарын ташлап, Биктимергә кызыгып карап тора башлыйлар. Моны күргәч, Биктимер, шатлыгыннан канатланып, җырлый-җырлый, берүзе шуарга тотына... А... Моны тыныч кына сөйләп тә булмый, моның рәхәте ничек булгандыр дисез сез!

Бер сүз белән әйткәндә, Биктимернең куллары канатларга әйләнәләр. Чабатачы Әхми малае сипкелле Биктимер, әкиятләрдә сөйләнә торган канатлы кешегә әверелеп, иртәдән кичкә чаклы бәхет томаны эчендә очып йөри. Бервакытны, әйтик, канатлары киредән кулга әйләнгәч, әйтик, бәхет томаны бераз тарала төшкәч һәм Биктимер инде оча торган малай түгел, ә иске бүрекле Биктимер булып калгач, ул, айнып, күзләрен ачып җибәрә. Бу вакытта инде, кояш баеп, күктә беренче йолдызлар күренә башлаган була. Биктимер, әнисен күз алдына китереп, «әни... кабара...» дигән сүзләрне өзек-өзек кабатлап куя. Ә бераздан соң инде, бозланып каткан итекләрен

Шәүкәт Галиев

(1928)

Сораулар.

1. Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев исеме сезгә танышмы? Аның турында ниләр беләсез?
2. Балалар өчен язучы тагын кайсы шагыйрьләрне беләсез?

САУМЫСЕЗ, АРЫШЛАРЫМ!

Исәнме, иркен кырларым,
Саумысез, арышларым,
Сез минем сабый чагымнан
Иң якын танышларым.
Еракларда, чит җирләрдә
Нихәтле торып та мин
Исләремнән чыгармадым,
Сагындым, онытмадым.
Агайлар килсә авылдан,
Сүзне гел сезгә бордым —
«Игеннәр ничек быел?» — дип,
Хәлегезне белеп тордым.
Сезнең өчен сусадым мин,
Яңгырлар яумаса да;
Сызландым, өзелгән башак
Тузанда аунаса да.
Сөенәм мин, бүген сезнең
Шаулап үскәнне күреп;
Башыгыздан сыйпыймчы бер,
Юлымнан читкә кереп.
Ятсынмагансыз лабаса,
Куенга уреләсез;
Сез миңа, ничә кайтсам да,
Яшәреп күренәсез.
Исәнме, иркен кырларым,
Саумысез, арышларым;
Бөтенләйгә булсын иде
Бу кайтып барышларым!

Сораулар.

1. Лирик герой күңелендә туган хисләр нинди күренеш белән бәйләнгән?
2. Ул кемнәр белән сөйләшә, алардан нәрсә турында сорый?
3. Лирик геройның күңеле ни өчен сызлана?
4. Автор белән лирик герой арасына бу шигырьдә тәңгәллек куеп буламы?

нихәтле — күпме, никадәр, ничаклы
агай — абый, олы кеше
сусадым — су эчәсем килде
аунаса да — җирдә кадерсез ятса да
ятсынмагансыз — онытмагансыз, читләшмәгәнсез
куенга — кочакка
бөтенләйгә — мәңгегә (навсегда, насовсем)
тәңгәллек куеп — тиңләп, охшатып, берләштереп

«Игенче» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Игенче кем ул?
2. Татарстанда нинди иген культуралары үстерәләр?
3. Зур уңыш җыеп алу өчен, игенчеләр нинди эшләр башкаралар?
4. *Иген батыры* дип кемнәргә әйтәләр?
5. Игенчелектә эшләүче нинди һөнәр ияләрен беләсез? Ни өчен аларның барысын да *игенчеләр* дибез?
6. Игенчеләр турында нинди шигырьләр, җырлар беләсез?
7. Игенчелек турында түбәндә бирелгән мәкаль һәм әйтемнәрне сез ничек аңлыйсыз? Игенчелеккә багышланган тагын нинди мәкальләр беләсез?

Игә белгән икмәк ашар.
Игенче — кырда, балыкчы суда булыр.

Арыш чәчсәң, көлгә чәч.
Сабан чәчсәң, суга чәч.

Җире байның иле бай.
Яз сөрсәң — көз уңарсың.
Яз уңмаган көз уңмас.
Язгы хезмәт — көзге хөрмәт.

Радик Фәизов

(1931)

ӘЖИРДӘ ТЕРЕКЛЕК БАРМЫ?

(*Хыялый (фантастик) хикәя*)

Иртәнге чәйдән соң Риф биштәрен әзерләде. Аңа зур термос белән кайнар аш, йомырка, ипи, бабасы бүләк итеп калдырган бинокльне, үзе укый башлаган «Хосусай вакыты» дигән фантастик хикәяләр китабын салды.

— Бүген үк Айга менәргә мәллә исәбең, улым? — дип елмайды әтисе.

— Мин төшкә кайтып йөрмәм, әткәй. Бозауларны урман аланына алып барам,— диде Риф.

Малай үз карамагына бирелгән утыз ике бозауны авыл астындагы болынга алып төште. Әле җәйнең башы гына, бу вакытта бозаулар көтүдән дә күңелле эш юк. Ник дигәндә, хәзергә бозауларны койрык чәнчеп чабарга, төрле якка таралырга мәҗбүр итә торган кигәвеннәр дә, чебеннәр дә күренми. Бозаулар әле үзләре дә нәниләр, йоннарының бөдрәсе дә язылып бетмәгән, гаҗәеп матур һәм сөйкемлеләр. Яңа тишелеп чыккан вак үләнне аз гына чемченгән булалар да, дәү күзләрен мөлдерәтеп, сиңа карап тик торалар. Аннары: «Әйдә, бергәләп уйныйбыз!» — дигәндәй, сикереп-сикереп китәләр.

Бозаулар бераз утлагач, Риф үзенең күптән уйлап йөргән бер тәҗрибәсен ясап карады. Биштәрен салып куйды да, дүртаякланып, алар арасына керде, сузып-сузып, нәкъ сыер мөгрәгәндәй тавыш бирде. Тиз арада малкайлары аның янына җыйналдылар. Дымлы борыннары белән аркасына, башына төртенделәр, хәтта кайберләре битен ялап алды. Әһә, барып чыкты бу! Кирәк чагында боларны ансат кына бер урынга

туплап алырга була икән. Риф торып баскан иде, тегеләр шундук читкә киттеләр. Берсе, үпкәләгәндәй, сузып кына мөгрәп куйды.

Көн искиткеч матур. Тирә-яктагы басулардан тракторлар тавышы килә. Сул якта зәңгәрләнеп урман күренә. Нинди иркен, тыныч, рәхәт монда! Риф, баш астына биштәрен салып, чирәмгә ятты. Кичә укый башлаган хикәясен дәвам итте.

...Җир шарына, галәмнең иксез-чиксез киңлекләрен үтеп, бик ерак планетадан бер космик кораб якынлашып килә иде. Гаҗәеп кораб ул, үзе бер дөнья! Аның эчендә йортлар, басулар, яшел аланнар, агачлар, хәтта челтерәп аккан чишмәләргә кадәр бар. Анда атмосфера, ясалма авырлык булдырылган, безнең кебек үк акыл ияләре яши. Алар шунда туалар, үсәләр, үзләре дә балалар үстерәләр.

Бөтен дөньясын, бозауларын да онытып җибәрде Риф. Ул инде күптән кораб эчендә, ерак планеталылар янында иде. Менә алар Кояш системасына килеп керделәр. Үзләре кебек үк акыл ияләрен эзли, элемтәгә керергә тели иде алар. Тик шунда көтелмәгән хәл булды. Җиргә нибары ике йөз мең километр ара калгач, кораб очу траекториясен үзгәртте, текә борылып, Җир тирәли әйләнә башлады. Ерак планеталылар барча күзәтү приборларын Җиргә юнәлттеләр һәм ... нинди аяныч! Кояшның өченче иярчене булган әлеге кечкенә планетада тереклек барлыгын раслый торган бер генә билге дә тапмады алар.

Рифкә күңелсез булып китте. Ерак планеталыларның Җиргә килеп җитүен түземсезләнеп көткән иде бит ул... Аларның кешеләр белән очрашуын, сөйләшүен көткән иде...

Риф каурый болытларга карап, бик озак уйланып ятты. Ерак планеталыларның Җирдә тереклек барын да белмичә, кире борылып китүләре бик кызганыч, әлбәттә. Тик Риф бик яхшы белә: язучының бу фикерендә зур хаклык бар. Әле күптән түгел генә ул бер журналдан шул турыда кызыклы мәкалә укыган иде. Галимнәр кайсыдыр ясалма иярченгә сизгер приборлар куйганнар. Бу приборлар беренче карашка бик тә сәер булган «Җирдә тереклек бармы?» дигән сорауга җавап бирергә тиешләр икән. Иярченне нибары мең километр биеклеккә җибәргәннәр, һәм шунда гаҗәп хәл килеп чыккан. Приборлар барысы да: «Җирдә бернинди тереклек юк!» — дип хәбәр иткәннәр.

Сораулар.

1. Рифне сез ниндирәк малай итеп күз алдына китерәсез?
2. Әтисе аңа ни өчен «Бүген үк Айга менәргә мәллә исәбең, улым?» дигән сорау бирә?
3. Риф бозаулар көтү турында нәрсәләр сөйләр иде икән?
4. Малайның кайсы сыйфатларын сез үзегездә булдырыр идегез?
5. *Акыл иләре, каурый болытлар* сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?

тереклек — тормыш, яшәеш (жизнь)
биштәр — аркага аса торган юл капчыгы
төшкә — төшке ашка (на обед)
урман аланы — урманда агачлар үсмәгән иркен урын (поляна)
койрык чәнчеп — койрык күтәреп
кигәвен — бөҗәк (овод)
чемченгән булалар — ашаган булалар
утлагач — ашагач
галәм — космос
текә — *монда*: кискен (круто)
аяныч — кызганыч (жалко)
сизгер — сизү көче зур булган (чувствительный)
сәер — гаҗәп (странный)

---

* * *

Риф шулай уйланып ятканда ... кинәт кенә тирә-якта ниндидер кискен үзгәреш булып алды. Әйтерсең урман өстеннән алагаем зур кош очып үтте. Һавалар тибрәнде, агачлар шаулап куйды. Шунда ук бөтен дөнья, су өсләре тагын да яктырып китте. Малай кулларына таянып күтәрелә төште һәм... өнсез калды. Елганың аръягында, ком өстендә... искитмәле дәү, ап-ак бер шар утыра иде! Кимендә зур кибән хәтле шар. Риф күзләрен чытырдатып йомды, башын чайкады, тагын күзләрен ачты. Юк, галлюцинация түгел иде бу. Ком өстендә чып-чын шар, гаҗәеп серле шар утыра иде. Риф аның як-ягына таралып киткән аяк сыман терәгечләренә кадәр күреп алды.

Малай җәһәт кенә шалаш эченә атылды. Аны шом биләп алды, йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Нәрсә бу, ниткән шар бу? Әллә галәмнән берәр космик кораб төшеп утырдымы? Алай дисәң, иллюминаторлары, ишеге күренми...

Тәмам аптыраган, гаҗиз булган малай сагаеп кына шалаш авызыннан карады. Серле шар һаман да хәрәкәтсез тора, ә бозаулар бер тамчы курыкмаганнар, кайсы-кайда күшәп ята,

тик кайберләре генә әсәренеп башын күтәргән иде. Малай үзалдына уңайсызланып куйды: бозаулар курыкмаган, ә ул... Шулай да ни эшләргә соң хәзер? Авылга кайтып, тиз генә кешеләр алып менәргәме? Ә ул арада шар кире һавага күтәрелеп, бөтенләй күздән югалса?.. Рифтән бөтен авыл халкы бот чабып көләчәк бит. Урманга һавадан бер шар төште, дип исбатлап кара син аннары. Туктале, ни булыр икән? Шар эченнән берәрсе килеп чыкмасмы? Һәм малай тын да алмый көтә башлады.

Менә шар тарафыннан тонык кына гүләү ишетелде. Аның ике ягыннан табак чаклы капкачлар ачылып китте һәм, акрын гына сузылып, манипуляторлар килеп чыкты. Алар гармун күреге төсле сырлы җиңсәләр эчендә, очларында зур гына чүмечләре дә бар иде. Манипуляторлар сузылдылар, як-якка, аска-өскә боргаланып, җирне капшадылар һәм ... чүмечләренә ком тутырып алдылар. Аннары, кыскарып, комны шар эченә алып керә башладылар. Риф хәтта куркуын да онытып җибәрде. Менә сиңа мә! Әгәр дә мәгәр бу шар кайсыдыр планетадан Җиргә килгән автомат станция булса?! Әгәр ул да Җирдә тереклек бармы-юкмы икәнен тикшерә калса?! Әгәр ул да Җирдә комнан кала берни юк дигән мәгълүмат алып, кире кайтып китсә?!

Их, ни булса, шул булыр! Риф, бар кыюлыгын, ихтыяр көчен бер төенгә төйнәп, шалаштан чыкты. Ауган каен буйлап елга аша үтте дә, сак кына атлап, шарга таба китте. Шунда гаҗәп хәл булды: әйтерсең лә шар малайның үзенә таба килгәнен тоеп, сизенеп алды. Манипуляторлар хәрәкәтсез калды, чүмечләре җиңсәгә яшеренеп, алар урынына ялпак түгәрәкләр чыкты. Бу түгәрәкләрдә кешене эләктереп алырдай берни дә юк кебек иде... Алар бик акрынлап кына Рифкә якын ук килделәр, гәүдәсенә орынмыйча гына, аның битен, иңбашларын сыйпап, капшап чыккандай иттеләр. Риф кымшанмады, түзде. Хәзер аңа кызык иде. Кем белә, бәлки, шар Рифнең тереклек иясе, акыл иясе икәнен сизеп алгандыр. Шулчак өстәрәк тагын бер люк ачылып китте. Аннан фотоаппаратныкы кебек объектив сузылып чыкты да туп-туры Рифкә текәлде.

Малай тәмам батырайды. Объектив каршысына басып, чәчләрен артка сыпырып куйды. Аннан бик нәзакәтле итеп елмайды, башын чөеп җибәрде. Ерак планета халкына сәлам тапшыргандай, уң кулын югары күтәрде. Туктале, бәлки, тавышны да язып ала торгандыр бу нәмәрсә. Тик ни әйтергә

соң? Малай бераз уйланып торды да күңеленә килгән иң гади сүзләрдән башларга булды.

— Хөрмәтле ерак планеталылар! Минем кебек малайлар! Җир кешеләреннән, Җир малайларыннан кайнар сәлам сезгә! Мин үзем — Риф Якупов, алтынчы класс укучысы. Безнең Җиребез бик матур планета! — Һәм ул горурлык белән кулларын җәеп җибәрде.— Менә ул безнең Җиребез. Әнә урман, агачлар. Анда бик күп төрле җәнлекләр, кошлар, бөҗәкләр яши. Әнә елга, суүсемнәр, балыклар, ондатралар. Әнә аланлык, бозаулар. Мин җәйге каникулда бозаулар көтәм. Безнең Җирдә тереклек бар, хөрмәтле ерак планеталылар! Искиткеч бай, бик күп төрле бездә тереклек. Сез безгә үзегез килегез. Малайлар да килсен!

Шар малайны, һичшиксез, тыңлый һәм күрә иде. Риф кулы белән кайсы якка күрсәтсә, объектив та шул якка борылды.

Менә объектив үз урынына кереп утырды. Ә манипуляторлар һаман да хәрәкәтсез, тик түгәрәкләр урынында тагын чүмечләр тора, капкачлары ачык, әйтерсең алар нидер көтә иде.

Ни эшләргә? Җирдән ерак планетага нәрсәләр җибәрергә? Монда бит югары интеллектлы акыл ияләре яшәгәнне раслый торган әйберләр кирәк. Риф тиз генә биштәрен алып килде, андагы бөтен нәрсәне ком өстенә таратып салды. Нәрсәләр генә җибәрергә икән соң? Бәлки, бинокльне, кул сәгатен җибәрергәдер? Ләкин болар белән генә гаҗәпләндереп булмас шул аларны. Ерак планеталылар өчен сәгать инде күптән үтелгән этаптыр. Әһә, тапты, ул аларга китап җибәрәчәк. Кешелек акылы тудырган иң бөек, иң кыйммәтле хәзинәне! Риф үзе укып та чыгарга өлгермәгән фантастик хикәяләр китабын кулына алып тузанын какты һәм манипулятор чүмеченә салып куйды. Мондый чакта саранланып тору килешмәс дип, Риф бабасының ядкяре булган бинокльне дә, кулындагы «Слава» сәгатен дә чүмечкә салды. Термосын да салмакчы иде дә, чүмечтә урын җитмәде.

— Мин — хәзер! — диде малай, һәм якындагы агачлар арасына йөгерде. Берничә чыршы күркәсе, былтыргы имән чикләвеге эзләп тапты, күп итеп чәчәкләр өзде. Аларның барысын да икенче буш чүмечкә китереп салды. Туктале, әгәр Акбайны да җибәрсә, ничек булыр икән? Бик кызганыч, әлбәттә, тик фән бәрабәренә, планеталар аралашу бәрабәренә монысын да эшләргә ярый...



Ә Җирдә тереклек бармы? *Д. Җәләлетдинов рәсеме*

Әмма Риф өлгерә алмый калды. Шарның манипуляторлары тавыш-тынсыз гына үз урыннарына керделәр, капкачлары ябылды. Хәзер шар шоп-шома, аның өслегендә бер генә эз дә, җөй дә юк, хәтта капкачларының урыны да күренми иде.

Шунда тагын гаҗәп хәл булды. Шарның терәк-аяклары да, җыйналып, эчкә кереп киттеләр. Һәм шар җирдән ярты метр чамасы биеклектә, һавада асылынып калды. Нинди дәү, нинди авыр шар үзе! Бернинди терәге дә юк, эчендә двигатель эшләгәне дә сизелми. Кинәт шар, акрын гына әйләнеп, Рифкә икенче ягы белән борылды. Аның бу яктагы өслегендә ниндидер сызымнар бар иде. Күр инде, Кояш системасы сызымы ич бу! Әнә үзәктә бик дәү шар — Кояш үзе, аннан бик нәни Меркурий, Венера... Әнә Җир шары, Марс, Юпитер, алкалы Сатурн, Нептун, Плутон. Ләкин нигә Юпитер кызыл төстә икән? Җитмәсә, аннан Җиргә туры сызык та үткәрелгән. Әллә бу шар Җиргә Юпитердан килгән автомат станцияме икән?

Тик менә һавада ничек асылынып тора ала икән соң ул? Әллә инде... Шунда малайның маңгае кайнарланып китте. Әллә бу шарны ясаучылар гравитация көчен җиңү әмәлен тапканнармы? Ай-яй-яй! Риф, дөньясын онытып, шарга якын ук килде, тезләнеп, аның аскы өлешен күздән кичерде. Тик бернинди экран да, бернинди җайланма да күренми, шарның асты шоп-шома иде. Димәк, авырлык көчен җиңү җайланмасын ясаган болар, һичшиксез, ясаган. Юкса, йөзләрчә тонналы аппарат бернинди терәксез һавада асылынып тора алмас иде.

Шулвакыт шар эченнән тонык кына гүләү ишетелде, ком өстенә һава агымы бәрелде. Шар салмак кына күтәрелде, төсе тоныкланганнан-тоныклана барды һәм күздән дә югалды.

Күктә — Кояш, урман тып-тын, бозаулар күшәп ята, күбәләкләр оча, салмак кына елга ага... Һәм аларның уртасында, әле генә күргәннәреннән тәмам тетрәнеп, тирән уйга чумып, Җир кешесе — Риф Якупов басып тора иде.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Малайның кызыксынучанлык һәм курку хисләре сурәтләнгән урынны табып укыгыз. Аның кайсы хисе җиңеп чыга, бу Рифнең нинди сыйфатын күрсәтә?

2. Малайның китаптан укып белгәннәре белән хикәянең икенче бүлегендә сурәтләнгән вакыйга арасында бәйләнеш бармы?

3. Риф — Җир планетасының патриоты. Хикәядә сурәтләнгәннәрдән чыгып моны дәлилләгез.

4. Риф хәтта үзенең яраткан этен дә чит планетадан килүчеләргә биреп җибәрер иде. Сезгә аның бу сыйфаты ошадымы?
5. Сез «оча торган тәлинкәләр»гә (НЛО) ышанасызмы? Алар турында нәрсәләр беләсез?
6. Риф урынында сез үзегез булсагыз, шушыңа охшаш хәлләрдә нәрсә эшләр идегез?
7. Автор ни өчен әсәрне «хыялый хикәя» дип атаган?

кискен — көтмәгәндә (неожиданно)
алагаем — артык, чамадан тыш
өнсез калды — куркып калды (сильно испугался, остолбенел)
искитмәле — исең китәрлек, гаҗәп
кибән — печәннән, саламнан салынган чүмәлә (стог)
җәһәт кенә — тиз генә
шом биләп алды — курку биләп алды, курыкты
гаҗиз булган малай — тәмам аптыраган, ни эшләргә дә белмәгән малай
бер тамчы — *монда*: бер генә
күшәп ята — чәйнәп ята
әсәренеп — куркышып, гаҗәпләнеп
бот чабып көлү — үртәп, мыскыл итеп көлү
исбатлап — дәлилләп
җиңсә — *монда*: бөҗралар
ялпак — җәенкеләнеп киткән (плоский, сплюснутый, приплюснутый)
ядкяре — истәлеге
фән бәрабәренә — фән хакына (во имя науки)
өслегендә — өстендә (на поверхности)
гравитация көче — тартылу көче
терәксез — таянып, тотынып тору әйбереннән башка (без опоры)

ГАЛӘМ СЕРЛӘРЕ

(*«Ә Җирдә тереклек бармы?» хикәясе турында*)

Хикәя бик гади генә башлана. Анда сурәтләнгән малай да авылдагы башка яшьтәшләреннән берни белән дә аерылып тормый. Аларның күпчелеге кебек, ул да табигатьне, хайваннарны ярата. Яшүсмерләргә хас булганча, хыялланырга һәвәс. Шуңа күрә хыялый әсәрләр уку белән мавыга. Бозаулар көтәргә барганда, үзе белән бинокль алуы да тикмәгә генә түгел. Ул күк җисемнәре, галәм белән кызыксына. Җиргә иң якын булган күк җисеме — Ай белән кызыксынуы аеруча көчле булса кирәк. Әтисенең «Бүген үк Айга менәргә мәллә исәбең, улым?» дип соравы юкка гына түгелдер. Бала вакытта Айга

менеп, аның кырыена аякны салындырып утырырга кем генә хыялланмаган?

Шул ук вакытта Риф бозаулар белән дә кызыклы тәҗрибәләр ясап карый. Күргәнебезчә, хикәянең беренче кисәгендә «фантастик» дип әйтерлек берни дә юк. Дөрес, Риф хыялый эчтәлектәге китап укый. Анда бәян ителгәннәр белән шулкадәр мавыгып китә, елганың аръягына төшеп утырган ниндидер шар сыман серле нәрсә аңа укый торган әсәрендәге вакыйгаларның дәвамы кебек тә тоелгандыр.

Малай башта, табигый, шүрләп кала. Әлбәттә, аны аңларга мөмкин. Ул якын-тирәдә берүзе. Бозаулар аңа ярдәм итә алмый. Әмма кызыксынучанлыгы аның курку хисләрен җиңә. Әлеге шарны җентекләп күзәтә торгач, аның начарлык кылмаячагына ышана. Балаларча беркатлылык белән якын ук килә.

Шунысы әһәмиятле: башка планетадан килгән (малай шулай дип нык ышана) бу шар белән очрашкач, ул үзен Җир планетасының вәкиле буларак хис итә. Рифнең ничек кенә булса да теге шар эчендәге акыл ияләрендә (ихтимал, алар, үзләре туган планеталарында калып, шушы аппаратны гына җибәргәннәрдер дип тә уйлый ул) Җир турында яхшырак тәэсир тудырасы килә. Алар биредә ком гына икән дигән ялгыш фикердә калмасыннар, югары дәрәҗәдәге акылга ия кешеләр яшәвен, төрле-төрле хайваннар, үсемлекләр булуын да белсеннәр дип тели ул. Моның сәбәбе бик гади — безнең планетабыз бөтен галәмендә тереклек булган бердәнбер җисем түгелдер ич. Табышырга иде бит галәм түрендәге җан ияләре белән. Хыялый китаплар укуы да аның бу теләген көчәйтә генә тора. Җитмәсә, аның кайдадыр укыганы бар: имеш, инде мең чакрым биеклектән дә Җирдә тереклек барын белү мөмкин түгел икән. Җае туры килгән икән, кунакларга күбрәк мәгълүмат биреп җибәрергә кирәк. Малай шулай уйлый. Бу аның әнә шулай юмартлануына китерә. Дөресрәге, ул үзен биредә Җирнең хуҗасы буларак сизә. Әлеге хис аны, чыннан да, көчле, кыю, акыллы һәм ярдәмчел итә.

Бирем.

1. Галәм турында хыялларыгызны сурәтләп, кечкенә генә хикәя язып карагыз. Аларны сыйныфта укыгыз. Уңышлы дип табылганнарын мәктәп газетасына урнаштырыгыз, балалар вакытлы матбугатына, радионың балалар өчен тапшыруларына җибәрегез.

Нур Әхмәдиев

(1946)

МИНЕМ ТУГАН КӨНЕМ

Бүген кызыбызга дүрт яшь тула. Әнисе белән без иртәдән бирле кухняда кайнашабыз. Ул пешерә, ә мин өстәлгә тезә торам. Кичкә таба кунаклар — кызымның иптәшләре киләчәк.

Башка елларны: «Кечкенә әле, үсә төшкәч үткәрербез туган көнен»,— дип йөргән идек. Беркөн үзен Гөлнараларга чакырдылар. Аннан чыккач:

— Без Гөлнараларга кердек. Аның туган көне булды. Әти-и,— диде ул, бераз суза төшеп,— минекен кайчан үткәрербез? Үткәрик әле, әти, ә!

Аның бу соравы минем күңелдә моңа кадәр онытылып торган хатирәләремне уятты.

Туган көн. Безнең балачак туры килгән сугыштан соңгы еллардагы туган көн. Ул чакта кайчан туганыңны белергә дә әтиләрнең вакыты юк иде. Шулай да дүртенче класста укып йөргәндә, каян исемә килгәндер:

— Туган көнне үткәрик әле? — дип, әти белән әнинең теңкәсенә тиеп, туйдырып бетердем.

— Анысы ниткән сүз тагын? Авылда, илдә булмаганны! Нинди туган көн ул, кемдә күргәнең бар? — дип, баштарак әти кулын гына селтәде. Мин дә уйлана калдым: чыннан да, ничек үткәрәләр соң аны? Ант итеп әйтәм, иптәш малайларның берсе дә бу сорауга җавап бирә алмас иде. Чөнки безнең авылда андый гадәт юк. Авылда булмаса да илдә бар икән шул. Әти белән әни белмәгәч тә. Әти, баштарак белмим дип кул селтәсә дә, бик йөдәтә торгач, беркөнне:

— Кая, әнкәсе, бир әле малайның метрикәсен, кайчан туган икән,— дип, әнидән сандыгын ачтырып, таныклыкны алды. Без алты бала үсә идек. Әти һәрчак безгә:

— Абыең кышын, апаң көлтә бәйләгәндә, кече абыең ташу вакытында туды,— дип әйткәли иде.

Бу юлы ул сыңар колакчыны сынган күзлеген борын очында тотып миңа карады да гаҗәпсенеп куйды:

— Бәй, син печән өстендә тумадыңмыни? Монда декабрь язылган.

— Сөйләмә инде тузга язмаганны! Анысы Мансур бит. Әдип туган көнне утыз градуслы чатнама суык иде,— диде әни.

— Шулай икән шул,— ул әнигә карап хәйләкәр елмайды.— Әллә, анасы, «бишле»ләр дә алгалый, туган көнен үткәрәбезме соң шул малай актыгының?

Мин, чыннан да, төпчек бала. Ләкин әти төпчек булган өчен генә әйтми малай актыгы дип. Кәефе яхшы вакытта абыйларга да шулай эндәшкәли.

Әни дә каршы килмәде.

— Ярар, үткәрербез, алай булгач.

Шуның белән эш хәл ителгәнгә санап, таныклыкларны сандыкка кире бикләп куйдылар.

Менә ул минем туган көн! Уянгач, башка көндәге кебек урында киерелеп ятмадым, абыйлардан алда сикереп торып киендем дә әти белән әни чәй эчеп утырган өстәл янына бардым. Туган көн булгач, өстәлгә тәмлерәк нәрсәләр дә куелгандыр дигән өмет бар иде. Кая ул! Гадәттәгечә җиз самавыр чыжылдап утыра, табында әтиләр карабодай ипие белән чәй эчәләр. Хәтта кайбер көннәрдә өстәлдә күренгәләп ала торган шикәр дә юк. Ул карабодай ипиеннән болай да туйган инде. Кыш буе ашадык, төче, үзе баллы. Беренче ашап карауга тәмле тоелса да, тиз биздерә. Тансыкка дип, мәктәптә малайлар аны тәм-томга, бодай күмәченә алышкалыйлар. Тәмле дип ашыйлар. Ә мин, алышсыннар гына, арыш ипиенә дә риза.

Өметем алданса да, сиздермәдем. Югыйсә, бик шыңшый башласаң, әтинең сугыштан алып кайткан каешы ничек чыжылдап сыртыңа төшкәнен сизми дә калырсың.

Бер кыерчык ипи белән ике чынаяк чәйне сүзсез генә капладым да, кайнар самавырга ышкып, галстукны шомартып

алдым. Кат-кат ямалса да, әле чиста булган чалбарымны әнинең сырлы бәләге белән «үтүкләп» кидем.

Киенеп ишек янына баскач:

— Әни, үземнең туган көнгә иптәшләрне дә чакырам! — дип кычкырдым да мәктәпкә йөгердем. Абыйларның мыштырдаганын көтеп торырлык түземем калмаган иде.

Мәктәпкә ашыгып барып кергәнгәме, минем шомарган галстукка да, «үтүкләнгән» чалбарга да игътибар итүче табылмады. Алар өчен бүгенге көннең кичәгесеннән һич аермасы юк иде. Күңел өчен генә булса да шунда хет берсе, нигә бик фыртландың, дип сорасын. Үзләренең югыйсә чалбарларын әйткән дә юк, галстукларына кадәр бозау муенчагы кебек бөтәрләнеп беткән. Ярар, сорамасалар сорамасыннар. Тик туган көнгә ничек чакырырга? Кызларга әйтергәме, юкмы? Әйтсәм, миннән көлеп, малайлар күземне ачырмаслар. Бигрәк тә Мәхмүттән көн булмас. Әле болай да:

— Ай-ли, Диләрә Әдипкә хат җибәрә! — дип, җай чыккан саен такмакламый калмый. Хикмәт шунда: өченче класста укыганда, Диләрә кәгазь кисәгенә нидер язып торганда, Мәхмүт аны тартып алды. Без Диләрәнең чәбәләнүеннән барыбыз да кызык табып көлгән идек. Их, ни язылганын белсәм, аны Мәхмүткә укытып, читтән көлеп тормас, сугышып булса да, хатны үземә алыр идем. Анда «Әдип, синең күзләрең үзе яшькелт, үзе матур. Ә колагыңның берсе тырпаеп тора. Бүген дәрестән бергә кайтабызмы?» дигән сүзләр булган икән. Мәхмүт шуны уку белән:

— Малайлар, Әдип белән Диләрә сөешәләр икән, менә хатлары! Ы-гы-гы,— дип, бөтен класска яңгыратты. Хәзер дә кулына күмер эләгәме, акбурмы, җай чыккан саен коймаларга, стеналарга «Әдип плюс Диләрә» дип күбрәк Мәхмүт яза.

Уйладым, уйладым да шул пумала баш чырылдык кызларга әйтмәскә булдым.

Соңгы дәрес бетүен белдереп, кыңгырау шалтырады. Класс җитәкчесенең чыгып китүен генә көттем дә, башкалар урыныннан кузгалганчы сикереп торып:

— Малайлар, бүген минем туган көнем, кунакка килегез! — дип кычкырдым. Үзем тизрәк чыгып йөгердем.

Мәктәп капкасын чыккач кына, Мәхмүт белән тагын берничә малай мине куып җиттеләр.

— Әдип, малай, синең туган көнгә хәзер үк барырга булдык. Өйдәгеләр барыбер кайтмаган. Ашарга да әллә бар, әллә юк.

— Киттек, малайлар, киттек, әйдәгез хәзер үк киттек!

Өйгә кайткач кичерәсе күңелле минутлар күз алдыма килеп, җаным рәхәттә йөзә. Әни тәмле нәрсәләр пешергәндер, алар кайнар, авызга кабуга телеңне йотарлыктыр. Шуларны уйлагач, авыздан сулар килеп китте. Бу рәхәтне мөмкин кадәр якынайтырга теләгәндәй, җитәкләшеп өйгә таба йөгердек.

Сораулар.

1. Язучы хикәяли торган вакыт кайсы елларга туры килә?
2. Ни өчен малайның әти-әнисе туган көнемне үткәрик әле дигән үтенечкә гаҗәпләнеп калалар?
3. Туган көнендә Әдип нинди хисләр кичерә?
4. Мәхмүтнең үз-үзен тотышы турында сездә нинди фикер туды?
5. Ничек уйлыйсыз, туган көнгә чакырганда, Әдип һәм аның әти-әниләре нинди ялгыш җибәрәләр?

хатирәләремне — истәлекләремне
ниткән сүз — нинди сүз
йөдәтә торгач — аптырата торгач
метрикәсен — туу турында таныклыгын (свидетельство о рождении)
көлтә бәйләгәндә — урак өстендә, урак вакытында
ташу вакытында — кар сулары акканда, яз көне
җиз самавыр — медный самовар
карабодай — ашлык төре (гречиха)
төче — чүпрә салмыйча әзерләнгән (пресный)
биздерә — туйдыра
тансыкка дип — *монда*: аш төрләндерү өчен
мыштырдаганын — әкрен кыймылдаганын
күземне ачырмаслар — *монда*: миннән көләрләр
сөешәләр — бер-берсен ошаталар, якын күрәләр

---

* * *

Кайтсак, син күр дә мин күр, ишектә — йозак! Ачып кердек. Әни әле эштән кайтмаган, иртән ягылган булса да, өй суынырга өлгергән иде. Безне күргәч, почмакта күшәп яткан бозау, шатлыгыннан мөгрәп, аягына басты һәм Мәхмүтнең сумкасына таба телен сузды. Идәндә йөгереп йөргән сарык бәрәннәре атылып сәкегә менеп киттеләр. Морҗаның кайсыдыр тишегеннән кычкырган чикерткә дә бермәлгә тынып калды. Идәндә сарык бәрәннәре туздырып ташлаган печән калдыклары иде.

«Туган көн, туган көн!» дип йокыдан торганда ук бик күпкә өметләнеп, тантана итеп йөргән булсам да, малайлар белән таракан катып үләрлек буш өйгә кайтып кергәч, нишләргә белмичә, аптырап калдым. Ярый әле Мәхмүт бар. Башымны кашып торганны күргәч, ярдәмгә килде.

— Син, Әдип, юкка кайгырма, малай. Туган көн — бәйрәм көн. Ә бәйрәм көнне, үзең беләсең, тәмлерәк ашыйлар.

— Әни берни дә пешермәгән, ахрысы, әле.

— Пешермәсә, пешерер, без көтәрбез әле. Ул кайтканчы капкалый торырга нәрсә булса да ярар...

Мәхмүтнең тел төбен аңларлык. Гомеремдә дә сандыкны ачып караганым юк иде. Ләкин әни аны ачканда ниләр барын күргәнем бар. Сандыкка үз белдегең белән кергән өчен әнинең баштан сыйпамасын яхшы беләм, ләкин малайлар алдында сер бирергә ярамый. Хуҗа кеше лә мин! Өстәвенә бүген туган көнем. Өченчедән, кунакларым бар.

Шкафтан ачкычны алып сандыкны ачтым, әнинең елына ике-өч кенә күрсәтә торган кәнфит, прәник ише тәмлерәк нәрсәләрен өстәлгә утырттым. Сәке астында кичә аерган каймак бар иде, аны да алып куйдым. Каймак булгач, кашык та кирәктер дип кузгалган идем, Мәхмүт:

— Мәшәкатьләнмә, Әдип, болай да ярар,— дип, прәниген каймакка батырды. Аның бу кыю адымы башкаларга да ошады.

Сыйны яраттылар малайлар. Берсеннән-берсе уздырып, мактый-мактый ашадылар. Иртәдән бирле канатланган күңелем эреде. Тагын боларны ничек сыйлыйм икән дип уйлый торганда, искә төште: әни, карчыкларны җыйгач, аларга акча да өләшә иде. Андый вак-төяк акчаларның сандыкта кайда сакланганын белә идем, шуннан алып малайларның һәрберсенә унбишәр тиен акча бирдем. Мәхмүт, акчаны әйләндереп-әйләндереп карагач, кесәсенә салды да:

— Яшә, Әдип, чын егет икәнсең! — дип мактады. — Синең туган көнең быел тагын булмыймы? Булса, безне калдырма, яме, малай. Әбәзәтелне килербез. Ие бит, Рәхми?

— Шту син, килмичә! — диде Рәхмәтулла, ике кәнфитне берьюлы кабып.

— Киләбез, киләбез! Әдипнекенә дә килмәгәч...

Төргәктән алып, алар алдына соңгы кәнфит-прәникләрне салдым. Ашау белән шулкадәр мавыгылган, әнинең кайтканын да сизмәгәнбез.

— И-и, кунаклар да бар икән,— дигән тавышка борылып карасак,— әни. Мин ни әйтергә дә белмичә урынымда калдым, малайлар, дәррәү кузгалып, киемнәренә тотындылар. Рәхмәтулла, киенеп тә тормыйча, пальтосын култык астына гына кыстырып чыгып сызды.

Әни ачуланыр дип курыккан идем, ачуланмады.

— Кая барасыз? Бүген улымның туган көне, хәзер коймак пешерәм. Бар, Рәхмәтулланы да чакыр,— дигәч, эреп киттем.

Дөньяда минем әнидән дә яхшырак берәү дә юктыр ул. Әни бит орышмады, шуның өстенә хәзер коймак белән дә сыйлыйм, ди. Елына Сабантуй белән Октябрь бәйрәменнән башка вакытта коймак авыз итеп карау бәхетенә ирешмәгән безнең кебек авыл малае мондый сыйдан баш тартамы соң?

Рәхмәтулла да кергәч, малайлар, киемнәрен чөйгә кабат элеп, өстәл янына килеп утырдылар. Әни мичкә ягып җибәрде, бер савытка йомырка сытып, сөт салып коймак туглый башлады.

Самавыр куярга су беткән икән, Мәхмүт белән икәү чыгып коедан су алып кердек.

— И, малай, кабыргаңны саный инде дигән идем әниеңне,— дип пышылдады Мәхмүт, суга чыгышлый.

Әни тиз генә самавырга су салды да мичтәге утлы күмер белән кайнатырга утыртты. Ул арада мич өлгерде. Әни, табаларны чыжылдатып, коймакларны салып тора, пешкәннәрен мичтән алып тора. Мин бер савыт коймакны майлап өстәлгә китердем.

— Кунакларың белән үзең дә аша инде,— дип, әни кайнаган самавырны өстәлгә куйды.

Коймак белән берәр чынаяк чәй эчкән идек, абыйларга ияреп тагын Сәгыйть, Дамир һәм Зөбәер килеп керделәр.

Тора-бара безнең эшләр хутка китте. Иптәш малайлар киләләр, ашап-эчеп китә торалар. Соңарып кына Салих белән Гата килделәр. Алар бездән бер класс түбән укыйлар.

— Әдип, синең туган көнең икәнен без ишетмәгән идек, гаепләмә инде, яме, Мәхмүт кенә әйтте трай тибеп уйнаганда,— диде Гата. Ә үзенең күзе миндә түгел, өстәлдәге коймакта.

— Ачуланма инде, яме.

— Ачуланмый, ачуланмый. Әйдәгез, өстәл янына утырыгыз! — Әни аларны түргә чакырды.

Чәй эчертеп Салих белән Гатаны да озаттык.

Караңгы төште. Классташ малайларның икешәрләп-өчәрләп һәммәсе дә килеп киттеләр. Әти кайтты, ул да ашап-эчте.

Туган көнем бүләге. *Д. Җәләлетдинов рәсеме*

Абыйлар буага кәшәкә сугарга чыгып тайдылар. Ихтимал, башка керүче булмас дип, табынны җыештырып куйдык. Мин дәрес әзерләргә утырдым.

Шулвакыт әкрен генә шыгырдап капка ачылганы ишетелде. Кемдер сак адымнар белән ишегалдына үтте. Менә керерләр, менә керерләр дип көтсәк тә, ишекне ачучы булмады.

— Ишек тоткасын табалмыйлардыр... Малларны да карап керермен.— Әти җилкәсенә тунын салып чыгып китте. Бераздан аның:

— Нигә кермисең, кызым, кер. Әдип тә өйдә,— дигән тавышы ишетелде. Шулай сөйләнә-сөйләнә ул ишектән, беләсезме кемне, Диләрәне кертте. Әйе, әйе, өченче класста миңа хат язып, икебезне дә оятка калдырган Диләрәне.

Әти үзе кереп тормады, ә Диләрә ишек төбендә басып калды. Башын аска игән, кулын артка яшергән. Мин дә ни әйтергә белми торам. Әле ярый эчке яктан әни чыкты.

— Бәлеш, Әдип, нигә кунагыңны утыртмыйсың? Уз, Диләрә, уз. Мин хәзер чәй хәзерлим.— Әни эчке якка кире кереп китте.

Ул кереп китүгә:

— Әдип, туган көнең котлы булсын! — дип, Диләрә миңа дәфтәр битенә төрелгән нидер сузды. Мин аны алуга, үзе ишектән чыгып та сызды. Сүз әйтергә дә өлгерми калдым.

Ишек тавышына әни чыкты.

— Кая китте кунагың?

Әни күрмәсен дип, Диләрәнең бүләген кесәгә яшердем. Үзем, җинаять эшләп тотылган кебек, кая барырга белмим. Әни янымнан киткәч кенә, җиңел сулу алдым

Диләрәнең төргәген бик карыйсым килсә дә, әти белән әни йокларга ятмыйча кыюлыгым җитмәде. Алдым. Минем кулда зәңгәр белән читләнгән ак кулъяулык иде. Аның өч почмагында кып-кызыл роза чәчәкләре. Ә берсенең тажы уртасында «Д» хәрефе чигелгән. Кинәт миңа әйтеп бетергесез рәхәт булып китте. Тәнем кызыша сыман. Йокларга яттым. Күзгә йокы керәме соң! Әледән-әле кулъяулыкны сыйпап куям. Ахырда, түзмичә торып, тәрәзәдән карап торган айның саран яктысында тагын бүләккә текәлдем. Үзем куркам. Әгәр Мәхмүт, башка малайлар белсә? «Кияү» дип күзне ачырмаслар бит.

Йокыга китәргә тырышып күземне чытырдатып йомам. Миңа барыбер Диләрә күренә. Юрганны баштан ук бөркәнеп ятам. Күз алдымда һаман шул ук Диләрә тора сыман. Кара әле, аның килүе, туган көнемә бүләк күңелне урыныннан

кузгатты ич. Уйлап карасаң, класстагы, юк, класстагы гына түгел, авылдагы кызлар арасында да иң сөйкемлесе ул икән бит. Ничек мин моңарчы сизми йөргәнмен? Кызларның бүләге шундый була микәнни?

Шуларны уйлый-уйлый йокыга киткәнмен...

Туган көнемне беренче искә алу әнә шулай үткән иде. Бераз үсә төшкәч, бигрәк тә студент чакта һәм эшли башлагач, туган көннәрне ел саен диярлек билгеләп үтә башладык. Ләкин аларның берсе дә иң беренчесенә охшамады. Бүген кызымның соравы әнә шул көнне күз алдына китереп бастырды. Бала. Заман. Язмыш. Мөмкинлекләр...

Мин иң кадерле истәлекләребез сакланган чемоданны ачтым. Һәм дәфтәр битенә төрелгән кулъяулыкны алып карадым. Зәңгәр читле ак кулъяулык. Өч читендә янып торган роза чәчәкләре. Берсенең уртасына «Д» хәрефе чигелгән. Хәзер аның тәҗрибәсез бала кулы белән эшләнгәне күзгә ташланып тора. Ләкин хикмәт ничек чигелүендәмени? Минем иң беренче тапкыр уздырган туган көнемнең бердәнбер бүләге бит ул. Ул бүләк, бәлки, аннан да зуррак сергә ия дер әле. Минем туган көнем бүләге.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Малайлар белән кайткач, эти-әнисе өйдә юклыкны күреп, Әдип нәрсә эшләргә тиеш иде?
2. Мәхмүт тә, Рәхмәтулла да Әдипнең ярамаган эш кылганын аңлап торалар. Ни өчен аны болай эшләүдән туктатып калмыйлар икән? Әсәрдә сурәтләнгәннәр, олылардан ишеткәннәрегез буенча, сугыштан соңгы елларда балалар тормышы турында сөйләгез.
3. Әдипнең әнисе ни өчен улын орышмый?
4. Әдипнең туган көнендә үзен иң дөрес итеп тотучы кем дип уйлыйсыз?
5. Диләрә ни өчен кулъяулык бүләк итә? Татар халкы йолалары буенча кулъяулыкка кагылышлы гореф-гадәтләр турында сөйләгез.

моржа — печь
чикерткә — сверчок
тантана итеп — шатланып, горурланып
таракан катып үләрлек — *монда*: салкын
каймак — сөт өсте (сметана)
яме, малай — *монда*: яме, дус
дәррәү кузгалып — кинәт берьюлы кузгалып

чыгып сызды — чыгып качты
кабырганы саный инде — *монда*: кыйный инде
мич өлгерде — мич коймак пешерерлек булып кызып җитте
кәшәкә сугарга — (кәшәкә — клюшка) хоккей уйнарга
ихтимал — мөгаен, бәлкем (возможно, вероятно)
табынны — өстәлне
ишек тоткасы — ишекне ачу, ябу өчен махсус сап (ручка)
таҗы уртасында — чәчәк уртасында

БАЛАЧАГЫМ ХАТИРӘСЕ

(*«Минем туган көнем» хикәясе турында*)

Әсәрдә вакыйгалар хикәяләүченең искә төшерүе рәвешендә сөйләнелә. Кызының туган көнендә эти кеше үзенең сугыштан соңгы авыр елларда уздырылган туган көнен бөтен ваклыкларына кадәр хәтереннән үткәрә.

Әлеге хикәядә 1941—1945 еллардагы сугыштан соңгы вакыт сурәтләнә. Күрәбез, ул елларда тормыш әле шактый авыр. Малайларның бик сирәгенең генә этиләре сугыштан исән кайткан. Әдип — шундый бәхетлеләрнең берсе. Мәхмүт, Рәхмәтулла кебек малайларның өйләрендә «ашарга әллә бар, әллә юк». Әдипләрнең исә сыерлары бар, сөт-каймаксыз тормыйлар. Әнә өйдә бозаулары, сарык бәрәннәре дә күренә. Дөрес, конфет-шикәр кебек нәрсәләр бу гаиләдә дә сирәк була. Ләкин ел буена икмәктән өзелмиләр.

Әдипнең әти-әнисе, туган көнемне үткәрик әле дигән гозерне ишеткәч, аптырап калалар. Ник дигәндә, татар халкында туган көнне уздыру гадәте булмаган. Кешенең яше генә түгел, бәлки кылган яхшы гамәлләре, игелеклелеге, булдыклылыгы аның чын йөзен күрсәтә дип уйлаганнар, аны олылауның башка төрле җайларын тапканнар.

Моңа кадәр олыларның да, балаларның да туган көннәрен уздырмагач, гаиләдә беркем дә мондый бәйрәмне оештыруның тәртибен белми. Кемнәрне чакырырга, табынга нәрсәләр әзерләргә, кунакларны көннең кайсы вакытында җыярга? Бу сораулар ачыкланмый кала. Әдип малайларны (бары тик малайларны!) инде иң соңгы мизгелдә — мәктәптән өйгә кайтып киткәндә генә чакыра. Ихтимал, болай дәшкәнгә, туклык еллары булса, игътибар да итмәсләр иде. Тамакны бер генә тапкыр булса да туйдыру бик мөһим булган сугыш

арты елларында малайлар мондый өндәүне ишетми кала алалармы соң?! Алар Әдипкә ияреп үк китеп баралар.

Бүген улыбызның туган көне дип ата-ана эштән кала алмый. Мондый сәбәп ул еллардагы авылда бөтенләй көлке булып тоелыр иде. Шуңа күрә Әдипләрне йозаклы өй каршылый. Әлбәттә, малайларга, хәзергә өйләренә таралып торып, кичкә таба кабат килү яхшырак булыр иде. Әмма, нихәл итмәк кирәк, эчтә бүреләр улый. Ашыйсы килү акылдан көчлерәк булып чыга. Әдип тә аларның өметен артыгы белән аклый. Иң яшерен урынга куелган, бик кирәкле вакытта гына кузгатыла торган ризыкларны өстәлгә чыгара.

Хикәядә ана образының сурәтләнүе бик әһәмиятле. Никадәр сабыр, балаларын өзелеп яратучы, аларны аңлый белүче ул. Ана балаларның алдан килеп утыруларына, улының ризыкларны рөхсәтсез алуына да ачуланмый, чөнки бүген гадәти генә көн түгел, ә улының туган көне, гомерендә беренче үткәрелгән туган көне бит. Ана иптәшләре алдында малаеның абруен төшерергә дә теләми.

Әсәрдә сурәтләнгән тагын бер образга игътибар ителмәсә, хикәя турында сөйләшү һич тә тулы булмас иде. Сүз Әдип белән бер сыйныфта укучы Диләрә исемле кыз турында бара. Бу кыз, әле өченче сыйныфта укыганда ук, башка укучы малайлар арасыннан аерып, Әдипне үз күреп йөри. Үзенең җылы мөнәсәбәтен белдерү өчен, малайга кечкенә генә хат кисәге дә язган була ул.

Әдип кызларны туган көненә чакырмый. Бу хәл, әлбәттә, Диләрәне күңелсезләндергәндер. Шулай да ул үзе чиккән кульяулыкны бүләк итәргә уйлаган. Чөнки матур бизәкләр белән чигелгән кульяулык бүләк итү татар халкында якын күрү, хөрмәт итү билгесе булган. Бу кульяулык — Әдип өчен бүгенге көндә дә иң кадерле истәлек.

гозер — үтенеч, теләк
олылауның — зурлауның, ихтирам итүнең
мизгел — вакытның бик кечкенә бәрәмлеге
эчтә бүреләр улый — ашыйсы килә

Илгизәр Солтан
(1961—2004)

ТУГАН ЯКТА КУНАКТА

Кыш килде дә бөтен җирне
Буяп куйды ап-акка.
Салкын җилләр очып килде
Туган якка кунакка.

Елгада боз ага бүген,
Су тавышы колакта.
Яз-егет әйләнеп кайткан
Туган якка кунакка.

Өлгереп килә җир җиләк,
Чия пешә куакта.
Җәй шатланып йөри бүген
Туган якта кунакта.

Иген кыры кулын болгый,
Эти чыкты уракка.
Тиз аңладым, көз килгән бит
Туган якка кунакка.

Рәшитләр шәһәргә күчте,
Ишекләре йозакта.
Рәшит җәен кайтып төште
Туган якка кунакка.

Бабай миңа сөйли: «Улым,
Рәхәт бит туган якта.
Китмә, гомер буе яшә
Туган якта кунакта».

Сорау һәм биремнәр.

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Автор нинди сынландырулар кулланган?
2. «Минем туган ягым» темасына кечкенә күләмле сочинение языгыз.

өлгереп килә — җитлегеп килә (созревает)
җир җиләк — җиләк атамасы (земляника)
куак — тәбәнәк агач (куст)
уракка чыкты — иген җыю эшенә чыкты (приступил к жатве)
йозак — бик, бикләвеч (замок)

ИЛНАР ТЕЛӘГЕ

1

Күтеп алам радиодан
Мин Казан сөйләгәнне.
...Радио тыңлап өйрәнәм
Үземнең туган телне.

Әлегә авыр сөйләшәм,
Сүзләрне бутыймын мин.
Бутамас өчен, аларны
Тырышып ятлыймын мин.

Кечкенә чагымда әни
Татарча сөйләшмәгән.
Ул минем бары урысча
Белүемне теләгән.

Әти дә миңа җырларны
Урысчалап көйләгән,
Миңа бөтен әкиятне
Гел урысча сөйләгән.

Мин боларның белдем барысын
Бары соңыннан гына,
Әтием кайтарып куйгач
Дәү әнием янына.

2

Авылга кунакка кайттым,
Зур шатлык көткән мине.
Дәү әнием авызыннан
Ишеттем туган телне.

Гаҗәпләндем ... дәү әнием
Мине аркамнан сөйде,
Яшьле күзләрен сөртте дә:
«Балам, өйрәтәм»,— диде.

Дәү әнием туган телгә
Өйрәтте мине көн дә,
Кызык әкиятләр сөйләде
Сөйкемле туган телдә.

Дәү әни белән урамда,
Кырда, болында йөрдем,
Нарат, каен урманнарын,
Салкын чишмәне күрдем.

Сандугач җырын тыңладык,
Бергәләп җыйдык җиләк.
Шәһәргә дип, вареньены
Кайнаттык ике чиләк.

3

Мин, әбидә бер ай яшәп,
Матур туган телемне
Өйрәнеп кенә җиткәндә,
Кайтып төште әнием.

Әби белән исәнләште:
«Саумы, мама, мамаша,
Сине җәфаламадымы,
Минем иркә Илюша?

«Моя мама кайда?» — диеп,
Көн дә еламадымы?
Кошканың койрыгын борып,
Сөйрәп уйнамадымы?

Ул бит минем бик «озорник»,
Ладно, ярый, мамаша.
Менә сиңа конфет, масло,
Көн дә туйганчы аша.

Киләсе елга да Илюш
Җәен авылга кайтыр.
Ә хәзергә, ладно, мама,
Син инде сау булып тор».

4

Алып китте мине әни.
Киткәндә дәү әнием
Әйтте: «Онытма телеңне,
Әй, наныем, нәнием».

«Шәһәрдә минем белән кем
Сөйләшер икән, әби?»
Әби әйтте: «Радионы
Тыңла син һәрчак, нәни».

Әбием сүзен онытмыйм,
Һәм хәзер көн дә менә
Радио аша кайтам мин
Якын туган телемә.

Радиода эшләүчеләр —
Дәү абыйлар, апалар,
Татарча күбрәк сөйләгез,
Сезне көтәм мин — Илнар.

Көтеп алам сезне көн дә,
Сөйләгез инде күбрәк.
Үз газиз туган телемә
Кайтасым килә тизрәк.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьне рольләргә бүлеп, сәнгатьле укырга өйрәнегез.
2. Илнарны русчага гына өйрәтеп, әнисе дөрес эшләде микән?
3. Әбисе оныгына нинди киңәшләр бирә? Илнар аны ничек үти?

4. Энисенең сөйләмен укыгыз. Сезнең әти-әниләрегез дә шулай сөйләшмиме? Сөйләшсәләр, әти-әниләрегезгә нинди киңәш бирер идегез?
5. Русча бирелгән сүзләрне татарчага тәрҗемә итегез.

өйрәнәм — *монда*: телне үзләштерәм (изучаю)
гаҗәпләндем — исем китте (удивился)
җәфаламадымы — интектермәдеме (не мучил ли)
газиз — *монда*: кадерле, изге (дорогой, родной)

ТУГАН ТЕЛЕМ

Оран салмыйм, кычкырмыйм мин,
Масаймыйм синең белән.
...Киләчәккә барасың син,
Туган тел, минем белән.

Синең белән булганга, мин
Шатланып җырлыйм менә.
Җырлаган саен, яңа җыр
Канат җәя күңелемдә.

Аннан күтәрелеп китеп,
Оча дөнья күгенә.
...Туган телем, хәзер миңа
Бөтен дөнья күренә!..

Бирем һәм сорау.

1. «Туган телем» шигырен сәнгатьле итеп яттан сөйләгез.
2. «Туган телем, хәзер миңа
Бөтен дөнья күренә»,—
сүзләре белән автор ни әйтергә теләгән?

оран салмыйм — кычкырмыйм
масаймыйм — мактанмыйм

Туган тел турында сөйләшү өчен сораулар

1. Сез нинди телдә сөйләшәсез? Туган телегез дип кайсы телне саныйсыз? Ни өчен?

2. Кешегә туган телен белү ни өчен кирәк дип уйлыйсыз?
3. Туган тел турында нинди шигырьләр, җырлар беләсез? Авторларын әйтегез.
4. Татар телендә балалар өчен нинди радио һәм телевидение тапшыруларын беләсез? Алар сезгә ошыймы? Туган телебездә тагын нинди тапшырулар булуын телисез? Бу турыда радио һәм телевидениегә татар телендә хат җибәрә аласыз.
5. Тел турында табышмаклар әйтешегез.
6. Түбәндәге мәкаль һәм әйтемнәрдә нәрсә хакында сүз баруын ачыклагыз.

Бер телдә — ун хикмәт,
Ун телдә — йөз хикмәт.
Иң татлы тел — туган тел, анам сөйләп торган тел.
Кул ярасы бетәр, тел ярасы бетмәс.
Суны — таяк белән, кешене тел белән үлчиләр.
Тел — белемнең ачкычы, акылның баскычы.
Тел өчен баш җавап бирер.
Теле барлар халык булган, теле юклар балык булган.
Теле бозыкның күңеле бозык.
Телсез кеше — ярты кеше.
Хайванны — азык белән, кешене тел белән өйрәтәләр.
Һәр илнең ачкычы — тел, телен белгән ил ачар.

Милли традицияләр

МИЛЛИ ЙОЛАЛАР

Милли традицияләр дигәндә аерым бер милләтнең үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, бу милләт кешеләренең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын күз алдында тотабыз.

Тормыш-көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны да үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши дә алмый.

Халык бәйрәмнәре, йолалары кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Әш шунда, ул бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә. Шулай итеп, һәр кеше, табигый рәвештә, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, милли тәрбия ала.

Халык йолалары кешеләрнең күңелен били, чөнки җыр, бию, уеннар башкару, ярышларда катнашу, очрашу-танышулар аларны бер-берләренә якынайта, дуслаштыра. Бәйрәмнәр, йолалар — туган төбәккә, туган илгә мәхәббәт тәрбияләүнең көчле чаралары.

Шулай итеп, милли йолаларыбыз, бәйрәмнәребез милли хисләр формалашуда, милли горурлык тәрбияләүдә әһәмиятле урын тоталар. Халкыбызның гореф-гадәтләре, йола, бәйрәмнәре, әлбәттә инде, буш җирлектә тумаган. Алар арасында

елның төрле вакытларына бәйле, тормыштагы нинди дә булса бер вакыйганы билгеләп үтүгә кагылышлы барлыкка килгәннәре бар.

Мәсәлән, боз озату күренеше яз башланып, елганың йокыдан уянуы белән бәйле рәвештә барлыкка килгән. Суга, елгага безнең халкыбыз изге әйбер итеп караган, елгаларны бервакытта да пычратмаган. Суга төкерсәң, авызың кутырлар, Су тотар сүзләре юкка гына әйтелмәгән.

Татарлар яшәгән авылларда елга-инешләрдә боз кузгалган көн үзенә бертөрле бәйрәмгә әйләнә торган булган. Елга икеөч чакрым ераклыкта булса да, яшь-җилбәзәк, киенеп-ясанып, боз киткәнне яки ташуны карарга барган. Кайбер төбәкләрдә бу көнне яр буенда саламнан зур итеп карачкы ясаганнар. Атна буена яшьләр көн саен шунда уйнарга җыелганнар. Соңгы бозлар киткән көнне карачкыны яндырганнар яисә, соңгы боз өстенә куеп, ут төртеп җибәргәннәр. Әнә шулай алар суык кышны озатканнар. Егетләрнең күбесе гармунчы булган. Яшьләр, корырак җир табып, шунда биеп күңел ача торган булганнар. Елга авыл яныннан ук узса, боз киткәнне карарага өлкәннәр дә барган.

Ботка бәйрәме. Яз көне «ала карда», ягъни кара җир күренгәли башлагач, аксакаллар әйткән көнне бала-чага, өй борынча йөреп, ярмадыр, сөттер, майдыр, йомыркадыр җыеп йөргән. Кайвакытта алар азык-төлекне үз өйләреннән дә алып килгәннәр. Азык-төлек җыеп йөргәндә, балалар такмаклап җырлаганнар:

Дәр, дәр, дәрәгә!
Майлы ботка казанда,
Сырлы кашык базарда.
Иртән торып сөрәнгә,
Берсекөнгә сабанга.

Шулай җыйган ризыклардан болында, тауда, басуда, кайбер очракларда берәр өйдә, бер-ике өлкән яшьтәге хатын җитәкчелегендә, зур казанда ботка пешергәннәр. Сыйланырга бөтен авыл баласы җыелган. Һәркайсы коштабак-кашык алып килгән. Сыйлангач, төрле уеннар уйный торган булганнар. Бу йола һәр җирдә балалар уены рәвешендә үткән. Шул ук вакытта ул Сабантуй бәйрәменең аерылгысыз өлеше дә булган, бәйрәмгә әзерләнә башлау билгесе булып хезмәт иткән.

Май башы. Бусы — чәчүдән соң үткәрелә торган хатынкыз бәйрәме. Ул һәр җирдә диярлек бер үк төрле үткән. Иске

стиль буенча 1 нче май көнне (ә ул атнаның теләсә кайсы көненә туры килергә мөмкин) барлык хатын-кыз авыл тирәсендәге тауларның берсенә киткән. Алар үзләре белән ризык һәм самоварлар алганнар, яисә чәйне казаннарда кайнатканнар. Күмәк табыннан соң уеннар башланган. Таудан манган йомырка тәгәрәткәннәр, аннары үзләре дә җирдә тәгәрәшеп аунаганнар һәм: «Менә яңа май җитте! Хастасырхау иске елда калсын!» — дип тәкрарлаганнар. Бу бәйрәмгә башка авыл хатыннары да чакырылган.

К у н а к л а ш у. Көз һәм кыш алды — авылда муллык чоры, бу вакытта туган-тумачалар, дус-ишләр бер-берсенә кунакка йөрешкәннәр. Кунак чакырышу, гадәттә, билгеле бер көнгә туры китерелмәгән. Кайбер авылларда исә моның махсус көне дә булган.

Ө м ә л ә р. Крестьян хуҗалыгында өмәләр ашлык сугу, утын әзерләү, бура күтәрү һ. б. аеруча авыр һәм зур эшләрне кыска вакыт эчендә башкарып чыгу өчен үткәрелгән.

Яшьләр өмәгә бик теләп барган, авыр эшләрне дә бәйрәм кебек итеп башкарганнар. Гадәттә, эш вакытында җырлар яңгырап торган. Эшне тәгәлләгәч, төрле уеннар да оештырылган.

К а з ө м ә с е н яшьләребез аеруча көтеп ала торган булганнар. Безнең әби-бабаларыбыз казны бик яратканнар. Беренчедән, аның мамыгыннан мендәр, түшәк, ястыклар ясаганнар. Татар өендә мендәр затлы җиһаз булып исәпләнгән. Икенчедән, каз итеннән бик тәмле аш-су әзерләгәннәр. Каз бәлеше, каз коймагы, каз тәбикмәге, каклаган каз... дисеңме. Каз маен дәвалау өчен дә кулланганнар: кышкы суыкларда бит, колак очлары өшесә, каз мае сөрткәннәр.

Шаян сүз, җыр, көлке белән аралашып, эш бик тиз һәм үрчемле барган. Кунак кызларына аеруча ихтирам күрсәтелгән, алар каз өмәсенең түрендә булганнар. Кызлардан соң туган-тумачаны, күрше хатыннарны, карчык-корчыкларны да чәйгә дәшкәннәр.

Халкыбыз милли традицияләргә гаҗәеп бай.

Тормыш шартлары үзгәрү йолалар дөньясына да төзәтмәләр кертә. Алар заманга яраклаша баралар. Ләкин аларның нигезендә ятучы кыйммәтле, затлы, милли, әхлаклы сыйфатларны саклау, үстерү — һәр буынның намус эше.

Сораулар һәм бирем.

1. Халкыбыз өчен милли йолалар, гореф-гадәтләрнең әһәмияте нидә?
2. Дәреслектә өйрәнгәннәргә өстәп, үзегез белгән милли традициябез үрнәкләре турында сөйләгез.
3. Сезнең авылда, районда яки шәһәрдә әлеге йолаларның кайсылары сакланып калган? Сез бу йолаларны кире кайтаруда һәм алга таба камилләштерүдә (мәктәбегездә, сыйныфларыгызда, авылда, шәһәрдә) нинди эшләр башкарасыз?

карачкы — кеше яки хайван рәвешендә ясалган фигура
сыйлау — ашату, эчертү, кунак итү
казан — аш пешерү һәм су кайнату өчен ясалган чуен савыт
коштабак — 1 литр сыйдырышлы агач яки калай тирән тәлинкә
хаста-сырхау — авыру, чир

МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР. САБАН ТУЕ

Һәр милләтнең борын-борыннан килгән йола-гадәтләре, бәйрәмнәре була. Бу аның яшәү рәвешен үзенчәлекле итә. Шулар белән ул башкалардан аерылып тора.

Күп гасырлар дәвамында, әби-бабаларыбыздан күчә-күчә, безнең чорларга кадәр килеп җиткән бик күп милли бәйрәмнәребез бар. Милли бәйрәм дигәндә, без аерым бер милләткә генә хас булган гореф-гадәтләрне, йолаларны, уеннарны, җыр-такмакларны үз эченә алган күңел ачуларны, олы тантаналарны күз алдында тотабыз. Бу бәйрәмнәр — олыларның кече буынга халкыбызның йола-гадәтләрен тапшыру ысулы да.

Бәйрәмнәрнең ел фасылларына, дини йолаларга, тормыш-көнкүрештәге үзгәрешләргә бәйле барлыкка килгәннәре була. Мәсәлән, безнең татар халкында елның төрле вакытлары белән бәйле рәвештә барлыкка килгән Нәүрүз (язны каршылау), Нардуган (кышны каршы алу) бәйрәмнәре ерак гасырлардан күчә-күчә хәзерге көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Татар халкы ислам дине белән бәйле бик күп дини бәйрәмнәрне дә олылап үткәрә килә. Аларның иң зурлары: Ураза гаете, ягъни Ураза бәйрәме (гайде фитыр), Корбан гаете (гайде әзхия), Мәүлид бәйрәме, Гашура бәйрәме.

Рамазан ае — мөселманнарның изге ае. Чөнки шушы айда Аллаһыдан Коръән иңгән. Шуңа күрә Рамазан аен кеше, Аллаһыга күңеле белән якын килеп, ураза тотып уздырырга

тиеш. Ураза тоткан кешенең күңеле сафланып, акылы ачыкланып кала. Ураза гаете — бу айның аеруча изге көне. Ураза ае — иман чынлыгына олы имтихан. Гает алдыннан фитыр садакасы бирелә, кешеләргә күп төрле яхшылыклар кылына.

Корбан гаете исә Ураза гаетеннән соң ике ай да ун көннән (ягъни җитмеш көннән соң) була. Бу көнне Аллаһы Тәгаләгә багышлап сыер, сарык ише мал-туар корбан итеп чалына. Аның ите ятимнәргә, авыру кешеләргә, ярлыларга өләшенә. Өйгә кунак чакырыла, Коръән укытыла.

Гает көннәрендә барча мөселманнар мәчеткә намаз укырга баралар, бер-берсенә кунакка йөриләр, хәлләрен белешәләр, вафат булган ата-аналары, әби-бабалары, туган-тумачалары рухына дога кылалар, хәер бирәләр.

Мәүлид бәйрәме. Бу көнне Мөхәммәд пәйгамбәр туган. Әлеге көндә дә өйләрдә Коръән укыталар, мәчетләрдә шушы көнгә багышланган намаз укыйлар.

Гашура бәйрәме мөхәррәм аеның унынчы көнендә була, ул — пәйгамбәребез Мөхәммәднең, ураза тотып, изге гамәлләр кылган көне.

Мөселман бәйрәмнәре кешедә саф күңеллелек, чисталык, пөхтәлек, миһербанлылык, игелеклелек кебек иң матур һәм кирәкле сыйфатларны тәрбиялиләр.

Кайбер бәйрәмнәр исә татар халкының көнкүрешендәге үзгәрешләренә бәйле рәвештә барлыкка килгәннәр. Олы бәйрәмебез Сабан туе да шулар рәтеннән. Ата-бабаларыбыз, әни-әбиләребез борын-борыннан яз килүне, җир эшләре башлануны дәртләнеп, зур өметләр белән каршы алган.

Озакламый яз җитәр,
Яздан куркып кар китәр;
Изү чишеп, җиң сызганып,
Җырлап эшләр чак җитәр, —

дип җырлаганнар алар. Хезмәттән ямь, тәм тапкан, аннан башка яшәүне бөтенләй дә күз алдына китермәгән авыл кешесе өчен яз — киләчәкнең нигезен салу фасылы. Язның бер көне ел туйдыра, Эшләмәсәң эш көне, ни ашарсың кыш көне, дип юкка гына әйтмәгән зирәк халкыбыз. Җир сөрү, тырмалау, чәчү — аның өчен үзе зур бәйрәм.

Сабан эшләре, чәчү эшләре тәгәлләнгәч, печән чаба башлаганчы, авыл кешесе бераз гына иркен сулыш ала, ял итеп алу мөмкинлеге туа. Тир түгеп, ләззәтләнеп эшләгән крестьян өчен бәйрәм ясап алу да бик урынлы.

Сабан туе — халкыбызның борынгыдан килгән бәйрәме. Аның белән башка халык вәкилләре дә кызыксынганнар. Татарларның бу олы бәйрәменең ни өчен Сабан туе дип аталуы турында немец галиме Карл Фукс (1776—1846 елларда яшәгән) болай дип язып калдырган: «Бу борынгы татар халык бәйрәме һәр язда үткәрелә, анда барлык татарлар да катнаша.

Сабан сүзе *сука́* дигән мәгънәне аңлата. Димәк, әлеге бәйрәм шуны аңлата: табигатьне уятучы яз басуларны эшкәртергә өнди...

Сабан бәйрәмен карарга картлар да килә. Кояш баю вакыты җитсә, алар шунда ук кичке намаз укыйлар. Төзек сафларга басып, җиргә иелә-иелә, дога укыйлар»[1].

Туй сүзе исә татар халкында нинди дә булса олы бер бәйрәм мәгънәсенә туры килә. Мәсәлән, *хезмәт туе, бәби туе, өй туе* һәм башкалар. Димәк, Сабан туе ул чәчүдә, язгы кыр эшләрендә төп корал булган сабанның (суканың) эше беткәч, ягъни чәчү тәгәлләнгәч үткәрелә торган туй, ягъни бәйрәм икән.

Сабан туе

Татар халык көе — *Мөхәммәт Садри шигыре*

Сабан туе — хезмәт туе,
Шатлык һәм бәхет туе,
Уйнап, биеп, җырлап, көлеп
Бәйрәм итик көн буе.

Шау-гөр килә киң болыннар,
Кырлар һәм су буйлары,
Котлы булсын, авылдашлар,
Ямьле Сабан туйлары.

Бәйрәм итик шатланышып,
Туганнар, бергә-бергә,
Безнең бергә булуыбыз
Китсен бөтен гомергә.

---

[1] *Фукс К.* Казанские татары.— Казань, 1991.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Бәйрәмнәр ничек барлыкка килгән?
2. Сез нинди дини бәйрәмнәрне беләсез? Аларның үзенчәлекләрен аңлатып бирегез.
3. Сабан туе бәйрәме ни өчен шулай аталган?
4. М. Садриның «Сабан туе» җырын укыгыз һәм беренче ике юлында әйтелгән сүзләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз. Җырның яңгырашын язмада тыңлагыз. Үзегез дә ул җырны башкарырга өйрәнегез.

кояш баю — кояшның офык (горизонт) артына китүе
дога — дин тотучыларның Аллага ялварып теләкләр теләве
китсен — *монда*: җитсен, сузылсын, барсын

---

* * *

Сабан туен ел буе сагынып көткәннәр, аңа алдан ук әзерләнеп килгәннәр. Ашау-эчү әйберләрен хәстәрләп куйганнар, һәркемгә нинди дә булса яңа кием-салым әзерләргә тырышканнар. Бигрәк тә аны малайлар көткән. Чөнки Сабан туе малайлар өчен аеруча мөһим бәйрәм, монда аларның мөмкинлекләре ачыла. Алар әле җир кардан арчылуга ук йөгерешләр оештырганнар, бер-берсенең чамасын белгәннәр, тауга йөгерешү, шома колгага менү буенча да осталыкларын арттырырга тырышканнар. Ә көрәш! Кайсы малай гына Сабан туе батыры булырга хыялланмый икән? Менә ни өчен ат саклаганда, кичләрен бергә җыелган чакларда, көрәшә-көрәшә, берсен-берсе мәйдан уртасында җиңү серләренә өйрәткәннәр. Осталык үзеннән-үзе генә килми, җиңү өчен көч-куәт, иркен сулышлы булу өстенә, күнекмәләргә ия булу да кирәк.

Әле колхозлар төзелгәнче, күпчелек авыл кешеләренең үз атлары булган. Кайберәүләр махсус рәвештә чабышкылар да асраганнар. Чабышкысы булган малай — бәхетле малай. Чөнки ул Сабан туенда үз чабышкысына атланып ярышачак. Җилдән җитез чапкан ат өстендә җан-фәрманга килү үсмернең үзенә дә канатлар куйгандай тәэсир иткән. Әмма ат өстендә ышанычлы утыру, егылып калмау өчен елгырлык, үткенлек, җитезлек кирәк. Менә ни өчен ат чабыштырырга барырга тиешле малайлар алдан ук күнегүләр уздырганнар, моны «ат аягын кыздыру» дип тә атаганнар.

Кызлар исә, бүләккә бирергә дип, сөлгеләр, тастымаллар, кулъяулыклар чиккәннәр.

Ниһаять, иртәгә Сабан туе дигән көн килеп җиткән. Бу көнне барысының да күңеле күтәренке, һәр өйдә тәмле ашлар, ризыклар пешә, кешеләр бәйрәмнәрдә генә киелә торган киемнәрен кияләр. Бүген Сабан туе бүләкләрен җыячаклар. Менә урамның бер башыннан, гармунга кушылып, егетләр җырлап килгәне ишетелә. Алар, аллы-артлы тезелешеп, урамны иңләп җырлап баралар. Алларыннан сөлге-яулыклар бәйләгән колга күтәргән таза гына бер егет атлый. Бөтен кеше, өйләреннән чыгып, аларны капка төпләрендә көтеп алалар. Килеп җиткәч, бисмиллаларын әйтеп, әзерләп куйган бүләкләрен әлеге колгага бәйләп куялар. Аңа элмәстәйләрен кәрзин, чиләк күтәреп йөрүчеләргә бирәләр. Яшь киленнәр сөлге бирергә тиешләр. Бу — үзгәрмәскә тиешле тәртип. Шуңа күрә кызлар, кияүгә чыкканчы ук, Сабан туена бирергә дип атап сөлге чигеп куялар. Шул рәвешле, бүләк җыю үзе бер күңелле бәйрәмгә әверелә.

Сабан туе бәйрәменең иң төп уеннарыннан берсе, әлбәттә, көрәш. Карл Фукс бу турыда менә нәрсәләр язып калдырган: «Түгәрәк уртасына яшь һәм таза татарлардан ике көрәшче чыга, билләренә сөлге бәйлиләр, куллары белән шуңа тотынып, бер-берсен егарга тырышалар. Бу көрәш кайчакта бик озак дәвам итә, яки, көрәшчеләрнең көченә карап, кайчак бик тиз тәмамлана. Кайсы да булса егыла икән, тамашачылар шаулашып көлешәләр, ә горур җиңүче, бүләк алып, моннан чыгып китә. Бәйрәм вакытында тәртип саклау өчен, татарларның шактые, кулларына таяк тотып, түгәрәк буенча йөреп торалар.

Татарлар бу уеннардан зур ләззәт алалар. Көрәштән тыш ат чабышы һәм йөгерешләр була. Йөгерештә алдан килүчеләргә бүләк итеп кулъяулык бирелә. Аларны йөгереш тәмамланасы урында озын колгага элеп куялар. Татарларның чабышкылары кечкенә гәүдәле, ләкин яхшы чабалар, җайдаклар (гадәттә, малайлар була) атлар белән оста идарә итәләр.

Бу бәйрәмдә татарларның хатын-кызлары да катнашалар. Дөрес, алар төп тамашалардан ераграк торалар. Алар бай киенеп килергә тырышалар, битләрен иннек-кершән белән матурлыйлар. Чит кеше якынлашса, озын җиңнәре белән битләрен каплыйлар. Куаклык янында татар хатыннары балалары белән чәй эчеп утыралар, таныш кеше күренсә, аны да чәйгә утырталар.

Русларның бәйрәмгә исерткеч эчемлек алып килүләренә татарлар ачуланалар. Чөнки, хәмер эчкәннән соң, тәртипсезлекләр

килеп чыга. Шуларны булдырмас өчен, полиция бирегә үзләренең кайбер хезмәткәрләрен һәм берничә казак җибәрә. Билгеле булганча, татарларга аларның кануны буенча исерткеч эчү тыела».

Бу — XIX гасыр Сабан туе күренешләре. Бүгенге көндә дә Сабан туе — халкыбызның иң олы бәйрәмнәреннән берсе. Бәйрәмнең башында, иң беренче эш итеп, сабанда, ягъни язгы кыр эшләрендә бик тырышып эшләгән, хезмәт куйган игенчеләрне хөрмәтлиләр, аларга бүләкләр бирәләр. Иң уңганнарына сабан батыры дигән исем бирәләр.

Сабан туенда көрәш, ат чабышларыннан тыш тагын бик күп уеннар, ярышлар була. Биек һәм шома колга башына менеп, әтәч яки башка бер бүләк алу, бау тартышу, бизәкле чиләк-көянтәләр белән йөгерә-йөгерә су ташу, йөгереш, авызга кашык кабып, анда куелган йомырканы төшермәскә тырышып узышу, шома бүрәнәгә утырып капчык бәргәләшү һәм башкалар.

Кичләрен яшьләр уены Сабан туеның аерылгысыз өлеше булып тора. Бу уеннар элек, йомырка җыю көненнән башланып, берничә көн дәвам иткән. Бәйрәм көнне андый уеннар үткәрү гадәти исәпләнгән. Уенны я көрәш булган җирдә, я су буенда, болында, аланлыкта үткәргәннәр. Яшьләр уенга киенепясанып килгән, бу көнне аларның әти-әниләре дә күңел ачуларына каршылык күрсәтмәгән. Төн урталарына тикле гармун, скрипка тавышы яңгыраган; егетләр һәм кызлар әйлән-бәйлән уйнаганнар, биегәннәр, җырлаганнар. Җырлыбиюле уеннар аеруча күп һәм төрле булган. Хәзерге көндә дә яшьләрнең кичке уеннары Сабан туеның аерым бер бизәге, аерылгысыз өлеше булып тора.

Күргәнебезчә, Сабан туе гади күңел ачу гына түгел. Ул анда катнашучыларны төрле яклап сыный, чыныктыра. Биредә көч сынашалар, осталыкта узышалар, һөнәрләрен арттыралар. Ләкин бер таләп бар: һәммәсе дә гадел, намуслы булырга тиеш.

Сабан туе — якыннарның, туганнарның, дусларның түгәрәкләнеп табын янына җыелу вакыты.

Сабан туе — кешеләрдәге тән тазалыгын күрсәтү генә түгел, бәлки аларның эчке дөньяларының да камиллеген, ныклыгын, яшәү рәвешләренең өстенлеген дә раслаган бәйрәм.

Сабан туе — кешеләрне алдагы зур эшләргә рухландыручы, аларны осталыкка, тапкырлыкка, уңганлыкка, булганлыкка өйрәтүче олы мәктәп.

Сабан туе — өлкәннәрнең яшь буынга үзенең олы тәҗрибәсен, җегәрен, елгырлыгын, ныклы әхлакый нигезгә корылган көн итү кануннарын тапшыру дәресе.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Сабан туе хәстәрләре турында сөйләгез.
2. Немец галиме К.Фукс татарларның Сабан туе турынданиләр яза? Фукс халкыбызның нинди уңай сыйфатларын күрсәтә?
3. Хәзерге вакытта Сабан туенда үткәрелә торган нинди ярышларны беләсез? Берсе турында аерым сөйләгез.
4. *Сабан батыры* һәм *Сабан туе батыры* дип кемнәрне әйтәбез?

хәстәрләре — нинди дә булса бер эш яки бәйрәм һ. б. алдыннан булган әзерләнүләр

Сабан туе күренешләре

Гомәр Бәширов

КӨРӘШ

(*«Туган ягым — яшел бишек» әсәреннән өзек*)

Сабан туен, язның бу шау-шулы, ыгы-зыгылы һәм шатлыклы якты бәйрәмен без, малайлар, кар җепшекләнә башлагач ук көтәргә тотына идек. Сабан туе дигәнебез һаман килә, үзенә күңелле яңалыклар ияртеп көн саен якыная бара. Моны кешеләр генә түгел, хәтта атлар да сизә.

Мәйдан тотасы атларны эшкә җикми башлыйлар. Эчләре җыелып килсен, сулышлары иркен булсын өчен, аларга ипи белән солы гына ашаталар. Койрыкларын кыска гына бәйләп, «аякларын кыздырырга» йөртәләр.

Үзенең көрәшчеләре, чабыш атлары, колга башындагы кызыл башлы сөлге-тастымаллары, канәфер, бадьян, дарчиннәр, әрбет чикләвекләре, төрле төскә буялган күкәйләре, чуклы конфетлары һәм гомергә онытылмаслык гармун көйләре, уен-җырлары — кыскасы, бөтен шау-шулы һәм бизәкле, чуп-чуар куанычлары белән дәп-дәү булып, шаулап, ыгы-зыгы кубарып безнең авылга Сабан туе әнә шулай килә иде...

Иртәгә Сабан туе дигән кичне кем генә тыныч йоклый алды икән!..

...Мәйдан уртасына сирәк кенә коңгырт сакаллы староста килеп чыкты. Күкрәгендә олы җиз калай.

Гыйбаш абзый:

— Күкрәк астына кермә, хәрәмләшмә! — ди-ди, малайларны көрәштереп ята иде.

— Маташма шул малай-шалай белән! — диде староста.— Тизрәк олыларга күч!

— Соң, аның үзенең пүрәдкәсе бар бит. Хәзер яшүсмерләр керә башлый, алар артыннан олылар.

Ул арада кайсыдыр: «Һайт!» — дип кычкырып та җибәрде, һавада ике аяк айкалып та китте, аякларның хуҗасы «дөп» иттереп барып та төште. Төште генәме әле! Бөтенләй тәгәрәп үк китте. Әллә ничә урыннан:

— Булды, булды! — дип аваз салдылар.— Шәп салды! Сызгырып кына барып төште!..

Гәүдәгә базык кына, киң җилкәле бер егет чыкты.

— Кәче егете чыкты, Кәче! — диештеләр.

Халык дулкынлана, гөжли, тора-торгач үзеннән-үзе кычкырып җибәрә, эһелдәп куя. Халык «аһ» итеп бөтен мәйданы белән кузгалып куйганда, Айбан егете әллә кая, мәйдан кырыена ук барып төшкән иде.

Җиңүче егет, ашыкмыйча гына, салмак кына атлап кырыйга барып чүгәләде. Гыйбаш абзый аңа ике йомырка илтеп тоттырды. Көрәшче аларны «чык» иттереп кенә берәм-берәм тешләренә бәреп алды да, башын артка ташлап, авызына агызды.

Кайсыдыр телен чартлатып куйды:

— Әй-әй, таза бу! Кара ул муенны! Кара ул беләкләрне! Бот юанлыгы!

Кәче егетенә каршы көрәшкә чыгучы күренмәгәч, пошынып:

— Һи, эшмени бу? Кая соң безнең егетләр? — дип кычкырды Мөхәммәтҗан җизни.

Шунда барысы берьюлы Әхәт абыйны димли башладылар:

— Йә, чык инде, Әбделәхәт, хур итмә Яңасаланы!

Әхәт абый Кәче егетенә караганда гәүдәгә бераз кәйрәк икән, буйга да кыскарак, муены да тегенеке шикелле юан түгел. Шулай да җилкәгә киң, бары белән нык кына күренә.

Мәйдандагы халыкның һәммәсе дә диярлек, куәт биреп, төрле яктан кычкыра башлады:

— Бирмә билне, Әхәт, бирмә!

— Нык бас аякларны, җиргә сеңдереп!

— Менә шулай, менә шулай!

Кәче егете күтәреп алмакчы булып карый да, шуа китә тегенең кулы. Кемнәрдер көлеп тә җибәрде:

— Аркасын майлап чыкканмы әллә югыйсә безнең Әбделәхәт!

...Көрәш озакка сузылды. Егетләрнең әле берсе тилпенеп карый, әле икенчесе йолкып алмакчы була. Барып чыкмый гына бит!

Әхәт абый «һоп!» дип кычкырып та җибәрде, Кәче егетен суырып та алды. Халык дәррәү урыныннан торды. Инде тотып ата дигәндә, Кәче егете кулын күтәрде.

Бөтенесе мәйдан уртасына ташландылар.

— Ай, маладис, Әхәт туган! — диештеләр.— Ай куандырдың!

— Ур-ра! Ур-ра батырга! Бил бирмәде, сынатмады!

Бу шау-шу, бәлкем, бик озакка сузылган булыр иде. Төрле яктан:

— Атлар килә! — дип аваз салдылар.

җепшекләнә — эри

дарчин — лаврлар семьялыгыннан булган агачның киптерелгән кайрысы (корица)

эрбет — мәңге яшел ылыслы агач (кедр)

хәрәмләшмә — уен тәртипләрен бозма, алдама

Фатих Хөсни

АТЛАР ЧАБА САБАН ТУЕНДА

(*«Йөзек кашы» повестеннан өзек*)

Без әллә кайчан ук сөйләшеп куйдык инде. Җыеннар башланса, ат йөгертергә барабыз. Быел теләгемә ирештем. Җиңел сөякле малай, дип гел мине эзләп йөриләр. Рәхәт тә соң ат өстендә килү! Бөтен халыкның күзе синдә. Атның кайнар ялы синең битеңә сирпелә. Ә алда, биек колга башында, берсеннән-берсе матур булып сөлгеләр күренәләр. Кайдадыр кычкыралар: «Каула, Айдар, каула!»

...Киттек. Барыбыз җидәү: Госман, мин, калганнары ят малайлар. Атлар барысы да — күрер күзгә ягымлы маллар.

Уйнаклап кына баралар. Барып җиттек. Тезелдек. Чыктык. Башта, бер-ике чакрым җирне барыбыз да тигез килдек дип әйтерлек. Бу араны атлар җиргә түгел, хәйләгә басып килделәр. Бер-беребезнең чамасын тарттык, йомшак якларны капшадык. Госман бездән, бер җир буе дип әйтерлек, алдан бара, тик шулай да мине ул түгел, арттан уйнаклап килүче кашка байтал шикләндерә.

Ниндидер юл аермасын үттек, берәү шунда кинәт кенә: «Һа!» — дип кычкырып җибәрде, колагыма җил бәрелде, тояклар ачу белән тупырдадылар. Күземне ачып-йомарга өлгермәдем, кашка байтал минем алга атылып чыкты. Аның арт тоякларыннан балчык атылып минем битемә бәрелде, бераз вакыт күземне ача алмыйча бардым, ә күзне ачарга вакыт бик җиткән иде.

Алда, берничә чакрым ераклыкта, колга башындагы сөлгеләр чагылып киттеләр. Күренделәр, аннары тагын югалдылар. Хәйлә бетте, безнең аяк астында хәзер җир, җитмәсә тагын нинди җир! Я күтәрә ул, я башыңны яра. Мин, ике бармагымны тешемә кысып, сызгырып җибәрдем һәм берничә мәртәбә атыма камчы селтәдем. Уен түгел икәнлекне ат та сизенде булса кирәк, кинәт сикереп алды, мин чак кына артка очып калмадым. Күз алдымда нәрсәләрдер тиз генә яктырып киттеләр, кинәт сүнеп калдылар, битемә үз атымның әчкелтем пары килеп бәрелде. Тагын шул: теге аермадан узып бер-ике генә сикердем, Госманның катына килеп бастым. Аның атының ухылдавы ишетелә, бу — дәртлелек түгел, хәлсезлек билгесе. Минем Госманнан көләсем килде, тик көлгәнче тагын бер сикерәсе бар иде әле. Атыма тагын бер селтәнеп җибәрдем, без хәзер бер тигезлектә барабыз. Тагын бер селтәнсәм, мин аны артка калдырачак идем. Госманга бу ошамады. Атына шәп кенә пар өстәмәкче булып селтәнде дә минем атның алга сузылып бара торган борынына сукты. Күземә кан бәрелде,— күрә дә, уйлый да алмадым...

Госманнан, тагын берничә ярканаттан җиңел генә узып китсәм дә, кашка байталдан узу ансат булмады. Ул сөлек төсле сузылган, ничектер агып бара. Өстендәге малае да божыр күк. Кадакланган шикелле утырган да, кулларын як-якка болгаштырып, очып кына килә. Атны борчымый, телен белгән төсле, әллә нидә бер кычкырып кына җибәрә.

Сөлгегә килеп җитәргә ярты чакрым чамасы җир калганда, без икебез дә бер тигезлектә бара идек. Мәйдандагы халыкның

умарта корты төсле гөжләве ишетелә башлады. Кемдер ярсулы тавыш белән: «Каула, Айдар!» — дип кычкырып җибәрде. Кауларга кирәк икәнен мин үзем дә бик яхшы белә идем, шулай да ул ярсулы тавыш ярап куйды, тартып алган төсле булды ул. Мин тешләремне кысып селтәнеп җибәрдем, нидер ауган-дай булды, божыр күк малай артка шуды, сөлгегә ярты җир буе калды дигәндә, минем атым кашка байталның алдына сикереп чыкты. Күзләремә яшь килде, үзем өчен түгел, кашка байтал өчен.

Мине ат өстеннән кочаклап алдылар, ә атның муенына бик озын сөлге эленде. Кайсыныкы булгандыр, әйбәт сөлге иде ул.

каула — ку, куала, чаптыр
ят — чит
мал — *монда*: хайван, терлек
кашка байтал — маңгаенда ак табы булган 3 яшьлек ат
камчы — каеш яки баудан үреп, ишеп ясалган кыска саплы чыбыркы (плетка)
божыр — чуар каурыйлы урман кошы (рябчик)

МИЛЛИ КИЕМНӘР

Төрле милләт халыклары яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, кайсы дин вәкиле булуы, йөз сызыклары, киемнәр төрлелеге белән бер-берсеннән аерылалар. Ләкин төс-кыяфәт, кием-салым бер дә үзгәрми торган нәрсәләр түгел. Моннан алты-җиде гасыр элек, ягъни Алтын Урда чорында киелгән кием Казан ханлыгы өчен ярап бетмәгәндер. Без исә XIX гасырдагы киемнәрнең дә күбесен музейларда гына күрәбез. Димәк, чорына карап, кешеләрнең киемнәре дә үзгәрә тора. Шуның өстенә бер үк вакытта яшәгән кешеләрнең кием-салымында да аерымлыклар була. Әйтик, көндәлек кия торган, эшкә һәм, әлбәттә, кунакка барганда, бәйрәмнәрдә генә тотылырдай киемнәр була. Шул ук вакытта авыл кешесенең киеме дә шәһәрнекеннән аерыла. Шулай ук кием теге яки бу милләтнең кайда яшәвенә дә, нинди хезмәт белән шөгыльләнүенә дә нык бәйле.

Татар халкы күп гасырлар буена уртача табигатьле урыннарда — Идел-Урал буйларында яшәгән. Габдулла Тукай әйткәнчә:

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава;
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.

Шуңа күрә биредә яшәүчеләргә кием елның һәр фасылы өчен аерым-аерым кирәк. Кыш кигәне җәйгә ярамый, яз-көз өчен тагын үзенә бер төрле кием булуы зарур.

Татарлар белән янәшә марилар, чувашлар, удмуртлар, руслар, мордвалар һәм башка милләтләр яши. Ләкин бу милләтләрнең киемнәре, алардагы бизәкләр гаҗәеп дәрәҗәдә төрле-төрле. Димәк, кием-салымның нинди булуы яши торган урынның табигате белән генә түгел, бәлки бу милләтләрнең ата-бабаларыннан, әни-әбиләреннән килә торган яшәү үзенчәлекләренә, йолаларга, гореф-гадәтләргә дә нык бәйләнгән икән.

Татар хатын-кызлары ситсыдан яки сатиннан тегелгән бала итәкле күлмәк, аның өстеннән алъяпкыч кигән. Алъяпкычның иңөстенә һәм итәкләренә дә бала итәкләр тегелгән, күкрәк турысына, итәгенә чәчәк чигелгән. Башларында дүртпочмаклап бәйләнгән ак яулык, аның баш түбәсенә туры килгән урыны түгәрәкләнеп чигелгән.

Гаяз Исхакыйның 1912 елда язылган «Кәҗүл читек» хикәясендә бер малай болайрак хыяллана: «Минем әти бүген Казаннан кайта. Миңа читек китерә. Өр-яңа читек. Аның саурысы... чәчәкле була. Аның олтаны болгар олтаны, кырыеннан киселгән. Аның балтыры шадраланып тора, чем кара. Миңа иртәгә гаетка барырга әби чапан тегә. Мулла абый миңа иртәгә чалма чалып бирә. Мин гаетка барам. Минем кәвешем әле өр-яңа...»

Болар — малайның уйларындагы киемнәр. Ул вакытта шулай киенгәннәр һәм малай да үзен шундыйрак кыяфәттә күз алдына китерә.

Безнең татар халкы ислам динен тота. Гает намазы укырга мәчеткә барырга тиешле малайның чалма чалып, кәвеш киеп халыкка күренергә теләве табигый. Димәк, киенү рәвешенә динебез дә нык тәэсир иткән.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Төрле милләт кешеләре бер-берләреннән нинди билгеләре буенча аерылалар?

2. Киемнәрнең, вакыт узган саен, үзгәрә баруын аңлатып бирегез.

3. Милләтләрнең нинди табигать шартларында яшәве аларның кием-салымына ничек тәэсир итә?

4. Татар милләте вәкиленең киеменә, табигать шартларыннан тыш, тагын нәрсә йогынты ясый?

5. Татар хатын-кызларының киемнәрен тасвирлап күрсәтегез.

гасыр — йөзьеллык (век)
көндәлек — көн саен кия торган
вә — һәм
фасылы — вакыты
болгар олтаны — болгарларча эшкәртелгән кызыл күннән ясалган олтан (подошва, подметка)
чапан — озын чабулы (итәкле) кием
кәвеш — йомшак күннән тегелгән кунычсыз (балтырсыз) аяк киеме

Галимнәр, язучылар һәм рәссамнар милли киемнәребез турында

Билгеле булганча, безнең нәсел-нәсәпнең бер тармагы болгарларга барып тоташа. Болгарлар исә югары мәдәниятле, белемле, көчле һәм затлы халык булганнар. Мәсәлән, Киев кенәзе Владимир 985 елда болгарларга яу белән килә. Басып алучылар болгарларның яхшы киенгән булуларына игътибар итәләр.

Барысы да яхшы атта,
өсләрендә затлы кием,
аякларында итекләр —
әйтерсең лә барысы да
кенәз йә кенәз оланы!

(Р. Харисның «Ант суы» поэмасыннан)

Киевтан килгән юлбасарларның берсе әйтә:
— Алар барысы да итектән. Алар безгә ясак түләп тормаслар. Әйдә киттек. Үзебезгә чабаталыларны табыйк[1].

Күрәбез, кешенең нинди киемнән булуы башкаларга көчле тәэсир итә. Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар, ди халкыбыз. Шуңа күрә кием-салым, акыл-фигылең дә башкаларда хөрмәт уятырлык булса, күпкә отышлырак. Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» романында баш геройның тасвирлануына игътибар итми булмый. «Артык дәү гәүдәле, чәч-сакалы агара башлаган, алтын җепләр белән аралаштырып тегелгән рум кафтаны кигән Кубрат хан торып баскач, барысы да үзләрен кечерәеп калгандай хис иттеләр. Аягүрә баскан Кубрат ханның күзләрендә, бөтен торыш-кыяфәтендә көч-гайрәт кенә түгел, ниндидер тылсым да бардыр

[1] Повесть временных лет. Ч. 1. — М.-Л., 1950.— С. 257.

сыман иде... Кубрат хан бер адым алга атлады, иелеп, бизәкле табактан энҗе тезгән калфакны алды, килеп, ханшага кидерде».

Биредә сүз 630 нчы еллардагы Бөек Болгар дәүләте ханы турында бара. Моннан 1350 ел элек яшәгән кешеләр әйтерсең лә бүген хәрәкәт итәләр. Ханның кафтаны, ханшаның энҗеле калфагы гына түгел, аларның үз-үзләрен тотышлары, сөйләгән сүзләре дә шул мәҗлестә катнашучыларда хөрмәт уята.

Узган гасырда Казан университетының медицина профессоры Карл Фукс, милләте буенча немец (ул татар телен яхшы белгән, татарлар белән аралашырга яраткан, шуңа күрә безнең милләтебезнең яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен дә әйбәт белгән), татарлар турында уйлануларын, истәлекләрен язып калдырган. Мәсәлән, татар сәүдәгәренең киемен ул болайрак тасвирлый: «Алар күбесенчә тезгә кадәр җиткән ак яки кызыл ситсы күлмәк, шулай ук ситсыдан тегелгән шактый киң ыштан кигәннәр. Аякларында киҗе-мамык яки киндер оекбаш, озын кунычлы сары яки кызыл читек. Алар өстеннән кара яисә яшел башмаклар, я галуш кияләр. Күлмәк өстеннән ике камзол: кечкенәсе җиңсез (ул, гадәттә, ефәк тукымадан тегелә), зурысы — җиңле яки әдрәс кәзәки, аның өстеннән җөббә киеп куялар. Куенда кулъяулык була. Башларына тәкыя, түгәрәк бүрек кияләр.

Татарлар һәр шимбәдә сакал-мыек төзәтәләр, ике атна саен чәч алдыралар. Җомга көнне мунча керәләр...»

Ә менә бай сәүдәгәр хатыннары ничек киенгән? «Муен тирәләре һәм күкрәк турысы чигүле, аяк йөзенә кадәр җиткән озын күлмәк, чәчәкле ситсыдан киң ыштан. Читек. Кызыл сафьян башмак. Ефәк яки парчадан эшләнгән күкрәкчә. Җиңсез камзол, аның буе тезгә җитә, уң якта кулъяулык өчен кесәсе дә була. Озын җиңле җилән (хәзер җилән модадан чыгып, аның урынына озын җиңле камзул кию гадәткә кереп бара). Зур ефәк яулык, ул калфак өстенә беркетелеп куела. Алтын йөгертелгән беләзекләр. Бармакларда йөзек (байларда хәтта һәр бармакта була). Гадәттә, бердән үрелгән чәч толымы, аның очына чулпы тагыла»[1].

Күрәсең, әлеге профессор күбрәк баерак татарлар белән аралашкан. Ярлылар, әлбәттә, хәлләренә карап, гадирәк киенгәннәр. Авылда яшәүче татарларның киемнәре шулай ук аерылып

---

[1] *Фукс К.* Казанские татары.— Казань, 1991.

торган. Мәсәлән, М. Фәйзи «Галиябану» драмасында (1916 елда язылган) уенда катнашучыларның өс-башын болайрак сурәтли:

«Бәдри — илле яшьләрдәге кеше. Беренче һәм дүртенче пәрдәләрдә, ягъни өй арасында йөргән вакытта болай киенә: ыштаннан, читек, камзул, тәкыядан. Ә инде шәһәргә барганда, ул чалбар, кәзәки, бүрек кигән.

Егерме бер яшьлек Хәлилнең исә аягында ыспай (матур, таман итеп тегелгән, ялтырап торган) итек, каплавыч яка, итәкләре чигелгән күк сатин күлмәк өстеннән төймәләми генә простойрак пиджак кигән. Башында кырынрак салынган җәйге бүрек.

Бай егет Исмәгыйльнең киеме бөтенләй башкачарак: аягында америкаи итек, ыспайлыгы бик күзәтелмәгән киң генә чалбар, өстендә һәйбәт тужурка, башында эшләпә.

Галиябану — унҗиде яшьлек кыз — бик матур. Аягында яңа читек-кәвеш, өстенә яңа күлмәк киеп, чуар алъяпкыч бәйләгән, чәчүргеченә чулпылар таккан, яулык бәйләп шәл ябынган».

Мирхәйдәр Фәйзи 1923 елның 4 маенда Казанда гает көнне күргәннәрен көндәлегенә язып куйган. «Татарлар ду килеп бәйрәм итә. Ирләр һәммәсе диярлек каракүл бүректән, кыз-хатын калфактан, шәлдән. Башка киемнәре һәммәсе европача»[1]. Шул ук елның 27 маенда ул Балтач ягындагы Түнтәр авылындагы җыен бәйрәменә килеп чыга һәм аның көндә-легендә менә мондый юллар барлыкка килә: «Ап-ак оеклар, яңа чабаталар, итекләр, ак алъяпкычлар, чиккән күлмәкләр, бүрек, кәләпүш, эшләпәләр кигән егетләр! Оек-чабата, ботинка, чуар күлмәкләр, чуар алъяпкычлар, яулыклар белән кызлар күзләрем белән иркәләнеп, күңелемдә тирбәтеләләр»[2].

Күренекле әдип Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда суга баручы кызлар менә болайрак сурәт-ләнә: «И чибәр киенгәннәр дә инде! Бигрәк тә кунак кыз. Башында кәшемир шәл, өстендә иңбашлары күпертмәле зәңгәр жикет, аягында сай гына кунычлы ак киез ката. Аның йөзен яшелле-зәңгәрле, аллы-шәмәхә дебеттан ясалган чәчәк сыман нәрсә матурлап тора. Ул бәрән йонынннан гына бәйләнгән нечкә челтәр кунычлы ап-ак перчаткасенең бармак очлары белән генә авызын каплаган.

---

[1] Шәһри Казан. — 1993, 14 август, 4 бит.

[2] Шунда ук, 5 бит.

Башка кызларның да өсләрендә яңа күлмәк белән кешелеккә генә киелә торган яхшы бишмәт я жикет, башларына күзеңнең явын алырдай аллы-гөлле шәлләр бөркәнгәннәр. Исең китмәле»[1].

Г. Бәширов Кибәхуҗа авылыннан килгән Ерак әбисенең өсте-башын болайрак итеп хәтерләп калган: «Әбинең өстендә ала-кола бикасап камзул, башында тәкыя, аның өстеннән юка шәл, баш түбәсендә кызыл ашъяулыкка төргән зур гына төенчеге бар»[2].

Менә шулай, җенесенә, яшенә, матди хәленә карап, татарларның киемнәре төрле-төрле булган. Вакыт узган саен, әкренләп үзгәрешләр керә барган.

Шулай да авыл җирләрендә киемдәге миллилек озаграк сакланды. Мәсәлән, атаклы рәссам Харис Якупов әле 1960 елларда Питрәч районының Шәле авылы хатын-кызларының рәсемнәрен ясады. Шулардан иң уңышлыларыннан берсе — терлекче хатын-кыз (М. Галиуллина) портреты. Ак җирлеккә эре чәчәкләр төшерелгән балитәкле ситсы күлмәк, кызыл алъяпкыч, артка кайтарылып бәйләнгән яулык, эре гәрәбәләрдән тезелгән муенса. Ике кулда да көмеш беләзек, колакта түгәрәк алка. Ә иң мөһиме — сәламәт, үзенең хәләтеннән канәгать, ачык йөз. Чак кына елмайган иреннәре арасыннан күренеп торган ап-ак таза тешләр портретны тагын да ачып җибәрә.

Милли киемнең гүзәллегенә яшь буынның игътибарын җәлеп итүгә әдәбият-сәнгать эшлеклеләре дә даими тырышлык куйдылар. Татар дәүләт академия театры бу яктан аеруча зур эш башкарды. Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җырчылары, биючеләре дә милли киемнәребезне горурланып киделәр. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле исә татар киемнәренең нәфислеген бик күп халыкларга күрсәтте, шулай итеп, халкыбызның затлылыгын, абруен раслады.

Татар милли киемнәрен аеруча үз иткән аерым шәхесләребез дә булды. Аларның берсе — тәүге татар опера җырчыларыннан булган һәм композитор буларак танылган олы шәхесебез Сара Садыйкова. Ул сәхнәгә һәрвакыт озын милли күлмәк, энҗеле калфак киеп чыга торган иде. Татарча камил,

---

1 *Бәширов Г.* И язмыш, язмыш... — Казан: Татар. кит. нәшр.— 1990, 152 бит.

2 Шунда ук, 157 бит.

нәфис итеп, хисләнеп сөйләве тыңлаучыларны җәлеп итә, тәэсирләндерә. «Бу ханым сәхнәдә яктырып-матурланып китә. Сара ханым сәхнәдә чагында, тамаша залында бер генә дә битараф, ваемсыз чырайны күрми идең»,— ди Г. Бәширов.

Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен дә гомере буе татар кәләпүше киеп йөрде. Ул елларда Казанда Шиһабеддин Мәрҗани мәчетенә йөрүчеләрнең башында гына кәләпүш күрергә мөмкин иде. М. Хөсәенне исә сәхнәләрдә дә, шигъри митингларда да, язучылар җыелышларында да кәләпүштән күрергә гадәтләндек. Кәләпүш Мәхмүт ага Хөсәеннең аерылмас юлдашы булды.

Кәләпүшем, димәк, Тукай төсе,
«Тәфтиләвем», «Әллүкием» ул.
Мәрҗаниләр, Гаяз Исхакыйлар,
Кариевлар кигән кием ул.

(*Мәхмүт Хөсәен. «Кәләпүшем»*)

Халкыбыз бүген үзенең матур гореф-гадәтләрен кайтара, рухын яңарта. Бу, әлбәттә, аның кием-салымына да карый. Хәзерге яшьләр ата-бабаларыбыз, әни-әбиләребез яратып кигән өс-баш киемнәренә игътибарларын көннән-көн арттыра баралар.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Борынгы бабаларыбыз болгарларның кием-салымы турында сөйләгез.
2. К. Фуксның татарларны ничек итеп сурәтләве турында әңгәмә уздырыгыз.
3. М. Фәйзи, Г. Бәширов әдәби әсәрләрдә геройларның киемнәрен ничек итеп тасвирлыйлар?
4. Татар милли киемнәренә зур хөрмәт белән караган әдәбият-сәнгать әһелләре турында сөйләгез. Аларның нинди әсәрләрен беләсез?
5. М. Хөсәен ни өчен кәләпүшне «Тәфтиләвем», «Әллүкием» дип атый икән?
6. «Минем әбием (яки бабам) яшь чагында ничек киенгән?» дигән темага сочинение языгыз. Әби-бабаларыгыздан, олы буын кешеләреннән истәлекләр язып алыгыз. Сыйныфташларыгыз белән бергәләп укыгыз.
7. Өйдәге милли киемнәрне мәктәпкә алып килеп, күргәзмә оештырыгыз. Ул киемнәр турында сөйләшүдә өлкәннәрне дә катнаштырыгыз.

нәсел-нәсәп — ата-бабаларыбыз (элекке буыннар)
мәдәниятле — культуралы
дәүләт — государство
затлы — яхшы, әйбәт
оланы — улы
юлбасар — басып алучы
ясак — налог
Кубрат хан — Бөек Болгар дәүләтенең ханы
кафтан — озын чабулы (итәкле) өс киеме
ханша — хан хатыны
сәүдәгәр — сату-алу белән шөгыльләнүче (купец)
тәкыя — түбәтәй
кәзәки — җиңле һәм кечерәк кенә утыртма якалы өс киеме
эдрәс кәзәки — ярым ефәк чуар тукымадан тегелгән кәзәки
чәчүргеч — чәч үрү өчен кулланыла торган тасма
җөббә — ефәк җилән
җилән — җәйге пальто сыман озын өс киеме
кешелеккә киелә торган — кеше арасына чыкканда киелә торган, ягъни яхшыга, чистага, мәсәлән, кунакка барганда кия торган киемнәр (кайбер урыннарда «рәешкә кия торган» дип тә әйтәләр)
бикасап камзул — буй-буй ярым ефәк тукымадан тегелгән камзул

МИЛЛИ ОРНАМЕНТЛАР. БИНА-КОРЫЛМАЛАРНЫ БИЗӘҮ ЫСУЛЛАРЫ

Халкыбызның борынгы мирасының бай булуы таң калдыра... Зәвык белән эшләнгән күпме әйберләрне без соклана-соклана карыйбыз, аларны барлыкка китергән осталарга гаҗәпләнәбез. Нәфис манаралы таш һәм агач мәчетләр, сыр-сыр бизәкле каберташлар, асыл кулъязма китаплар, кадерле шәмаилләр, алтын җепләр белән чигелгән милли калфаклар, зиннәтле хәситәләр, Казан сөлгеләре, каюлы читекләр, кыйммәтле ука белән чигелгән китап япмалары, кечкенә алтын Коръән савытлары... Болар барысы да татар халкының милли орнамент үрнәкләрен тәшкил итә. **Милли орнамент** дигәндә без шул милләткә генә хас булган кабатланучы сызым элементларына яки үсемлек һәм хайваннар дөньясына бәйләнешле булган төрле формадагы бизәкләрне күз алдына китерәбез.

Татарларның сәнгате гарәп, фарсы, төрки мәдәниятләр белән берлектә ислам мәдәнияте дигән олы мирасның бер өлешен тәшкил итә. Әйе, безнең мәдәниятне ислам дине

йогынтысыннан башка күз алдына китерүе дә кыен. Шәрык мәдәнияте татар халкы өчен үрнәк булган дип тә әйтергә кирәк. Шул ук вакытта башка милләтләр дә аңардан күп нәрсәләргә өйрәнгәннәр.

Аның фольклоры, үз сәнгать төрләре, аңа гына хас орнаментлары бар. Шәһәр һәм авыл һөнәрчеләре күп гасырлар дәвамында безгә бүген дә рухи азык булырдай гүзәл әйберләр эшләүне үзләштергәннәр. Европа халыкларыннан безнең сәнгатебез үзенчәлекле булып аерылып тора. Инглиз, французларда, итальяннарда, немецларда, русларда, мәсәлән, сурәтчелек нык алга киткән, Шәрык халыкларында исә әйбер бизәү һәм көнкүреш кирәк-яракларын матур итеп эшләү бик югары дәрәҗәгә җиткән.

Сәнгать кешенең бөтен яшәеш мохитен, йортын, киемен, савыт-сабаларын, куллану әйберләрен миллилек белән сугарган. Тере әйберләрне (кеше, хайван, кошларны) ясау гадәте булмаганга, бездә орнамент белән мавыкканнар. Орнамент-бизәк эчтәлексез сурәт кенә түгел, аны камиллеге ягыннан гүзәл музыкага, төсләр балкышына, сихри моңга тиңләп була. Орнамент теле халыкның аңа гына хас күңел дөньясын, рухын, сәнгати зәвыгын, уйлау һәм фикер йөртү үзенчәлеген чагылдыра.

Халкыбызның орнаментлары аның иң борынгы шөгыльләреннән саналган төзелеш өлкәсендә аерым урын алып тора.

Борынгы шәһәрләребездәге бина-корылмаларның рәвеше ниндирәк булганлыгын хәзерге вакытта күз алдына китерүе читен, чөнки ул тарихи истәлекләр безнең заманнарга кадәр килеп җитмәгән диярлек.

Әмма тарих һәм археология фәннәренә һәм галимнәребезнең кайчандыр без аралашып яшәгән шәркый дәүләтләрнең архитектура истәлекләрен өйрәнүләренә нигезләнеп, ул өйрәнүләрне үзебезнең корылмалар турындагы мәгълүматлар белән чагыштырып, борынгы шәһәрләребезнең йөзен күпмедер чамалый алабыз.

Бина-корылмаларның формалары, төзелү рәвеше, бизәлеше бик күп сәбәпләргә бәйле. Табигый шартлар да, ул җирдә теге яки бу төзү материалының булуы я булмавы да, гореф-гадәтләрнең аермалыгы да биналарның төзелешенә йогынты ясаган.

Безнең борынгы бабаларыбыз да үзләрен дөньяга оста төзүчеләр итеп танытканнар. Матур калалар, кальга-крепостьлар

салганнар, биек манаралы мәчетләр, сарайлар төзегәннәр. Болгар дәүләте, гомумән, шәһәрләр дәүләте булып саналган. Безгә бүгенге көндә ул заманнардагы бик күп шәһәр урыннары билгеле.

Хәзерге Татарстан җире элек-электән урманга бай булган, төзелеш өчен кирәкле агачка аптырамаганнар. Ата-бабаларыбыз мәчет-манараларны, йортлар, келәтләр, мунчаларны нараттан, ә күперләрне, базлар, коелар, агач диварлар, шәһәрне уратып алган саклану коймаларын имән агачларыннан төзегәннәр. Болгар иленең халкы күбесенчә агачтан салынган өйләрдә яшәгән. Хан сарайларын, байлар йортларын, шәһәр мунчаларын, зур мәчетләрне, төрбә-мавзолейларны таш-кирпечтән төзегәннәр, аларны зиннәтле бизәкләр белән нәкышләгәннәр.

Затлы таш биналарны зиннәтләп бизәгәндә, төрле-төрле материаллар кулланганнар. Алтын Урданың төзү сәнгатендә ялтыравыклы плитәләр еш кулланылган. Аларның хәзер табылган кыйпылчыкларында ак, зәңгәрсу, яшел, сары, кызгылт-көрән төсләрне еш очратырга мөмкин.

Плитәләрдәге язулар ак төстә, чәчәк сурәтләре һәм кечкенә бизәк өлешләре сары, кызыл, зәңгәр белән йөгертелгән. Биналарның эчке һәм тышкы өлешләрен, кәрнизләрен, тәрәзә һәм ишек йөзлекләрен мозаика белән матурлаганнар.

Таш корылмалардагы тәрәзәләрне элек челтәрле рәшәткәләр бизәгән. Андагы гарәби орнаментларны гипстан коеп эшләгәннәр һәм аны «пәнҗәрә бизәкләре» дип йөрткәннәр. Челтәр араларына беркетелгән төсле пыялалар үзенә бер матурлык биреп торганнар. Биналарның бик әһәмиятле өлешләрен, ишек һәм тәрәзә йөзлекләрен чәчәк сыман итеп ясалган ак ташлар белән дә бизәгәннәр. Идәннәрне матурлап нәкышләгәннәр, аның өстенә гүзәл келәмнәр җәйгәннәр, диварга шәмаилләр элгәннәр. Агач ишекләрне дә бизәкләргә онытмаганнар.

Татар кешесе болындагы чәчәкләргә карап соклана белгән һәм ямьле табигать төсләрен гасырлар буена милли бизәкләренә күчерә барган.

Шәрык илләрендә гарәби бизәкләрне ләззәтле вә моңлы көй белән чагыштырганнар. Мөселман халыкларының сәнгатендә нәкыш салу һөнәре әһәмиятле эш булып саналган һәм шуңа күрә бизәк ясаучы осталар зур хөрмәт казанганнар.

Татар халкының бизәкләрендә лалә (тюльпан), кашкарый (астра), алтын чәчәк (хризантема), дәлия (георгин), мәк, канәфер

(гвоздика), ромашка, кыңгырау (колокольчик), гөлҗимеш (шиповник), күкчәчәк (василек) һ. б. чәчәк сурәтләре еш таралган.

Татар халык орнаментларында төрле җан ияләрен: бөҗәк, күбәләк, кош-кортлар, чабыш атларын сурәтләүләрне дә күрергә мөмкин. Болгар сәнгатендә бигрәк тә көн дә күз алдында булган хайван сурәтләре күп. Сурәт, сыннар арасында Идел-Кама буе хайваннар дөньясында булмаган арыслан, юлбарыс, чаян кебек җан ияләренең рәсемнәре дә очрый. Боларны Көнчыгыш сәнгате тәэсире һәм борынгы төрки традицияләр сакланышы итеп карарга кирәк.

Габдулла Тукай әйтмешли: «Халык зур ул, көчле ул, әдип ул, шагыйрь ул». Халкыбыз иҗаты — ата-бабаларыбызның сүз-тел сәнгатен һәм көй-моңнарын, акыл-фәлсәфә җимешләрен һәм тормыш тәҗрибәсен, уен-бию үрнәкләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен һәм гореф-йолаларын бергә җыйган олуг диңгездер. Безнең рухи һәм әхлакый яктан савыгуыбызга, иман яңартырга һәм күңелләребезне сафландырырга ярдәм итәргә тиешле иң изге шифалы милли чыганак та, һичшиксез, шулдыр.

Сораулар.

1. Ни өчен татарларда орнамент сәнгате аеруча нык үсеш алган?
2. Татар халык сәнгатенә аеруча кайсы халыкларның йогынтысы зур булган?
3. Борынгы бабаларыбыз нинди биналар салуда зур уңышларга ирешкәннәр? Төзелештә нинди материал файдаланылган?
4. Биналарны, көнкүреш әйберләрен матурлауда нинди бизәкләр файдаланылган?

орнамент — бизәк
нәкыш — агач, сөяк кебек нәрсәләргә кисеп, уеп, сырлап яки чокып ясалган бизәк
олуг — олы, зур

Йомгак

Менә дәреслекнең соңгы битенә дә җиттек. Шуның белән быелгы уку елы да тәмамлана. Ләкин тормыш дәвам итә, белем алуга булган омтылышны да туктатып булмый. Белгән саен күбрәкне беләсе килә. Сез дә җәйге ял вакытында матур әдәбиятыбыздан аерылмассыз дип ышанабыз. Дәреслеккә әдәби әсәрләрнең бик азы гына кертелде. Сез быел иҗатларын өйрәнгән язучы һәм шагыйрьләрнең әле тагын күпме яхшы әсәрләре бар! Аларны китапханәдән алып укысагыз, сезнең алда нинди кызыклы дөнья ачылыр иде.

Халкыбызның каһарман кызы Сөембикә турындагы әсәрләрне уку сезгә үткәннәребезне дөрес аңларга ярдәм итәр. М. Җәлил, А. Алиш, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, И. Гази, З. Нури, С. Хәким, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин һ. б. кебек каләм осталарының тагын бик күп әсәрләре сезне көтә.

7 нче сыйныфта исә сез Г. Тукай, М. Гафури, Г. Ибраһимов, Г. Кутуй, Х. Туфан, Ә. Еники, З. Мансур һәм башкаларның иҗатлары белән танышырсыз. Аларның әсәрләрен табып укый торсагыз, киләсе уку елында үзегезгә әдәбият дәресләрендә җиңелрәк һәм кызыклырак булыр иде.

Ял вакытының бер өлешен китап укуга багышлауның никадәр файдалы һәм мавыктыргыч икәнен сез тора-бара үзегез дә яхшы төшенерсез. Матур әдәбият әсәрләрен күп укырга яраткан кеше белән сөйләшү, аралашу кызыклы була, ул башкаларны үзенә җәлеп итеп тора. Ә бу исә — кеше өчен олы бәхет. Укыйк, белем туплыйк, хис-кичерешләргә байыйк, бәхетле булыйк, мәгънәле яшик!

Китап тормышыгызда олы киңәшче булып әверелсен!

6 нчы сыйныф дәреслеге авторлары

ЭЧТӘЛЕК

Татар халык авыз иҗаты. Җырлар 4
Казан Кремле, Сөембикә манарасы һәм аларның архитектурасы 11
Абдулла Әхмәт 18
Үги кыз 19
Муса Җәлил 45
Чәчәкләр 48
Кызыл ромашка 50
Зөләйха Хисмәтуллина 52
Азат Аббасов 55
Рөстәм Яхин 57
Абдулла Алиш 59
Ялкаулык — хурлык, тырышлык — зурлык 62
Габдрахман Әпсәләмов 66
Миңа унтугыз яшь иде 67
Һади Такташ 84
Иптәшләр 87
Җәүдәт Фәйзи 92
Урман кызы. *Һади Такташ* 94
Ибраһим Гази 96
Йолдызлы малай 98
Фуат Халитов 103
Шәүкәт Биктимеров 106
Зәки Нури 109
Яңа шәһәр 111
Сибгат Хәким 113
Җырларымда телим 116
Бакчачылар 116

Ләбибә Ихсанова 128
Лачын кыз 130
Бүләк 133
Равил Фәйзуллин 140
Көмәч пешерүчеләр җыры 142
Фатих Хөсни. Сөйләнмәгән хикәя 147
Шәүкәт Галиев. Саумысез, арышларым 152
Радик Фәизов. Ә Җирдә тереклек бармы? 154
Нур Әхмәдиев. Минем туган көнем 163
Илгизәр Солтан. Туган якта кунакта 174
Илнар теләге 175
Туган телем 178
Милли традицияләр
Милли йолалар 180
Милли бәйрәмнәр. Сабан туе 183
Милли киемнәр 193
Милли орнаментлар. Бина-корылмаларны бизәү ысуллары 200

Учебное издание

Галимуллин Фоат Галимуллович
Мифтиева Фарида Киямовна
Гилязов Ильдус Гилязович

ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА

Учебник-хрестоматия для 6 класса
средней общеобразовательной школы
с русским языком обучения

(для учащихся-татар)

Казань. Издательство «Магариф». 2005

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Галимуллин Фоат Галимуллович
Мифтиева Фәридә Кыямовна
Гыйләҗев Илдус Гыйләҗевич

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
6 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия

(татар балалары өчен)

Редакторы *И. И. Кадыйрова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *В. С. Тимошкин*
Корректорлары *Г. Р. Ногманова, С. З. Гыймалетдинова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләре
Э. Ф. Нурмөхәммәтова, Л. Р. Вафина

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 3.08.2005. Форматы $60\times90^1/_{16}$.
Китап-журнал кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 13,0 + вкл. 0,25 + форз. 0,25.
Нәшер-хисап табагы 10,59 + вкл. 0,21 + форз. 0,39.
Тиражы 13 800 д. Заказ А-471.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ААҖ «Идел-Пресс»
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Дәреслекнең саклану дәрәҗәсе

№	Укучының исеме һәм фамилиясе	Уку елы	Дәреслекнең торышы	
			ел башында	ел азагында
1				
2				
3				
4				

Сабантуй. *Э. Золондинов фотосы*